СЫНАУЛАР ҺӘМ ҖИҢҮЛӘР ГАСЫРЫ
ВЕК ИСПЫТАНИЙ И ПОБЕД

КЕШЕЛӘР ҺӘМ ҖИР ТАРИХЛАРЫ
ИСТОРИИ ЛЮДЕЙ И ЗЕМЛИ

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министырлыгының 100 еллыгына

К 100-летию Министерства сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан

ДВОРЕЦ ЗЕМЛЕДЕЛЬЦЕВ

ИГЕНЧЕЛӘР САРАЕ

Дорогие друзья!

Во все времена труд аграриев был основой общества, гарантом его выживания, процветания государства. Сегодня, в юбилейный для республики год, у нас есть еще один замечательный повод от всего сердца поблагодарить тружеников села за их благородный труд. Ведь 100-летие ТАССР – это, в том числе, и 100 лет развития сельского хозяйства республики.

Эта книга – своего рода подведение итогов нелегкого, но очень востребованного труда наших соотечественников. И тех, кто находился у истоков создания агропромышленного комплекса республики, и тех, кто сейчас формирует имидж Татарстана, как региона, в значительной мере обеспечивающего продовольственную безопасность страны. А тот факт, что республика много лет находится среди лидеров российского сельского хозяйства, подтверждает устойчивость этого поступательного развития.

Представленный в книге материал свидетельствует, каким непростым был путь становления сельскохозяйственной отрасли республики. Были и трагические испытания, которые вознаграждались заслуженными победами. Может быть, в историческом контексте 100 лет – срок не большой, но, сравнивая состояние аграрного сектора Татарстана на разных исторических этапах, понимаешь, насколько изменилась наша жизнь. Уверен, книга будет способствовать формированию у молодого поколения уважительного отношения к сельскому труду, которое нам передалось от отцов и дедов.

Развитие села – это не только забота о хлебе насущном. Это также забота государства о благополучии сельчан, труд которых, как и 100 лет назад, несет в себе неиссякаемую любовь к земле, к очагу родного дома, к устоявшемуся сельскому укладу жизни.

Пословица гласит: «Мы не унаследовали Землю от наших предков. Мы берем ее взаймы у наших потомков». От нас зависит, каким будет село будущего. И глядя сквозь призму истории, понимаешь, сколько всего нам еще нужно сделать, сколько внедрить новых технологий и воплотить в жизнь прорывных идей, чтобы по максимуму автоматизировать труд сельчан, а их семьи обеспечить современной инфраструктурой и доступной социальной средой.

Желаю всем нам успехов на этом пути!

Рустам Нургалиевич Минниханов
Президент Республики Татарстан

Кадерле дуслар!

Аграрийлар хезмәте һәрвакытта да җәмгыятьнең нигезе, аның сакланышы, дәүләтнең чәчәк атуы гаранты булып тора. Бүген, республиканың юбилее елында, авыл хезмәтчәннәренә намуслы хезмәтләре өчен ихлас рәхмәтебезне белдерергә тагын бер күркәм форсат туды. Чөнки ТАССРның 100 еллыгы – республика авыл хуҗалыгының да 100 еллык үсеше ул.

Бу китап – ватандашларыбызның авыр, әмма бик тә кирәкле хезмәтенә үзенә күрә бер йомгак ясау. Республиканың агросәнәгать комплексын оештыруның башында торучыларның да, илебезнең азык-төлек иминлеген шактый зур күләмдә тәэмин итүче төбәк буларак, хәзерге вакытта Татарстан имиджын булдыручыларның да хезмәтен бәяләү. Республиканың күп еллар дәвамында Россия авыл хуҗалыгы лидерлары арасында булуы исә әлеге омтылышлы үсешнең тотрыклылыгын раслый.

Китапта урын алган сәхифәләр республиканың авыл хуҗалыгы тармагын торгызу юлының гади генә булмавын дәлилли. Лаеклы җиңүләргә китергән фаҗигале сынаулар да була. Ихтимал, тарих өчен 100 ел бик үк дәвамлы чор түгелдер, әмма Татарстанның аграр секторының төрле тарихи этаплардагы торышын чагыштырып караганда тормышыбызның никадәр үзгәрешләр кичергәне ачык аңлашыла. Иманым камил, китап яшь буында авыл хезмәтенә карата ата-бабаларыбыздан тапшырыла килгән ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыруга ярдәм итәр.

Авылның үсеше – ул икмәк турында кайгырту гына түгел. Бу шулай ук дәүләтнең авыл кешеләре иминлеге турында кайгыртуы да, аларның хезмәте исә, 100 ел элеккеге кебек үк, җиргә, туган нигезгә, ныклы авылча яшәү рәвешенә бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт белән сугарылган.

«Без Җирне ата-бабаларыбыздан мирас итеп алмадык. Без аны киләчәк буыннардан әҗәткә алып торабыз», диелә мәкальдә. Киләчәк авылының нинди булачагы бездән тора. Тарих күзлеге аша караганда, шуңа төшенәсең: безнең әле авыл халкының хезмәтен максималь дәрәҗәдә автоматлаштыру, ә аларның гаиләләрен заманча инфраструктура һәм уңайлы социаль тирәлек белән тәэмин итү өчен никадәр эшлисебез бар, никадәр яңа технологияләр кертәсебез һәм алгарышлы идеяләрне гамәлгә ашырасыбыз бар.

Бу юлда барыбызга да уңышлар телим!

Рөстәм Нургали улы Миңнеханов
Татарстан Республикасы Президенты

Уважаемые коллеги!

Республика Татарстан является одним из крупнейших аграрных регионов страны, ежегодно демонстрируя стабильные темпы развития агропромышленного комплекса. Сегодня, когда аграрная политика страны нацелена на укрепление продовольственной безопасности, обеспечение роста производства сельхозпродукции и повышение ее конкурентоспособности в России и за рубежом, аграрии региона вносят существенный вклад в достижение общих результатов, а их успешная деятельность служит основой благополучия и процветания республики.

Успешное развитие АПК Татарстана во многом определяют богатый опыт и знания, накопленные поколениями земледельцев и животноводов, высокая культура ведения сельского хозяйства, а также готовность активно применять новые технологии и достижения аграрной науки. В настоящее время сельскохозяйственная отрасль – одна из передовых в отечественной экономике, в ней широко используются инновационные научные разработки и современные средства производства, внедряются прогрессивные цифровые решения. Татарстан всегда был среди лидеров развития этих процессов. Республика и сегодня ставит перед собой серьезные задачи по повышению эффективности АПК, модернизации и обновлению материально-технической базы сельскохозяйственных предприятий, реализации новых современных инвестиционных проектов, расширению каналов сбыта произведенной сельхозпродукции, улучшению условий работы людей на селе.

Хочу выразить глубокую признательность аграриям региона за высокий профессионализм, преданность своему делу и способность неизменно добиваться результата. Ваш опыт и целеустремленность – замечательный пример для подрастающего поколения, которому предстоит сохранить и преумножить столетние традиции сельского хозяйства Татарстана и богатства нашей земли.

Дмитрий Николаевич Патрушев
Министр сельского хозяйства
Российской Федерации

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Татарстан Республикасы – илебезнең агросәнәгать комплексы үсешенең тотрыклы темпларын даими чагылдыручы иң эре аграр төбәкләрнең берсе. Бүген, илнең аграр сәясәте азык-төлек иминлеген ныгытуга, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү үсешен тәэмин итүгә һәм аның Россиядә һәм чит илләрдә көндәшлек сәләтен арттыруга юнәлдерелгән чорда, төбәк аграрийлары уртак нәтиҗәләргә ирешүдә зур өлеш кертә, ә аларның уңышлы эшчәнлеге республиканың иминлеге һәм чәчәк атуы нигезе булып тора.

Татарстан агросәнәгать комплексының уңышлы үсешен күп очракта игенчеләр һәм терлекчеләр буыннары тарафыннан тупланган бай тәҗрибә һәм белемнәр, авыл хуҗалыгын алып баруның югары культурасы, шулай ук аграр фәннең яңа технологияләрен һәм казанышларын актив кулланырга әзер булу билгели. Хәзерге вакытта авыл хуҗалыгы – ил икътисадында алдынгы тармакларның берсе, анда инновацион фәнни эшләнмәләр һәм заманча җитештерү чаралары киң кулланыла, прогрессив цифрлы карарлар гамәлгә кертелә. Татарстан һәрвакыт бу процессларны үстерү лидерлары арасында булды. Татарстан Республикасы бүген дә агросәнәгать комплексының нәтиҗәлелеген күтәрү, авыл хуҗалыгы предприятиеләренең матди-техник базасын яңарту һәм камилләштерү, заманча яңа инвестицион проектларны гамәлгә ашыру, җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сату мөмкинлекләрен киңәйтү, авыл кешеләренең эш шартларын яхшырту буенча җитди бурычлар куя.

Төбәк аграрийларына югары һөнәри осталыклары, үз эшләренә бирелгәнлекләре һәм һәрвакыт нәтиҗәгә ирешә белүләре өчен тирән рәхмәтемне белдерәсем килә. Сезнең тәҗрибәгез һәм максатчанлыгыгыз – Татарстан авыл хуҗалыгының йөзьеллык традицияләрен һәм җиребез байлыгын саклап калырга һәм арттырырга тиешле үсеп килүче буын өчен менә дигән үрнәк.

Дмитрий Николаевич Патрушев
Россия Федерациясе
Авыл хуҗалыгы министры

«Труд есть отец богатства, земля – его мать»

В первом томе «Капитала» Карл Маркс не случайно привел это известное и актуальное на все времена изречение. И вправду, все самое важное в жизни так или иначе связано с землей. Это подтверждает история всех народов.

У татарского народа живы тысячелетние земледельческие традиции. В нашей многовековой истории были разные события, но наш трудолюбивый народ, независимо от разных, порой даже противоположных веяний времен, не терял связи со своей землей. Крестьянина часто ругали за консерватизм: почему так крепко держится за свой уклад? Потому что далеко не все в сельском хозяйстве зависит только от человека и его кропотливой деятельности. Россия – страна рискованного земледелия; скажем, нет долгожданного снега или дождя – землепашец всегда с надеждой смотрит на небо и молится Всевышнему, потому что от погоды зависит урожай, а значит, и судьба его самого и его семьи.

Благодаря исконным традициям, улучшению технической оснащенности, росту мастерства земледельцев в настоящее время нам удается выращивать высокие урожаи. Сегодня сельское хозяйство Татарстана занимает одно из ведущих мест в Российской Федерации.

Работа на земле – одна из древнейших и самых благородных профессий, которой люди занимаются во все времена. И нет у меня сомнений, что сельский бизнес, как называется теперь крестьянское дело, станет еще более востребованным. А сам человек сельского труда и впредь будет у нас уважаемым и по достоинству оцененным.

Весьма символично, что в 2010 году в самом центре нашей столицы – Казани, у подножия Кремля, как дань уважения труду наших сельчан, был возведен Дворец земледельцев, где разместилось Министерство сельского хозяйства и продовольствия республики. Получился красивый дворец, где мощное Дерево жизни, украшающее фасад, символизирует природу, возделанную благородным трудом земледельцев.

100-летняя история Министерства сельского хозяйства республики складывалась из самоотверженного труда и судеб всех тружеников села, руководителей-организаторов, посвятивших себя этой нелегкой благородной работе на земле. И мы все перед ними в неоплатном долгу!

С глубоким уважением и пожеланиями благополучия и здоровья.

С низким поклоном перед вашим трудом,

Минтимер Шарипович Шаймиев,
первый Президент Республики Татарстан,
Государственный советник
Республики Татарстан,
Герой Труда Российской Федерации

«Хезмәт – байлыкның атасы, ә җир – анасы»

Әлеге мәгълүм һәм һәрвакыт көнүзәк гыйбарәне Карл Маркс “Капитал” китабының беренче томына юкка гына кертмәгән. Чынлап та, тормыштагы барлык иң мөһим нәрсәләр җиргә бәйле. Моны бөтен халыкларның да тарихы раслап тора.

Татар халкында игенчелекнең меңьеллык традицияләре яшәп килә. Күп гасырлык тарихыбызда төрле вакыйгалар булган, әмма безнең хезмәт сөючән халкыбыз, заманаларның төрле-төрле, кайчак капма-каршы искән җилләренә бирешмичә, үз җире белән элемтәсен югалтмаган. Крестьян халкын еш кына иске карашлы булуда гаепләгәннәр: ни өчен үзгәрми, һаман үз тормыш тәртибенә ябышып ята? Чөнки авыл хуҗалыгында барысы да кешедән генә, аның тырыш хезмәтеннән генә тормый. Россиядә игенчелек хәвефле, әйтик, күптән көтелгән кар яки яңгыр яумаска мөмкин, җир игүче һәрвакыт өмет белән күккә төбәлеп, Ходайга дога юллый, чөнки уңыш, димәк үзенең һәм гаиләсенең язмышы да һава торышына бәйле.

Хәзерге вакытта борынгы традицияләрне саклау, техника җиһазларын яхшырту, игенчеләр осталыгын үстерү нәтиҗәсендә без мул уңыш алуга ирешеп киләбез. Бүген Татарстанның авыл хуҗалыгы Россия Федерациясе буенча алдынгы урында бара.

Игенчелек - иң борынгы һәм иң затлы һөнәрләрнең берсе, кешеләр моның белән барлык заманнарда да шөгыльләнәләр. Һич шигем юк: хәзер авыл хуҗалыгы эшмәкәрлеге дип аталучы крестьян эшчәнлегенә ихтыяҗ тагын да артачак. Ә бездә алга таба да игенчеләргә кадер-хөрмәт күрсәтеләчәк, эшләренә лаеклы бәя биреләчәк.

2010 елда башкалабыз Казан үзәгендә, Кремль янында авыл хезмәтчәннәренә хөрмәт йөзеннән Игенчеләр сарае төзелү символик мәгънәгә ия. Анда республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы урнашкан. Сарай бик матур эшләнде, аның алгы ягын бизәүче Яшәеш агачы игенченең затлы хезмәте куелган табигатьне чагылдыра.

Республика Авыл хуҗалыгы министрлыгының 100 еллык тарихы гомерен җир игүгә багышлаган барлык авыл хезмәтчәннәренең, җитәкче-оештыручыларның фидакарь хезмәтеннән һәм язмышыннан гыйбарәт. Алар алдында без барыбыз да бурычлы!

Тирән ихтирам белән, сәламәтлек һәм бәрәкәтле тормыш теләп,

Хезмәтегез алдында баш иеп,

Минтимер Шәрип улы Шәймиев,
Татарстан Республикасының Беренче Президенты,
Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе,
Россия Федерациясенең Хезмәт Герое

Эта книга – первая в своем роде попытка обобщить вековую историю сельского хозяйства Татарстана, которая неразрывно связана с историей республики, 100-летний юбилей которой мы отмечаем в этом году.

Книга посвящается людям, которые ценой неимоверных усилий выполняли и выполняют очень важную и ответственную миссию – обеспечение продовольственной безопасности населения республики.

Непростые периоды пришлось пережить нашим аграриям – полные трудностей и лишений в годы войны, связанные с экономическими кризисами, перестройками и реформами. Тем не менее руководству республики всегда удавалось добиваться, чтобы земля Татарстана засевалась даже в самые тяжелые годы и приносила урожай.

Очень важно, чтобы память о первых героических руководителях Народного комиссариата земледелия Татарской республики, о самоотверженных председателях колхозов, о мужественных женщинах, на чьи плечи легли самые тяжелые работы в сельском хозяйстве в военное лихолетье, – была сохранена. Это является для нас примером безграничной любви к своей земле и ответственного отношения к своему делу.

Далеко не все герои нашего невидимого фронта попали на страницы этого издания. Это и понятно, ведь их было очень много за столетнюю историю. Главная задача книги – подтолкнуть читателя к раздумьям о том, как важно знание прошлого для понимания настоящего и будущего развития аграрного сектора Татарстана. Полагаем, что в этом издании можно найти много интересной и полезной информации, которая будет бережно храниться и передаваться из поколения в поколение как документальное свидетельство нашей национальной чести и гордости.

С уважением,
Марат Азатович Зяббаров,
заместитель Премьер-министра
Республики Татарстан,
министр сельского хозяйства и продовольствия
Республики Татарстан

Әлеге китап – Татарстан авыл хуҗалыгының быел 100 еллык юбилеен билгеләп үтүче республика тарихыннан аерылгысыз бер гасырлык тарихи юлын гомумиләштерү омтылышы.

Басма чиктән тыш тырышлыклар бәрабәренә гаять мөһим һәм җаваплы миссияне башкаручыларга – республика халкының азык-төлек иминлеген тәэмин итүче кешеләргә багышлана.

Крестьяннарга төрле чорларны – югалтулар белән бәйле фаҗигале, өметләр тулы шатлыклы заманнарны да кичерергә туры килде. Төбәкләрдә авыл һәм авыл хуҗалыгы еш кына ашыгыч сәяси карарлар, уйланылмаган реформалар объектына әверелде. Шуңа да карамастан, республика җитәкчелеге иң авыр елларда да Татарстан җирләренең чәчелүенә һәм уңыш алуга һәрдаим ирешә килде.

Татарстан республикасы Җир эшләре халык комиссариатының беренче каһарман җитәкчеләре, фидакарь колхоз рәисләре, сугыш елларында авыл хуҗалыгында иң авыр хезмәтләрне үз иңнәрендә күтәргән батыр хатын-кызлар хакындагы истәлекләрне хәтердә саклау бик мөһим. Бу безнең өчен туган җиребезгә чиксез мәхәббәт һәм һәр эшкә җаваплы мөнәсәбәт үрнәге булып тора.

Күзгә күренмәгән фронтның барлык каһарманнары да әлеге басма битләрендә урын алмавы табигый, чөнки алар йөз еллык тарихта бик күп иделәр бит. Китапның төп бурычы – укучыны Татарстанның аграр секторының бүгенгесен һәм киләчәген аңлау юлында аның үткәнен белүнең әһәмияте турында уйлануларга юнәлтү. Бу басмада милли намусыбызның һәм горурлыгыбызның документаль дәлиле буларак кадерләп сакланачак һәм буыннан-буынга тапшырылачак бик күп кызыклы һәм файдалы мәгълүмат табып булыр дигән фикердә калабыз.

Ихтирам белән,
Марат Азат улы Җәббаров,
Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары,
Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

1920 – 1940 гг.

Икътисадны торгызуда локоматив буларак авыл хуҗалыгы

ГЛАВА 1

Сельское хозяйство

как локомотив в восстановлении экономики

НАРКОМЗЕМЫ – НАРОДНЫЕ КОМИССАРЫ ЗЕМЛЕДЕЛИЯ

Валидов Юнус Нуриманович – работал с апреля 1920 по1923 г.
Родился в деревне Балтачево Салаушской волости Елабужского кантона. Трудился батраком у местных баев. На должность наркома пришел после поста начальника политотдела Центральной мусульманской военной коллегии. Частые командировки, тяжелый труд, необустроенность быта подорвали здоровье Ю.Н. Валидова. Он скончался в 1925 г. в возрасте 36 лет.

Амиров Исхак Гаязетдинович – работал в декабре 1924 г.
Родился в 1883 г. в крестьянской семье. По образованию учитель. Наркомом был избран на первой сессии ЦИК ТАССР, в январе 1924 г. избрали членом экономического совета, в мае – членом Сельскохозяйственной налоговой комиссии.

Якубов Юсупхан Якубович – работал с июня1924 по 1926 г.
Родился в одном из селений Челнинского кантона в крестьянской семье. В молодости работал чернорабочим на железной дороге. В 1920–1923 гг. работал заведующим земельным отделом, затем председателем Свияжского кантисполкома. Будучи наркомом земледелия входил в малый Совнарком.

Ахметшин Миннегарей Ахметович – работал в 1926–1927 гг.
Родился в 1989 г. в деревне Биклян Мензелинского уезда в семье бедного крестьянина. Сражался против Колчака. С 1919 по 1921 г. – председатель Мензелинского исполкома, затем народный комиссар внутренних дел республики. Наркомом земледелия работал недолго, но успел выдвинуть ряд смелых идей, направленных на борьбу с засухой, на развитие государственных товарных ферм, коневодства. При нем была организована первая в истории Татарии Всетатарская сельскохозяйственная выставка. В 1927 г. его перевели в председатели областной партийно-контрольной комиссии, затем в наркомы рабоче-крестьянской инспекции, а в ноябре 1927 г. он стал председателем ЦИК ТАССР.

Петров Николай Васильевич – работал в 1927–1929 гг.
В 1929 г. по его предложению VIII Всетатарский съезд Советов принял специальное постановление «О восстановлении и реконструкции сельского хозяйства Татарской Советской Социалистической Республики». Николай Васильевич работал над организацией в республике производства фосфорных и азотных удобрений. Впервые была поставлена задача переустройства отсталой зерновой системы в зерново-животноводческую с постепенным повышением роли и масштабов развития животноводства.

Искандеров Габдрахман Искандерович – работал в 1929–1937 гг.
Родился в 1898 г. в деревне Малая Рясь нынешнего Высокогорского района в семье крестьянина. В юности служил в Казани у помещиков. В 1917 г. работал в системе НКВД. В 1923 –1928 гг. – председатель исполкома Арского, затем Мамадышского и Кукморского кантонов, секретарь Буинского кантонского комитета ВКП(б). Деятельность в качестве наркома земледелия Татарии пришлась на годы развернутого колхозного строительства, поэтому его по праву называли наркомом колхозов. При нем в 1934 г. республика награждена орденом Ленина.
20 августа 1937 г. Г.И. Искандеров был арестован НКВД ТАССР. Обвинение – участие в антисоветской националистической пантюркистской организации, руководство правотроцкистским-национальным блоком, действовавшим на территории ТАССР. Расстрелян 9 мая 1938 г.

Абсалямов Шафик Гафиятуллович – работал в 1937–1938 гг.
Проработал всего несколько месяцев, переведен в Москву.

Черзор Прокопий Петрович – работал в 1939–1940 гг.
Родился в 1899 г. в селе Шигалей Урмарского района Чувашской АССР. Окончил Высшую колхозную школу при Колхозцентре СССР. С 1931 по 1938 г. работал председателем правления «Татмясомолколхозсоюз», секретарем Аксубаевского, Буденовского и Казанского районных комитетов ВКП(б). С поста наркома земледелия ушел в связи с назначением его наркомом, а затем министром мясной и молочной промышленности ТАССР.

НАРКОМЗЕМНАР – ҖИР ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ

Вәлидов Юныс Нуриман улы – 1920 елның апреле –1923 елларда эшләде.

Алабуга кантоны Салагыш волосте Балтач авылында туа. Җирле байларда батрак булып эшли. Халык комиссары вазифасына Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәясәт бүлеге башлыгы вазифасыннан соң килә. Еш командировкалар, авыр хезмәт, көнкүрешенең төзек булмавы Ю.Н.Вәлидовның сәламәтлеген какшата. Ул 1925 елда 36 яшендә вафат була.

Әмиров Исхак Гаязетдин улы – 1924 елның декабрендә эшләде.

1883 елда крестьян гаиләсендә туа. Белеме буенча укытучы. Халык комиссары итеп ТАССР ҮБКның беренче сессиясендә сайлана, 1924 елның гыйнварында икътисади совет әгъзасы, май аенда Авыл хуҗалыгы салым комиссиясе әгъзасы итеп сайлана.

Якубов Йосыфхан Якуб улы – 1924 елның июне –1926 елларда эшләде.

Чаллы кантоны авылларының берсендә крестьян гаиләсендә туа. Яшь чагында тимер юлда кара эшче булып эшли. 1920 – 1923 елларда Зөя кантоны башкарма комитетының җир бүлеге мөдире, аннан соң рәисе булып эшли. Җир эшләре халык комиссары буларак, Кече Совнаркомга керә.

Әхмәтшин Миңнегәрәй Әхмәт улы – әлеге вазифаны 1926–1927 елларда башкара.

Родился в 1989 году в деревне Биклян Мензелинского уезда в семье бедного крестьянина. Сражался против Колчака. С 1919 по 1921 год – председатель Мензелинского исполкома, затем Народный комиссар внутренних дел республики. Наркомом земледелия работал недолго, но успел выдвинуть ряд смелых идей, направленных на борьбу с засухой, на развитие государственных товарных ферм, коневодства. При нем была организована первая в истории Татарии Всетатарская сельскохозяйственная выставка. В 1927 году его перевели в председатели областной партийно-контрольной комиссии, затем в Наркомы рабоче-крестьянской инспекции, а в ноябре 1927 года он стал председателем ЦИК ТАССР.

Петров Николай Васильевич – 1927–1929 елларда эшли.

1929 елда аның тәкъдиме белән Советларның VIII Бөтентатар съезды «Татарстан Совет Социалистик Республикасының авыл хуҗалыгын торгызу һәм реконструкцияләү турында» махсус карар кабул итә. Ул республикада фосфорлы һәм азотлы ашламалар җитештерүне оештыру өстендә эшләде. Беренче тапкыр, терлекчелекнең ролен һәм үсеш масштабларын акрынлап арттыра барып, артта калган игенчелек системасын игенчелек-терлекчелек системасына үзгәртеп кору бурычы куела.

Искәндәров Габдрахман Идрис улы – 1929–1937 елларда эшли.

1898 елда хәзерге Биектау районының Кече Рәс авылында крестьян гаиләсендә туа. Яшь чагында Казанда алпавытларда хезмәт итә. 1917 елда НКВД системасында эшли. 1923 – 1928 елларда – Арча, аннары Мамадыш һәм Кукмара кантоннары башкарма комитеты рәисе, ВКП(б)ның Буа кантон комитеты секретаре. Татарстанның җир эшләре халык комиссары буларак эшчәнлеге киң җәелдерелгән колхоз төзелеше елларына туры килә, шуңа күрә аны хаклы рәвештә колхоз халык комиссары дип атыйлар. Ул эшләгән чорда 1934 елда республика Ленин ордены белән бүләкләнә.

1937 елның 20 августында Искәндәров ТАССР НКВДсы тарафыннан кулга алына. Советларга каршы милли пантөркичеләр оешмасында катнашу, ТАССР территориясендә эшләгән уң троцкийчылар милли блогы белән җитәкчелек итүдә гаепләнә. 1938 елның 9 маенда атып үтерелә.

Әпсәләмов Шәфикъ Гафиятулла улы – 1937–1938 елларда эшли.

Бары тик берничә ай гына эшләп ала, Мәскәүгә күчерелә.

Черзор Прокопий Петрович – 1939–1940 елларда эшли.

1899 елда Чуваш АССРның Урмар районы Шыгали авылында туа. СССР Колхоз үзәге каршындагы Югары колхоз мәктәбен тәмамлый. 1931–1938 елларда «Татмясомолколхозсоюз» идарәсе рәисе, ВКП(б) ның Аксубай, Буденный һәм Казан район комитетлары секретаре булып эшли. Җир эшләре халык комиссары вазифасыннан аны ТАССР ит һәм сөт сәнәгате халык комиссары, ә аннары министры итеп билгеләп куюга бәйле рәвештә китә.

1920 год – год исторических испытаний для молодой Татарской республики. Чтобы понять всю сложность общественно-политической и экономической обстановки, в которой начинала свое существование республика, и охарактеризовать трудности и драматические противоречия в развитии деревни и сельского хозяйства в этот период, достаточно назвать три слова – разруха, голод, НЭП. Политические потрясения и военное лихолетье довели крестьян до крайнего состояния нищеты и, казалось, отодвинули на необозримое будущее вековую мечту народа о земле. Между тем в этих непростых условиях советская власть отводит именно сельскому хозяйству роль локомотива в восстановлении экономики.

26–27 сентября 1920 г. состоялся I съезд Советов рабочих, крестьянских и красноармейских депутатов ТАССР. В принятой на съезде резолюции подчеркивалось, что правильное экономическое развитие ТАССР может быть обеспечено лишь при условии полной централизации продовольственного дела на всей территории РСФСР, что выполнение продразверсток является обязанностью каждого крестьянина. Пятый пункт резолюции гласил: «Съезд считает, что ответственность за выполнение разверсток

1920 ел – яшь Татарстан республикасы өчен тарихи сынаулар елы. Республика тормышының башлангыч чорларындагы иҗтимагый-сәяси һәм икътисади кыенлыкларны аңлау, авыл һәм авыл хуҗалыгы үсешендәге авырлыкларны һәм драматик каршылыкларны тасвирлау өчен өч сүз дә җитә – җимереклек, ачлык, нэп (яңа икътисади сәясәт).

Сәяси тетрәнүләр һәм сугыш китергән кыенлыклар крестьяннарны хәерчелекнең соңгы чигенә китереп җиткерде һәм халыкның җир турындагы күпгасырлык хыялларын күз күреме җитмәс ерак киләчәккә күчерде. Асылда исә әлеге катлаулы шартларда совет хакимияте икътисадны торгызуда локоматив ролен нәкъ менә авыл хуҗалыгына йөкләде.

1920 елның 26-27 сентябрендә ТАССР Эшче, крестьян һәм кызылармияче депутатлары Советларының беренче съезды булып уза. Съездда кабул ителгән резолюциядә ТАССРның дөрес икътисади үсеше РСФСРның бөтен территориясендә азык-төлек эшләрен тулы үзәкләштерү шартларында гына тәэмин ителә алуы, продразверстканы үтәүнең һәрбер крестьянның бурычы булып торуы ассызыклана.

Резолюциянең бишенче пунктында: «Съезд разверсткаларны үтәү өчен җаваплылык ту-


Министерство сельского хозяйства РСФСР
Министерство сельского хозяйства ТАССР
ИСТОРИЧЕСКАЯ СПРАВКА
14.03.75
К фонду Министерства сельского хозяйства ТАССР

№ 155

ДЕКРЕТ ВСЕРОССИЙСКОГО ЦЕНТРАЛЬНОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА СОВЕТОВ

ОБ АВТОНОМНОЙ ТАТАРСКОЙ СОЦИАЛИСТИЧЕСКОЙ СОВЕТСКОЙ РЕСПУБЛИКЕ

27 мая 1920 г.

Всероссийский Центральный Исполнительный Комитет и Совет Народных Комиссаров постановляют:

I

1. Образовать Автономную Татарскую Социалистическую Советскую Республику как часть Российской Социалистической Федеративной Советской Республики и в состав ее включить:

а) из Казанской губернии: уезды Казанский, Лаишевский, Мамадышский, Свияжский, Чистопольский, Тетюшский и Спасский, за исключением волостей Жилинской и Юрткульской, и волости Елабужского уезда — Черкасовская и Салаушская и Краснококшайского уезда — Кулле-Киминская и Кшкловская;

б) из Уфимской губернии: Мензелинский уезд;

в) из Самарской губернии: волости Бугульминского уезда — Азнакаевская, Александровская, Альькеевская, Альметьевская, Бавлинская, Богоявленская, Варваринская, Верхне-Кармальская, Каратаевская, Кузайкинская, Ивановская, Масягутовская, Микулинская, Мордовско-Афонькинская, Мордовско-Ивановская, Мордовско-Кармальская, Нижне-Чершелинская, Ново-Письмянская, Салиховская, Спасская, Спиридоновская, Стерлитамакская, Сумароковская, Тумутукская, Урсалинская и Чекановская;

г) из Вятской губернии: волости Малмыжского уезда — Кошкинская, Нослинская, Арборская, Янгуловская, Сардыбашская, Нижне-Четаевская и Шудинская;

д) из Симбирской губернии: волости Симбирского уезда — Скиндяковская, Б.-Тархановская и Б.-Цильнинская; волости Буинского уезда — Старо-Студенецкая, Энтугановская, Шихирданская, Ново-Камерлинская, Дрожжановская, Мочалеевская, Бурундуковская, Рунгинская, Тимбаевская, Убеевская и Городищенская.

Примечание. Вопрос о включении в состав Татарской Социалистической Советской Республики Белебеевского и Бирского уездов Уфимской губернии оставить открытым впредь до волеизъявления трудящегося населения этих уездов.

возлагается на крестьянское общество в целом, и поэтому несдача продуктов по разверстке одним его членом пополняется запасами всего общества». Также обозначаются пути повышения производительности труда земледельцев и животноводов на основе налаживания помощи государства агротехникой, инвентарем.

Вот как описывает этот период в своей автобиографии первый нарком земледелия Татарской АССР Юнус Нариманович Валидов – человек, сыгравший огромную роль в государственной организации аграрного хозяйства в Татарии: *«На этом посту пришлось работать (при малой подготовке и новизне этого поприща для меня) не покладая рук. Работа осложнялась тем, что саботировали не только специалисты, которые вообще были везде (в то время) и повсюду старались ставить рогатки в работу госаппарата, но и большая часть товарищей русских коммунистов, не успевших освоить политику нашей партии в условиях национальных республик…»*.

Для объективности и полноты картины прокрутим маховик истории к началу XX в., когда Казанская губерния была одним из крупных российских производителей и поставщиков сельскохозяйственной продукции. Отсюда еже-

лаем крестьян җәмәгатенә йөкләнә һәм разверстка буенча продуктны аның бер әгъзасы тапшырмау бөтен җәмәгать запаслары белән тутырыла, дип саный», – диелә. Шулай ук агротехника, инвентарь белән дәүләт ярдәмен җайга салу нигезендә игенчеләрнең һәм терлекчеләрнең хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү юллары билгеләнә.

Әлеге чорны Татарстанда аграр хуҗалыкны дәүләт оештыруына зур өлеш керткән зат – Татарстан АССРның беренче җир эшләре халык комиссары Юныс Нуриман улы Вәлидов үзенең автобиографиясендә менә ничек тасвирлый:

«Әзерлекнең җитәрлек булмавына һәм бу өлкәнең минем өчен яңа булуына карамастан, әлеге вазифаны бик җентекләп башкарырга туры килде. Эшне оештыру ул чагында гомумән һәркайда хөкем сөргән һәм һәр җирдә дәүләт аппараты эшчәнлегенә таяк тыгарга тырышкан белгечләрнең генә түгел, бәлки милли республикалар шартларында безнең партия сәясәтен үзләштерергә өлгермәгән рус коммунист иптәшләрнең күп өлеше корткычлык кылуы аркасында да катлауланды... ».

Мәсьәләне объектив һәм тулырак күз алдына китерү өчен тарих тәгәрмәчен XX гасыр башына,

Габдулла Тукай
сүзләре,
Татар халык көе

Ишеттем мин кичә: берәү
җырлый, Чын безнеңчә матур,
милли көй;
Әллүки, бәллүки, Чын безнеңчә
матур, милли көй.

ПОЭЗИЯ

годно поставлялось в другие регионы России и за границу 15–20 млн пудов хлеба. Первая мировая война, революция, интервенция Антанты, Гражданская война – события, которые привели село и всю экономику страны к серьезному экономическому упадку. В 7 раз сократилось промышленное производство, почти на 40% – сельскохозяйственное, что не могло не сказаться на продовольственном вопросе. Особенно тяжело было на территориях, где имели место военные действия. В их числе – Казанская губерния, которую потрясли ожесточенные сражения Красной армии с частями Комуча (Комитета Учредительного собрания), Чехословацкого корпуса, войсками Колчака.

К 1914 г. большая часть населения губернии проживала в сельской местности и составляла 2 млн 565 тыс. человек из 2 млн 850 тыс. человек общего населения губернии. Под влиянием развивающихся капиталистических отношений усиливается прослойка сельской буржуазии, и в то же время увеличивается удельный вес обедневших, безлошадных крестьянских хозяйств. Особенно быстро растет число безлошадных дворов у татарских крестьян, на одну треть состоявших из батраков и поденщиков. У основной массы крестьян надел на двор не превышал 8 десятин, у значительной части был

Казан губернасы Россиядә авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүче һәм аның белән тәэмин итүче зур төбәкләрнең берсе булган чорга таба әйләндерик. Бирелән ел саен Россиянең башка төбәкләренә һәм чит илләргә 15-20 млн пот икмәк җибәрелә. Беренче бөтендөнья сугышы, революция, Антанта интервенциясе, Гражданнар сугышы – авылны һәм бөтен ил икътисадын җитди икътисади түбәнлеккә төшергән вакыйгалар. Сәнәгать җитештерүе җиде тапкыр, авыл хуҗалыгы җитештерүе 40 % ка диярлек кыскара, бу исә азык-төлек мәсьәләсендә дә чагылмый калмый. Сугыш хәрәкәтләре булган территорияләрдә аеруча авыр була. Кызыл Армиянең Комуч (Учредительләр җыены комитеты) частьлары, чех-словак корпусы, Колчак гаскәрләре белән кызу сугышлар барган Казан губернасы да алар арасында.

1914 елга губерна халкының күп өлеше авыл җирлегендә яши һәм губернада яшәүче 2 миллион 850 мең кешенең 2 миллион 565 меңен тәшкил итә. Үсә баручы капиталистик мөнәсәбәтләр йогынтысында авыл буржуазиясе катламы көчәя һәм шул ук вакытта бөлгенлеккә төшкән, атсыз крестьян хуҗалыкларының саны да арта бара. Өчтән бер өлеше батраклар һәм көнлекчеләрдән торган татар крестьяннарының атсыз хуҗалыклары саны аеруча тиз күбәя. Төп

еще меньше – всего 1,5–2 десятины. Но были и другие проблемы. Земледелие в основном велось при помощи примитивных орудий – это соха, плуг, коса, серп и цеп. А почти 40% крестьянских хозяйств не имели вообще никакого сельскохозяйственного инвентаря.

Политика «военного коммунизма», проводившаяся Советским государством в условиях Гражданской войны, обернулась для крестьян настоящим ограблением. Продотряды вывезли из Татарии 10 млн пудов хлеба. В какой-то момент оказалось некому обрабатывать землю – почти все взрослое мужское население было мобилизовано в Красную армию. Скот шел под нож, царили бедность и нищета.

«Мы голодаем, на наших руках умирают дети, умирают старики, умирает молодежь», – писали жители Челнинского кантона в Москву В.И. Ленину в надежде получить хоть какую-то помощь.

О голоде начала 20-х годов как всенародной трагедии, унесшей тысячи жизней в Среднем Поволжье, написано немало и научной, и художественной литературы. Советские историки официальной причиной бедствия называли двухлетнюю засуху 1920–1921 гг. Часто приводилась цитата В.И. Ленина, что, начиная от Астраханской губернии и кончая Татарской

крестьян массаларының хуҗалыкка туры килгән имана җирләре 8 дисәтинәдән артмый, шактый зур өлешенеке тагын да азрак – бары 1,5-2 дисәтинә тәшкил итә. Игенчелектә нигездә примитив хезмәт кораллары – сука, сабан, чалгы, урак һәм чылбыр кулланыла. 40 % диярлек крестьян хуҗалыкларында исә бернинди авыл хуҗалыгы кораллары да булмый.

Гражданнар сугышы шартларында Совет дәүләте тарафыннан уздырылган «хәрби коммунизм» сәясәте крестьяннар өчен чын-чынлап талауга әйләнә. Продотрядлар Татарстаннан 10 миллион пот икмәк алып чыгып китә. Кайсыдыр бер вакытта җирне эшкәртергә дә кеше калмый – өлкән яшьтәге барлык ир-атлар диярлек Кызыл Армиягә мобилизацияләнә. Терлекләрне суялар, кытлык һәм хәерчелек хөкем сөрә.

Нинди дә булса ярдәм алуга өметләнеп, Чаллы кантоны халкы: «Без ачлыктан интегәбез, безнең кулларыбызда балалар үлә, картлар үлә, яшьләр үлә», – дип, Мәскәүгә В.И.Ленинга яза.

20 нче еллар башындагы ачлык турында, Урта Идел буенда меңнәрчә гомерләрне өзгән бөтенхалык фаҗигасе буларак, фәнни һәм матур әдәбиятта шактый язылды. Совет тарихчылары фаҗиганең рәсми сәбәбе итеп 1920-1921 еллардагы ике еллык корылыкны

Беженцы, бежавшие от голода, 1920-е годы

Урожай, 1920-е годы

республикой и Пермской губернией, всюду засуха выжгла почти окончательно и хлеб, и траву: «Миллионы людей – трудовых крестьян и рабочих, миллионы голов скота готовы погибнуть и гибнут уже. Беда так велика…».

Постсоветские исследователи наряду с неурожайностью 1921 и 1922 гг. называют и другие причины – например, негативное отношение большинства крестьян Среднего Поволжья к приходу большевиков к власти, поэтому введение продразвестки было здесь встречено как крайний акт несправедливости. И начиная с 1919 г. крестьяне активно поедают и тратят весь полученный урожай, дабы он не достался кому другому. Вот как описывали этот период очевидцы: «…Старались есть как можно более, не считаясь с тем, что впоследствии придется голодать, хлеб не жалели и часто добавляли в корм скоту. Хлеб прятали, он гнил или поедался мышами. Лишний пуд старались сбыть спекулянту. В результате с наступлением весны семенного овса у весьма значительной части населения нет, земля останется незасеянной. Само же население к весне осталось уже почти без хлеба и голодает».

В апреле 1921 г. советское правительство

күрсәтәләр. Еш кына В.И. Ленинның Әстерхан губернасыннан башлап, Татарстан республикасы һәм Пермь губернасына кадәр бөтен җирдә корылыкның тулысынча диярлек икмәкләрне һәм үләннәрне көйдерүе хакындагы өземтәсен китерәләр: «Миллионлаган кеше – хезмәт крестьяннары һәм эшчеләр, миллионлаган баш терлек һәлак булу хәлендә һәм инде һәлакәткә дучар. Бәла шундый зур…».

Советлардан соңгы чор тикшеренүчеләре, 1921 һәм 1922 еллар уңдырышсызлыгы белән беррәттән, башка сәбәпләрне дә атыйлар – әйтик, Урта Идел буе крестьяннарының күпчелегенең хакимияткә большевиклар килүгә тискәре мөнәсәбәте, шуңа күрә продразверстка кертү биредә гаделсезлекнең соңгы чиге буларак кабул ителә. Һәм 1919 елдан башлап крестьяннар җыеп алынган бөтен уңышны башкаларга эләкмәсен өчен актив рәвештә сарыф итәләр. Әлеге чорны шаһитлар менә ничек тасвирлыйлар: «… мөмкин кадәр күбрәк ашап калырга тырыштылар, соңыннан ач торырга туры киләчәге белән исәплəшмәделәр, икмәкне кызганмадылар һәм еш кына терлекләргә ашаттылар. Икмәкне яшерделәр, ул череде яки тычканнарга азык булды. Артык потны спекулянтка

Зерноочистительных МАШИН	ПЛУГОВ	БОРОН	СЕЯЛОК	МОЛОТИЛОК
завезено в республику	завезено в республику	завезено в республику	завезено в республику	завезено в республику
3005	70069	74916	461	1437
1924-1926 год	1924-1926 год	1924-1926 год	1924-1926 год	1924-1926 год

принимает Постановление «О борьбе с засухой». Создается Центральная комиссия помощи голодающим при ВЦИК (Помгол). В конце июля 1921 г. в Татарии начинает работу аналогичная комиссия, в ее составе – нарком земледелия Ю. Валидов.

Масштабы голода в Татарии потрясают: зарегистрировано 741 768 голодающих. Во многих селах не осталось ни кошек, ни собак. Участились случаи трупо- и людоедства. Жители Поволжья спасались от голода лепешками из лебеды, пуд муки из которой на рынках Казани стоил 122 тыс. руб. Общие людские потери составили, по разным оценкам, 400–500 тыс. человек.

Бегство, начавшись с отдельных людей, охватывало целые деревни и села. По рассказу крестьянина из деревни Клянчеево Тетюшского кантона А. Абдулсатгарова, в начале лета 1921 г. жители этой деревни, распродав все имущество и скот, уехали искать благополучные места. Одни – в Среднюю Азию, другие – в Сибирь, где, по рассказам, уродился хлеб, но планировали вернуться в родные места к весеннему севу. К 1922 г. из пятисот хозяйств в Клянчеево осталось только сто.

С 10 мая по 5 июля 1921 г. Татарский союз потребительских обществ направляет в наиболее урожайные губернии 933 человека с мандатами для покупки хлеба. С 6 июля началась организация волостных троек через многолавки для заготовки семян в «сытых губерниях». Татсоюз проводил так называемый голодный товарообмен и общественное питание голодающих. В 1922 г. через Татсоюз кормилось 144–400 человек.

В распоряжение Помгола при ТатЦИКе на 1 сентября 1921 г. поступило добровольных пожертвований: деньгами 19,8 млн руб., 180 пудов хлеба, 33 пуда соли, 55 пудов разных круп и гороха, 36 пудов рыбы, 90 пудов овсяной муки, 198 пудов пшеничной муки. В сентябре 1922 г. за счет присланных продуктов в Татарии питалось 150 тыс. детей, которые, кстати, были самой уязвимой частью голодающего населения – в период голода их умерло в республике

сатарга тырыштылар. Нәтиҗәдә, язга чыкканда халыкның шактый өлешенең орлыкка дигән солысы юк, җир чәчелми калачак. Халык үзе исә язга икмәксез диярлек калды һәм ачка интегә».

1921 елның апрелендә Совет хөкүмәте «Корылыкка каршы көрәш турында» карар кабул итә. Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты каршында ачлыктан интегүчеләргә ярдәм итү буенча Үзәк комиссия (Помгол) төзелә. 1921 елның июль ахырында Татарстанда шундый ук комиссия эшли башлый, игенчелек халык комиссары Ю.Вәлидов та аның составына кертелә.

Татарстанда ачлык масштаблары шаккатыра: ачлыктан интегүче

741768 кеше теркәлгән. Күп авылларда песиләр дә, этләр дә калмаган. Үләксә һәм кеше ашаучылык очраклары ешайды. Идел буе халкы ачлыктан алабута көлчәләре белән котылып калган, Казан базарларында алабута онының бер поты 122 мең сум торган. Төрле бәяләүләр буенча, ачлыктан үлүчеләр саны 400-500 мең кеше тәшкил иткән.

Качып китүләр, аерым кешеләрдән башланып, бөтен бер авылларны колачлаган. Тәтеш кантонының Келәнче авылы крестьяны Ә. Габделсаттаров сөйләве буенча, 1921 елның җәе башында бу авылда яшәүчеләр, барлык мөлкәтләрен һәм терлекләрен сатып, муллык булган урыннар эзләп чыгып китә. Кайберәүләр – Урта Азиягә, икенчеләре, сөйләүләр буенча, икмәк уңган якка – Себергә юнәлә, әмма язгы чәчүгә туган якларына әйләнеп кайтырга ниятлиләр. 1922 елга Келәнче авылының биш йөз хуҗалыгыннан фәкать йөзе генә калган.

1921 елның 10 маеннан 5 июленә кадәр Татарстан кулланучылар җәмгыятьләре берлеге икмәк сатып алу өчен мандатлы 933 кешене иген уңган губерналарга җибәрә. 6 июльдән «тук губерналарда» күп лавкалы кооперативлар аша орлык әзерләү өчен волость өчлекләрен оештыру башлана. Татсоюз ачлар өчен товар алмашы һәм ачлыктан интегүчеләргә җәмәгать туклануы үткәрә. 1922 елда Татсоюз аша 144-400 кеше ризыклана.

1921 елның 1 сентябренә ТатҮБК каршындагы Помгол карамагына ярдәм рәвешендә 19,8

! НА ОСНОВАНИИ ПОСТАНОВЛЕНИЯ ВЦИК И СНК РСФСР ОТ 29 ИЮНЯ 1929 г. ДО КАЖДОГО КАНТОНА, РАЙОНА И СЕЛА БЫЛ СПУЩЕН ОБЯЗАТЕЛЬНЫЙ ПЛАН ПО ХЛЕБОСДАЧЕ

Сельское хозяйство ТАССР, 1930-е годы



Колхозник с призовым быком, 1930 – 1940 гг.

более 300 тыс. В городах в поисках пропитания буквально роились десятки малолетних оборванных беспризорников, бежавших от голода из деревень. Татарский писатель Ибрагим Гази так описывает это в своем романе «Хлеб, винтовка и любовь»: *«На пристанях полно голодных детей. Тех, кто пробирается тайком на пароход, матросы сгоняют. Но спастись от этой «саранчи» никак нельзя. С одного парохода сгонят – облепят другой…».*

Однако эти трагические обстоятельства не могли остановить ход истории. Вопреки всему весенняя посевная 1922 г. должна была состояться. И она проводилась в тяжелейших условиях, при нехватке лошадей, отсутствии хлеба у населения и корма у скота. Тем не менее благодаря огромным усилиям работников Наркомата земледелия и лично Ю. Валидова, а также благоприятным природным условиям крестьяне не только успешно засеялись, но и посадили огородные культуры. Осенью был собран неплохой урожай, но до полного выправления ситуации еще было очень далеко. Надежды возлагались на осеннюю посевную 1922 г. Озимыми в Татарии засеяли 760 тыс. десятин, по сравнению с 1921 г. это было вдвое больше.

В марте 1921 г. Х съезд РКП(б) провозглашает переход от политики «военного коммунизма» к новой экономической политике (НЭП). Первым актом НЭПа стал декрет ВЦИК от 21 марта 1921 г., заменивший продразверстку системой из 13 налогов в натуральной форме: продналог, подворно-денежный, трудгужналог, местные налоги. С 1923 г. налоги объединили в единый сельхозналог, выплачивавшийся сначала натурой и деньгами, а с 1924 г. – только

млн сум акча, 180 пот икмәк, 33 пот тоз, 55 пот төрле ярмалар һәм борчак, 36 пот балык, 90 пот солы оны, 198 пот бодай оны тапшырыла. 1922 елның сентябрендә Татарстанда ярдәм йөзеннән җибәрелгән продуктлар хисабына 150 мең бала туклана, алар ачлыктан интегүче халыкның иң якланмаган өлешен тәшкил итә – ачлык чорында республикада 300 меңнән артык бала үлә. Шәһәрләрдә азык эзләп авыллардагы ачлыктан качкан дистәләгән кечкенә сукбайлар кайнаша. Татар язучысы Ибраһим Гази моны үзенең «Икмәк, винтовка һәм мәхәббәт» романында болай сурәтли: *«Пристаньнар ач балалар белән тулы. Пароходка качып кына керeп утыручыларны матрослар куып төшерә. Тик бу «саранчадан» котылып булмый. Бер пароходтан куып төшерсәләр – икенчесенә барып ябышалар...».*

Әмма бу фаҗигале хәлләр тарих барышын туктата алмый. 1922 елгы язгы чәчү бернигә карамый башкарылырга тиеш иде. Ул атлар җитмәгән, халык икмәккә һәм терлекләр азыкка кытлык кичергән бик авыр шартларда үткәрелде. Шуңа да карамастан, Игенчелек халык комиссариаты хезмәткәрләре һәм шәхсән Ю. Вәлидовның тырышлыгы, табигать шартлары уңай килү аркасында, крестьяннар чәчүне уңышлы башкарып чыгу белән бергә, яшелчә культуралары да утырталар. Көз кенә яхшы гына уңыш җыеп алына, әмма эшләрне тулысынча җайлауга шактый ерак була әле. Өметләр 1922 елгы көзге чәчүгә баглана. Татарстанда уҗымнар 760 мең дисәтинә мәйданга чәчелә, 1921 ел белән чагыштырганда бу ике тапкырга күбрәк була.

1921 елның мартында РКП(б) ның Х съезды «хәрби коммунизм» сәясәтеннән яңа икътиса-

Отчего, соображай,
Здесь обильный урожай?
Нет другого мнения:
Дело в удобрении!
Минеральные
удобрения

Учеба работников сельского хозяйства, 1930-е годы

Работа спорится, 1930-е годы

деньгами. Выплачивался он по ставке 5% от дохода с каждого крестьянского двора, что позволяло крестьянам наладить свое хозяйство. К 10-й годовщине Октября 35% всех крестьянских хозяйств – бедняцких и маломощных – были вообще освобождены от сельхозналога. Крестьяне могли выйти из сельской общины и самостоятельно выбрать форму землепользования.

Осенью 1922 г. принимается Земельный кодекс, закрепляющий национализацию земли и предоставляющий большие права на землепользование. В 1925 г. в Татарии площадь посевов хлебов составляла 92,5% довоенной. Середняки составляли 58%, бедняки – 32,4%, зажиточные крестьяне (кулаки) – 7,6%. Коллективных хозяйств насчитывалось несколько сотен – это товарищества по совместной обработке земли, артели, коммуны, совхозы. Некоторые из них добивались значительных успехов: например, артели «Агрокультура» в Чистопольском кантоне, «Луч» в Челнинском, «Дружба» в Мензелинском, «Ярдам» в Тетюшском.

Еще одна примета этого времени – открытие в республике семи коммерческих банков и филиалов, в их числе – Татарская республиканская контора сельскохозяйственного банка, Казанское общество сельскохозяйственного кредита. Известно, что в 1923 – 1927 гг. крестьянству было выдано свыше 23 млн руб. сельскохозяйственного кредита. Однако эти кредиты были отпущены крестьянам банками под большие проценты: Всекобанк – 18%, Сельхозбанк – 15%. Имея краткосрочный характер, они были мало приспособлены к внутрихозяйственному обороту крестьянского хозяйства.

Кредитные и ссудосберегательные общества представляли кредитную кооперацию в деревне. А совсем маломощные хозяйства, состав-

ди сәясәткә (нэп) күчүне игълан итә. НЭПның беренче акты 1921 елның 21 мартындагы БҮБК декреты, ул продразверстканы натураль формадагы 13 салымнан торган система белән алмаштыра: азык-төлек салымы, йорт башыннан салына торган салым, хезмәткә һәм җигүле эш көченә салым, җирле салымнар. 1923 елдан салымнар баштарак натуралата һәм акчалата, ә 1924 елдан – бары тик акчалата гына түләнә торган бердәм авыл хуҗалыгы салымына берләштерелә. Ул һәр крестьян ихатасы керемене 5 % ы күләмендә түләнә, бу крестьяннарга үз хуҗалыкларын җайга салырга мөмкинлек бирә. Октябрьнең 10 еллыгына барлык крестьян хуҗалыкларының 35% ы – ярлылар һәм аз керемлеләр – авыл хуҗалыгы салымыннан бөтенләй азат ителә. Крестьяннар авыл җәмәгатеннән чыга һәм мөстәкыйль рәвештә җирдән файдалану формасын сайлый алалар.

1922 елның көзендә җирне национализацияләүне беркетүче һәм җирдән файдалануга зур хокуклар бирүче Җир кодексы кабул ителә. 1925 елда Татарстанда икмәк чәчү мәйданнары сугышка кадәрге мәйданның 92,5% ын тәшкил итә. Урта хәллеләр – 58%, ярлылар – 32,4% һәм таза тормышлы крестьяннар (кулаклар) – 7,6%. Күмәк хуҗалыклар берничә йөзләп исәпләнә – болар җирне бергәләп эшкәртү буенча ширкәтләр, артельләр, коммуналар, совхозлар. Аларның кайберләре, мәсәлән, Чистай кантонындагы «Агрокультура», Чаллыдагы – «Луч», Минзәләдәге «Дружба», Тәтеш кантонындагы «Ярдәм» артельләре зур гына уңышларга ирешә.

Бу чорның тагын бер билгесе – республикада җиде коммерцияле банк һәм филиал ачыла, Авыл хуҗалыгы банкының Татарстан республикасы конторасы, Казан авыл хуҗалыгы кредиты җәмгыяте дә шулар исәбендә. Мәгълүм

Сахарная свекла, 1930-е годы

Обед на полевых работах в колхозе, 1920-е годы

лявшие в Татарии пятую часть всех хозяйств, полностью освобождались от сельскохозяйственного налога. Чуть позже кооперативным производственным товариществам предоставлялись 10-процентные скидки, для артелей и сельскохозяйственных коммун – 25%.

Восстановление аграрного сектора Татарии шло, главным образом, по линии расширения посевов и увеличения поголовья скота. Валовая доходность сельского хозяйства республики вследствие низкой урожайности и слабых выходов в других отраслях находилась на крайне низком уровне по сравнению с другими российскими регионами. К тому же из-за неразвитости инфраструктуры деревни хлебный экспорт оставался одним из главнейших источников внутреннего «национального» накопления в Татарии. Вывоз дешевого хлеба и других видов сырья приводил к задержке развития интенсивных отраслей.

Таким образом, в 1920-е годы в сельском хозяйстве столкнулись две противодействующие тенденции: с одной стороны, стремление сохранить патриархальные устои в деревне, с другой – стремление перейти к более интенсивным отраслям хозяйствования, продиктованное интересами развития сельскохозяйственного производства. Большинство хозяйств в Татарии оставались малоземельными. К 1928 г. у 80% сельских хозяйств площадь земельных угодий колебалась от 3 – 4 до 7 десятин (реже до 9 десятин), у 20% – от 9 до 16 десятин.

ки, 1923–1927 елларда крестьяннарга 23 млн. сумнан артык авыл хуҗалыгы кредиты бирелә. Әмма бу кредитлар банклар тарафыннан крестьяннарга зур процентлар белән (Всекобанк (Бөтенроссия кооператив банкы) – 18%, Авыл хуҗалыгы банкы – 15%) җибәрелә. Кыска вакытка бирелеп, алар крестьян хуҗалыгының эчке хуҗалык әйләнешенә аз җайлашкан була.

Проблема дефицита рабочей силы в сельском хозяйстве приобрела хронический характер, поэтому селяне работали бесперебойно. Как поднять дух крестьян, поддержать их? Осенью 1941 г. специальным постановлением ЦК ВКП(б) на селе воссоздаются политотделы МТС и совхозов. В ноябре этого же года принимается Постановление заседания бюро Татарского обкома ВКП(б) по Постановлению СНК СССР и ЦК ВКП(б) от 17 ноября 1941 г. об организации обучения сельскохозяйственным работам учащихся старших классов средних учебных заведений, учащихся высших учебных заведений и части служащих городов и районных центров. Активно используется детский труд – сельские ребятишки наравне со взрослыми работали на прополке, сенокосе, молотьбе, уборке урожая и т.д. Учебный год в сельских школах начинался позже положенного.

дукциясе белән, ә сәнәгатьне чимал белән өзлексез тәэмин итәргә тиеш була. Шул ук вакытта дәүләткә җибәрелә торган авыл хуҗалыгы продукциясенең мәҗбүри күләме эшкә яраклы колхозчылар исәбеннән түгел, күмәк хуҗалыкларга беркетелгән сөрүлекләр буенча билгеләнә.

Техника, тере тарту көче, энергия ресурслары кимүе аркасында күп кенә авыл хуҗалыгы эшләре, элеккеге кебек үк, кулдан башкарыла башлый. Колхозның зәгыйфь атлары, хәлсез һәм ярым ач көенчә, басуларда да кала, чөнки аларның инде аранга барырлык көчләре булмый. Атлар урынына хатын-кызларга җигелергә туры килә…

Авыл хуҗалыгында эшче көчләргә кытлык проблемасы хроник төсмер алды, шуңа күрә авыл халкы өзлексез эшләде. Крестьяннарның рухын ничек күтәрергә, аларга ничек ярдәм итәргә? 1941 елның көзендә ВКП(б) ҮК ның махсус карары белән авылда МТС һәм совхозларның сәяси бүлекләре торгызыла. Шул ук елның ноябрендә СССР Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) ҮКның «Урта уку йортларының өлкән сыйныф укучыларын, югары уку йортлары укучыларын, шәһәр һәм район үзәкләре хезмәткәрләренең бер өлешен авыл хуҗалыгы эшләренә укытуны оештыру турында» 1941 ел 17 ноябрь карары буенча ВКП(б) ның Татарстан өлкә комитеты бюросы утырышы карары кабул ителә. Балалар хезмәте актив файдаланыла – авыл балалары өлкәннәр

ЦИТАТА

«Безнең ризык – элмә каерысы да юкә кабыгы. Көненә бер мәртәбә бер уч арыш ярмасыннан пешерелгән аш эләгә. Безнең бәхеткә яз иртә килде. Черек бәрәңге җыелып беткәч, халык узган елда коелып калган башакны җыярга ябырылды. Без дә, башагыннан аерып җилгәргәннән соң, бер чиләккә якын ризык җыйдык. Әмма ике көн эчендә безнең кечкенә генә авылдан алты кеше вафат булды. Теге кар астында кышлаган башак бодаен ашап агуланганнар икән».

Вакиф Нуруллин «Шинельсез солдатлар» («Солдаты без шинели»)

ПОЭЗИЯ

...Да разве об этом расскажешь,
В какие ты годы жила!
Какая безмерная тяжесть
На женские плечи легла!..

В то утро простился с тобою
Твой муж, или брат, или сын,
И ты со своею судьбою
Осталась один на один.

Один на один со слезами,
С несжатыми в поле хлебами
Ты встретила эту войну.

И все – без конца и без счета –
Печали, труды и заботы
Пришлись на тебя на одну.

Михаил Исаковский

ЦИТАТА

Вот как описала свои детские ощущения Амина Юнусова из Теньковского (ныне – Верхнеуслонского) района Татарии:

«С 12-летнего возраста, как началась война, мы ежегодно по три месяца работали в колхозе. Будили в 3–4 часа утра, не смотрели, что дети. Просыпаться было тяжело. Выполняли различные работы. Помню, как мы трудились на сенокосе: мальчики косили, а мы сначала разбивали огромные копны сена, чтобы успеть их просушить до обеда, затем переворачивали, а вечером снова собирали в копны. За день так умаешься, что еле волочешь вечером домой ноги».

Для повышения эффективности сельского труда принимается решение увеличить обязательный минимум трудодней для колхозников. Для взрослого населения устанавливалось 100–150 трудодней в год в зависимости от местности, для подростков 12–16 лет – не менее 50. При невыполнении этого минимума колхозников ожидала судебная ответственность. Как правило, наказывали исправительно-трудовыми работами на срок до 6 месяцев

белән беррәттән утау, печән чабу, ашлык сугу, урып-җыю һ.б. эшләр башкаралар. Авыл мәктәпләрендә уку елы вакытыннан соңга калып башлана.

ЦИТАТА

Татарстанның Тәмте (хәзерге Югары Ослан) районыннан Әминә Юнысова үзенең бала чактагы хис-кичерешләрен менә ничек тасвирлый: ***«Сугыш башлангач, 12 яшьтән алып, без ел саен өч ай колхозда эшләдек. Иртәнге сәгать 3 тә – 4 тә уяталар, балалар дип тормыйлар иде. Йокыдан тору бик авыр була. Төрле эшләр башкардык. Печән чабуда ничек эшләвебезне хәтерлим: малайлар чабып чыктылар, ә без башта тешкә кадәр киптереп өлгерү өчен зур печән чүмәләләрен тараттык, аннары әйләндердек, ә кичен кабат чүмәләләргә җыйдык. Көне буе шулкадәр арыйсың, кич өйгә кайтканда аякларны көчкә өстерисең».***

Авылда хезмәтнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен колхозчылар өчен мәҗбүри хезмәт көннәре минимумын арттыру турында карар кабул ителә. Зурлар өчен елына 100–150, 12–16 яшьлек яшүсмерләр өчен 50 дән дә ким булмаган хезмәт көне билгеләнә. Бу минимумны

ЗА ЧЕТЫРЕ ВОЕННЫХ ГОДА КРЕСТЬЯНЕ ТАТАРИИ ПОСТАВИЛИ ГОСУДАРСТВУ

ХЛЕБА	МЯСА	КАРТОФЕЛЯ И ОВОЩЕЙ	МОЛОКА	МАСЛА САЛА МЁДА
131	56	39	200	ДЕСЯТКИ ТЫСЯЧ ПУДОВ
МЛН ПУДОВ	МЛН ПУДОВ	МЛН ПУДОВ	МЛН ЛИТРОВ	

Ученицы Айшинской средней школы Юдинского района на полях колхоза «Авангард»

с удержанием из оплаты трудодней до 25% в пользу колхоза. Кроме того, осужденных считали выбывшими из колхоза и лишали приусадебного участка. В результате уже к 1943 г. число сельчан, не выработавших обязательного минимума трудодней, сократилось по сравнению с довоенным уровнем на одну треть, число выработавших от 300 до 400 трудодней увеличилось вдвое, а свыше 400 – в 3 раза.

Еще одной серьезной проблемой деревни военных лет стала нехватка руководящих колхозных кадров. Цифры красноречивы: из 3884 председателей колхозов Татарии на фронт были призваны 2586 человек, сменилось 6363 бригадира полеводческих бригад. При выдвижении на должность обращали внимание прежде всего на политическую благонадежность кандидата. За весь 1942 г. на должности председателей колхозов были выдвинуты 2760 человек, среди них немало женщин. В целом за годы войны в Татарстане число женщин среди председателей колхозов выросло с 19 до 320, среди бригадиров полеводческих бригад – со 150 до 6327, среди заведующих животноводческими фермами – с 747 до 2575.

Особое внимание уделялось работе с коренным татарским населением. На пленумах ОК ВКП(б) предлагалось активнее привлекать на-

үтәмәгән колхозчыларны суд җаваплылыгы көтә. Кагыйдә буларак, 6 айга кадәр срокка хезмәт аша төзәтү эшләре белән җәза бирелә, хезмәт көненә түләүнең 25% ка кадәр өлеше колхоз файдасына тотып калына. Моннан тыш, хөкем ителүчеләрне колхоздан чыккан дип санаганнар һәм йорт яны участогыннан мәхрүм иткәннәр. Нәтиҗәдә, инде 1943 елга ук мәҗбүри хезмәт минимумын үтәмәгән авыл кешеләре саны, сугышка кадәрге күләм белән чагыштырганда өчтән бер өлешкә кими, 300 дән 400 гә кадәр хезмәт көне эшләүчеләр саны ике тапкыр, 400 дән күбрәкләр – өч тапкыр арта.

Сугыш еллары авылының тагын бер җитди проблемасы колхозларда җитәкче кадрларның җитмәве була. Саннар ачык: Татарстанның 3884 колхоз рәисеннән 2586 кеше фронтка чакырыла, 6363 кырчылык бригадалары бригадиры алышына. Вазифага тәкъдим ителгәндә, барыннан да элек, кандидатның сәяси ышанычлылыгына игътибар итәләр. 1942 ел эчендә колхоз рәисләре вазифасына 2760 кеше тәкъдим ителә, алар арасында хатын-кызлар да шактый була. Гомумән алганда, сугыш елларында Татарстанда колхоз рәисләре арасында хатын-кызлар саны 19 дан 320 гә, кырчылык бригадалары бригадирлары арасында – 150 дән 6327

В 1942-1944 ГОДАХ В РЕСПУБЛИКЕ
СОБРАЛИ В ФОНД ПОБЕДЫ
БОЛЕЕ 262 МИЛЛИОНОВ РУБЛЕЙ

циональные кадры на руководящие должности. Это и понятно – население татарских деревень в те годы плохо владело русским языком. В соответствии с этими рекомендациями в Кзыл-Армейском районе в 1943 г. из 34 вновь назначенных председателей колхозов 20 человек оказались татарами, а еще 22 татарина должны были заведовать животноводческими фермами. В Ципьинском районе председателем колхоза им. Сталина была назначена Набеева. Хорошим организатором зарекомендовала себя председатель колхоза им. Ленина Атнинского района Галия Нигметзянова. В 18-летнем возрасте возглавил колхоз «Искра» того же Атнинского района Файзи Галеев.

В республике активно проводились социалистические соревнования – за скорейшее завершение уборочной кампании, сева, получение лучших результатов в растениеводстве, животноводстве и т.д. Количество участников соревнований женских тракторных бригад и звеньев высокого урожая росло из года в год. Так, в республиканском соревновании 1942 г. участвовало 112 женских тракторных бригад

ЦИТАТА

«Тыл – это половина Победы, даже больше».

Георгий Жуков

гә, терлекчелек фермалары мөдирләре арасында 747 дән 2575 кә кадәр арта.

Татарстанда яшәүче төп халык – татарлар белән эшләүгә аерым игътибар бирелә. ВКП(б) өлкә комитеты пленумнарында милли кадрларны җитәкче вазифаларга активрак җәлеп итү тәкъдим ителә. Бу аңлашыла да – ул елларда татар авыллары халкы рус телен начар белә иде. Бу тәкъдимнәр нигезендә, 1943 елда Кызыл Армия районында яңадан билгеләнгән 34 колхоз рәисенең 20 се татар булып чыга, тагын 22 татар терлекчелек фермалары белән җитәкчелек итәргә тиеш була. Чепья районында Сталин исемендәге колхоз рәисе итеп Нәбиева билгеләнә. Әтнә районының Ленин исемендәге колхоз рәисе Галия Нигъмәтҗанова үзен яхшы оештыручы буларак күрсәтте. 18 яшендә шул ук Әтнә районының «Искра» колхозын Фәйзи Галиев җитәкли.

Республикада урып-җыю кампаниясен тизрәк тәмамлау, чәчү, игенчелектә, терлекчелектә иң яхшы нәтиҗәләргә ирешү һ. б. максатларда актив рәвештә социалистик ярышлар үткәрелә. Ярышларда катнашучылар саны елдан-ел арта. Әйтик, 1942 елгы республика ярышында 106 МТС буенча 112 хатын-кыз трактор бригадасы, 1943 елда – 108 МТС буенча 123 хатын-кызлар бригадасы катнаша, 1944 елда инде 168 брига-

ҺӘРБЕР ОРЛЫК
-ДОШМАНГА
УДАР УЛ!
Орлык ни ул?
Моны аңлау жиңел!
Аның тышындагы кабыгы
Ядрә яки туп тимере түгел,
Аның тышы гади, табигый;
Эче аның эди оннан тора
Әмма безне . өчен үткер корал—
Штык төсле аның кыйммәте,
Илне саклау-сугыш эшенә тиң
Һәр орлыкның әһәмияте!
Д. Бедный.

по 106 МТС, в 1943 г. – 123 женские бригады по 108 МТС, в 1944 г. соревновалось уже 168 бригад (число МТС осталось прежним). Результаты соревнующихся не могут не впечатлять. Например, более 200% плана давали трактористки Фатима Серазеева из Юртушской МТС, Гаян Динмухаметова из Бондюжской МТС, Замиля Ильясова из Буденновской МТС и многие другие. Призовые места в разные годы по Татарии занимали тракторные бригады Хатимы Хуснутдиновой из Яныльской МТС Кукморского района (1942), Сагуры Мустафиной из той же МТС (1944), М. Гиниатуллиной из Казанбашской МТС Арского района (1943). Мастерами высоких урожаев зерновых и овощных культур показали себя женщины звена Закии Садыковой из колхоза «Красный партизан» Таканышского (Мамадышского) района, Мадины Кадыровой из колхоза «Дорес юл» Теньковского (Верхнеуслонского) района.

Наибольшую известность в ТАССР получило звено Альфии Ибрагимовой из колхоза «Алга» Дубъязского района, коллектив которого в 1944 г. собрал рекордный урожай, не только завоевав 1-е место по республике, но и 2-е место по стране. Передовики аграрного хозяйства награждались орденами, медалями, грамотами, специальными нагрудными значками «Лучший тракторист», «Отличник социалистического сельского хозяйства» и др. Всего за военный период были представлены к награждению значком «Отличник социалистического земледелия» 139 трактористов и 268 комбайнеров Татарии.

Государство всячески старалось поддержи-

да көч сынаша (МТСлар саны элеккечә кала). Ярышучыларның нәтиҗәләре гаҗәпләндерми калмый. Мәсәлән, Юртыш МТСыннан Фатыйма Сираҗиева, Бондюг МТСыннан Гаян Динмөхәммәтова, Буденный МТСыннан Җәмилә Ильясова кебек тракторчылар планны 200% тан артыгракка үтиләр. Төрле елларда Татарстан буенча призлы урыннарны Кукмара районының Янил МТСыннан Хәтимә Хөснетдинованың (1942 ел), шул ук МТСтан Сәгүрә Мостафинаның (1944 ел), Арча районының Казанбаш МТСыннан М.Гыйниятуллинаның (1943 ел) трактор бригадалары яулады. Тәкәнеш (Мамадыш) районының «Кызыл партизан» колхозыннан Зәкия Садыйкова, Тәмте (Югары Ослан) районының «Дөрес юл» колхозыннан Мәдинә Кадыйрова звенолары хатын-кызлары бөртекле һәм яшелчә культураларыннан югары уңыш алу осталары булып танылды.

ТАССРда иң зур танылуга Дөбъяз районының «Алга» колхозыннан Әлфия Ибраһимова звеносы лаек була, 1944 елда ул җитәкләгән коллектив рекордлы уңыш җыеп ала, республика буенча 1 нче урынны гына түгел, ә ил буенча 2 нче урынны яулый. Аграр хуҗалык алдынгылары орденнар, медальләр, грамоталар, «Иң яхшы тракторчы», «Социалистик авыл хуҗалыгы отличнигы» һ.б. махсус күкрәк билгеләре белән бүләкләнәләр. Сугыш чорында «Социалистик игенчелек отличнигы» билгесе белән бүләкләнүгә барлыгы 139 тракторчы һәм 268 комбайнчы тәкъдим ителә.

Дәүләт крестьяннарның хезмәт күтәрелешенә төрлечә ярдәм күрсәтергә тырыша – игенчелектә уңдырышлылыкны һәм терлекчелектә

Подводы с хлебом

вать трудовой подъем крестьян – дополнительно оплачивалось повышение урожайности в земледелии и продуктивности скота в животноводстве. Например, дополнительную оплату получали колхозники при перевыполнении планов по урожайности сельскохозяйственных культур или значительного повышения продуктивности животноводства. Премиальная надбавка начислялась механизаторам МТС за качественное проведение сева, подъем урожайности и своевременную уборку зерновых. Кроме того, трактористам за перевыполнение планов урожайности предусматривалась выдача 13% зерна, собранного сверх плана, 11% картофеля; комбайнеры за намолот зерна сверх нормы должны были получить по 10 пудов, если за сезон была обработана площадь свыше 180 га, и 25 пудов – за обмолоченную площадь в 300 га и т.д.

Правда, как считают историки, плановые задания большинства видов сельхозработ завышались, нередко допускались случаи уравнительного распределения в оплате труда колхозников, во многих колхозах отсутствовала индивидуальная сдельная работа. Советские крестьяне не имели паспортов, поэтому не могли свободно выезжать из деревни, да и выйти

терлекләрнең продуктивлыгын арттыруга өстәмә түләү кертелә. Мәсәлән, авыл хуҗалыгы культураларының уңдырышлылыгы буенча планнарны арттырып үтәгән яисә терлекчелекнең продуктивлыгын шактый арттыруга ирешкән колхозчылар өстәмә түләү ала. МТС механизаторларына премиаль өстәмә чәчүне сыйфатлы итеп уздырган, уңдырышлылыкны күтәргән һәм бөртеклеләрне вакытында җыеп алган өчен исәпләнә. Моннан кала, тракторчыларга уңдырышлылык планнарын арттырып үтәгән өчен планнан тыш җыеп алынган ашлыкның 13% ын, бәрәңгенең 11% ын бирү каралган була; әгәр бер сезонда 180 гектардан артык мәйдан эшкәртелгән булса, комбайнчылар нормадан тыш ашлык суктырган өчен 10 ар пот, ә 300 гектар мәйданда ашлык суктырган өчен – 25 пот ашлык алырга тиеш була һ. б. Дөрес, тарихчылар фикеренчә, күпчелек төр авыл хуҗалыгы эшләренең план йөкләмәләре арткан, еш кына колхозчыларның хезмәт хакын тигезләү очраклары булган, күп кенә колхозларда индивидуаль эш башыннан түләнә торган эш булмаган. Совет крестьяннарының паспортлары булмый, шуңа күрә авылдан ирекле рәвештә чыгып китә алмыйлар, шулай ук элегрәк «ирекле» рәвештә кергән колхоздан да чыга да алмаганнар.

Вак-вак итеп турап, яшь
киленнәр Табаларда сине биетә;
Кайнар боткаң ашап, эшчән
ирләр Тәннәренә җылы йөгертә.

Йодрык кадәрле. Йомры
гәүдәле, Ак тәнле, Ах, тәмле,
Бигрәк тәмле бәрәңге!

Мәхмүт Хөсәен сүзләре,
Ифрат Хисамов кө

ПОЭЗИЯ

из колхоза, в который они ранее «добровольно» вступили, тоже было практически невозможно.

Главными производителями сельскохозяйственной продукции оставались колхозы и совхозы. Сложившаяся система партийно-государственного управления сельским хозяйством оказывала двоякое воздействие на состояние отрасли. С одной стороны, высокая централизация управления помогла сельхозпредприятиям адаптироваться к непростым условиям военного времени, мобилизовать все имеющиеся ресурсы. С другой стороны, отсутствие хозяйственной самостоятельности и материальной заинтересованности трудящихся сельхозпредприятий, а также некомпетентное руководство и нарушения законности – все это привело к отставанию в развитии сельского хозяйства республики и к чрезвычайно низкому уровню жизни сельчан к концу войны.

Ущерб, полученный сельским хозяйством Татарской республики за годы Великой Отечественной войны, – сегодня в центре внимания историков и специалистов-аграриев. Они анализируют причины резкого отставания производства сельскохозяйственных продуктов от растущих потребностей страны – процесс разрушения материально-технической базы сельского хозяйства в эти годы и серьезные недостатки в руководстве сельским хозяйством. По данным исследований З.И. Гильманова, за военный период посевные площади в республике сократились с 3199 тыс. до 2130 тыс. га, т.е. почти на одну треть. Площади под пшеницей – основной зерновой культуры – уменьшились в 2 раза, под кормовыми культурами – в 2,5

Авыл хуҗалыгы продукциясен төп җитештерүчеләр булып колхозлар һәм совхозлар кала. Авыл хуҗалыгы белән партия-дәүләт идарәсенең барлыкка килгән системасы тармакның торышына ике төрле йогынты ясады. Бер яктан, идарәнең югары үзәкләштерелгән булуы авыл хуҗалыгы предприятиеләренә сугыш чорының катлаулы шартларына җайлашырга, булган барлык ресурсларны мобилизацияләүгә ярдәм итте. Икенче яктан, хуҗалык мөстәкыйльлеге һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәтияләренең матди кызыксынуы булмау, шулай ук компетентсыз җитәкчелек һәм закон бозулар – болар барысы да республика авыл хуҗалыгының үсеше артта калуга һәм сугыш азагына авыл халкының тормыш дәрәҗәсе чиктән тыш начараюга китерде.

Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан республикасы авыл хуҗалыгына килгән зыян – бүген тарихчы һәм белгеч-аграрийларның игътибар үзәгендә. Алар авыл хуҗалыгы продуктларын җитештерүнең илнең үсә баручы ихтыяҗларыннан кискен артта калу сәбәпләрен – бу елларда авыл хуҗалыгының матди-техник базасы җимерелү процессын һәм авыл хуҗалыгы белән җитәкчелек итүдә җитди җитешсезлекләрне тикшерәләр. З.И. Гыйльманов тикшеренүләре буенча, сугыш чорында республикада чәчү мәйданнары 3199 меңнән 2130 мең гектарга кадәр, ягъни өчтән бер өлешкә диярлек кими. Төп бөртекле культура – бодай чәчү мәйданнары – 2 тапкыр, азык культуралары чәчү мәйданнары 2,5 тапкыр кечерәя. Чәчүлек мәйданнарының бераз артуы бәрәңге һәм бакча культуралары утыртылган мәйданнарга гына

раза. Небольшое увеличение посевных площадей произошло лишь под картофель и овоще-бахчевые культуры. Кроме того, в республике появилась новая сельскохозяйственная культура – сахарная свекла.

Значительно сократился объем тракторных работ, что, в свою очередь, сказалось на уровне и степени механизации основных аграрных работ. Также в военные годы почти прекратилась поставка минеральных удобрений. В итоге урожайность с гектара понизилась более чем наполовину, а ежегодные сборы зерновых за 1942–1945 гг. сократились более чем в 2,5 раза.

Крайне неблагоприятное положение в военные годы сложилось в животноводстве республики. К концу войны поголовье лошадей уменьшилось в 2 раза, свиней – в 2,5 раза, крупного рогатого скота – в 1,5 раза. В августе 1944 г. принимается Постановление Совета народных комиссаров СССР «О мерах по подъему животноводства в колхозах ТАССР». В условиях, когда резко сократилась кормовая база за счет концентрированных кормов, фуражных

туры килә. Моннан тыш, республикада яңа авыл хуҗалыгы культурасы – шикәр чөгендере игелә башлый.

Тракторлы эшләр күләме шактый кыскара, бу үз чиратында төп аграр эшләрне механикалаштыру дәрәҗәсендә дә чагылыш таба Шулай ук сугыш елларында минераль ашламалар белән тәэмин итү туктатыла диярлек. Нәтиҗәдә, бер гектардан алына торган уңыш яртылаш кими, ә 1942–1945 еллар өчен бөртеклеләрнең еллык җыемы 2,5 тапкыр азая.

Сугыш елларында республикада терлекчелек торышында бик авыр хәл күзәтелә. Сугыш ахырына атларның баш саны 2 тапкыр, дуңгызларның – 2,5 тапкыр, мөгезле эре терлекләрнең – 1,5 тапкыр кими. 1944 елның августында СССР Халык Комиссарлары Советының «ТАССР колхозларында терлекчелекне үстерү чаралары турында»гы карары кабул ителә. Концентрацияләнгән азык, фуражлы бөртекле культуралар, бәрәңге хисабына азык базасы кискен кимегәндә, азык әзерләү стратегик әһәмияткә ия була. Үләннәр чиста итеп

ПИОНЕРЫ и
ШКОЛЬНИКИ,
БОРИТЕСЬ
С ПОТЕРЯМИ УРОЖА
СОРЕВНУЙТЕСЬ НА ЛУЧШУЮ ПОМОЩЬ

АЯ !
ФРОНТУ !

зерновых культур, картофеля, заготовка кормов приобрела стратегическое значение. Травы собирались подчистую, причем использовались они не только в животноводстве, но и служили существенной витаминной продукцией для самих колхозников. Дети войны хорошо помнят, чему учили их мудрые деревенские старики: на лугу можно есть ту траву, которой питается лошадь.

Как пишет А.Ш. Кабирова, распространенным явлением в колхозах и совхозах в военные годы стало использование крупного рогатого скота в качестве тягловой силы. Только в 1943 г. в республике на уборке зерновых было задействовано 15 тыс. коров из колхоза и 30 тыс. коров из личного пользования.

Государственные планы мясозаготовок в основном выполнялись за счет стада колхоза. В военные годы была возобновлена практика контрактации. При этом условии на колхозном рынке за мясо можно было выручить гораздо больше средств, чем за выдававшееся за скот зерно. Еще одна беда: в большинстве хозяйств имеющийся скот негде было содержать. Животные размещались в холодных грязных помещениях. Значительно ухудшилось ветеринарное обслуживание. Как следствие, участились случаи заболеваний (ящур, чесотка, бруцеллез) сельскохозяйственных животных.

Упадок в развитии полеводства, недостаток кормовой базы, ухудшение условий содержания животных – все это привело к сокращению поголовья и продуктивности колхозно-совхозного стада. Более всего это коснулось коневодства и свиноводства. В меньшей степени пострадали другие отрасли животноводства, однако ни в одной из них численность поголовья скота не приблизилась к довоенному уровню.

җыела, өстәвенә алар терлекчелектә генә файдаланылмый, колхозчыларның үзләре өчен дә витаминлы продукция булып хезмәт итә. Сугыш чоры балалары авыл аксакалларының нәрсәгә өйрәткәнен яхшы хәтерли: болында ат ашаган үләнне ашарга ярый.

А.Ш. Кәбирова язганча, сугыш елларында колхоз һәм совхозларда мөгезле эре терлекләрдән тарту көче буларак файдалану киң таралган күренеш була. 1943 елда гына да республикада бөртеклеләрне җыеп алуда 15 мең колхоз сыеры һәм 30 мең шәхси кулланудагы сыер җәлеп ителә.

Ит әзерләү буенча дәүләт планнары нигездә колхоз көтүе хисабына үтәлә. Сугыш елларында контрактацияне куллану яңадан торгызыла. Шушы шартларда колхоз базарында ит өчен, терлеккә тиңләштерелгән ашлыкка караганда, күбрәк акча алырга мөмкин иде. Тагын бер бәла – күпчелек хуҗалыкларда терлекләрне тоту өчен урын булмау. Хайваннар салкын пычрак биналарда тотыла. Ветеринария хезмәте күрсәтү шактый начарлана. Нәтиҗәдә, терлек авырулары (ящур, корчаңгы, бруцеллез) ешая.

Кырчылык үсеше түбәнәю, азык базасының җитмәве, терлекләрне тоту шартларының начараюы – болар барысы да колхоз-совхоз көтүләренең баш санын һәм продуктивлыгын киметүгә китерә. Барыннан да бигрәк бу атлар асраугa һәм дуңгызчылыкка кагыла. Терлекчелекнең башка тармаклары азрак зыян күрә, әмма аларның берсендә дә терлекләрнең баш саны сугышка кадәрге күрсәткечкә җитә алмый..

Партия органнары индустрияләштерү һәм күмәкләштерү елларында ук нигез салынган тра-

Партийные органы по традиции, заложенной еще в годы индустриализации и коллективизации, начали поиск «врагов» и «диверсантов» среди крестьян. Необходимо было найти «виновников» развала колхозов, срыва хлебозаготовок, «намеренного» заражения животных, даже террористических действий. На пленуме Татарского ОК ВКП(б) 13–16 февраля 1943 г. нарком внутренних дел Габитов доложил об «обнаруженных» в хозяйствах республики контрреволюционных группах... в колхозе «Красная Звезда» Альметьевского района, колхозе «Дон» Набережночелнинского района, колхозе «Горный ключ» Бондюжского района и др. К ним были применены соответствующие карательные меры.

Сегодня, 75 лет спустя, нам трудно представить, как при такой колоссальной физической нагрузке, суровости быта и многочисленных лишениях деревенские люди выжили. И не только выжили, но и сохранили, вырастили достойными людьми своих детей. Очень ярко, почти документально описал эти тяжелые годы глазами своих героев – деревенских подростков – татарский писатель Мухаммет Магдиев в с повести «Без – кырык беренче ел балалар» («Мы – дети сорок первого года»).

Существовавшая в то время карточная система не распространялась на сельчан. Выдача продовольствия колхозникам зависела исключительно от выработанных ими трудодней, а она по сравнению с довоенным периодом сократилась почти в 3 раза. Крестьянин получал на трудодень из колхоза меньше 200 граммов зерна и около 100 граммов картофеля. Хлеб пекли, добавляя в муку желуди, картошку, полынь и даже картофельные очистки. Самой

дициция буенча крестьяннар арасында «дошманнар» һәм «диверсантлар» эзли башлый. Колхозлар таркалуда, икмәк әзерләүләр өзелүдә, хайваннарны «алдан уйлап» зарарлауда, хәтта террорчылык гамәлләрдә «гаеплеләрне» табарга кирәк иде. 1943 елның 13–16 февралендә ВКП(б) Татарстан өлкә комитеты пленумында Эчке эшләр халык комиссары Габитов республика хуҗалыкларында – Әлмәт районының «Красная Звезда» колхозында, Яр Чаллы районының «Дон» колхозында, Бондюг районының «Горный ключ» колхозында контрреволюцион төркемнәр «табылганлыгы» турында хәбәр итте... Аларга карата тиешле җәза чаралары күрелде.

...Бүген, 75 елдан соң, шундый зур физик авырлыклар, көнкүреш кырыслыгы һәм күп санлы югалтуларга карамастан, авыл кешеләренең ничек исән калуын күз алдына китерүе дә кыен. Исән генә калмадылар, балаларын да саклап калдылар, аларны лаеклы кешеләр итеп үстерделәр. «Без – кырык беренче ел балалары» повестенда татар язучысы Мөхәммәт Мәһдиев бу авыр елларны үз геройлары – авыл үсмерләре күзлегеннән, алар язмышы аша бик ачык итеп тасвирлап бирә.

Ул чорда кертелгән карточка системасы авыл кешеләренә кагылмый. Колхозчыларга азык-төлек бирү бары тик алар эшләгән хезмәт көннәренә генә бәйле була, ә ул, сугышка кадәрге чор белән чагыштырганда, өч тапкырга диярлек кими. Крестьянга колхоздан бер хезмәт көненә 200 граммнан кимрәк ашлык һәм 100 граммга якын бәрәңге бирелә. Икмәкне онга имән чикләвеге, бәрәңге, әрем һәм хәтта чистартылган бәрәңге кабыклары кушып пешерәләр.

распространенной уголовной статьей, по которой осуждались колхозники в военные годы, была статья за колоски, унесенные с полей.

Вообще недоедание и голод были постоянными спутниками тех лет. Заветная мечта каждого деревенского ребенка и взрослого – поесть досыта. В то время как мужья и отцы воевали, их семьи выживали, как могли. Использовали в пищу пролежавшее зиму хлебное зерно, замерзший гнилой картофель, из которого делались лепешки. Нередко от картофельного гниля люди травились – опухали лица, руки и ноги… Сахар заменяли самодельным мармеладом из тыквы и свеклы. Кашу варили из семян лебеды, лепешки пекли из конского щавеля. Вместо чая использовали листья черной смородины, сушеную морковь и прочие травы. Зубы чистили обычным углем.

И даже в таких тяжелейших условиях жизни крестьяне Татарии за четыре года поставили государству 131 млн пудов хлеба, 39 млн пудов картофеля и овощей, 56 млн пудов мяса, 200 млн литров молока, десятки тыс. пудов масла, сала, меда, 11 млн пудов сена и другой продукции.

В 1942–1944 гг. в республике собрали в фонд Победы более 262 млн руб. На средства из личных сбережений трудящихся были построены танковые колонны «Красная Татария» и «Колхозник Татарии», авиадивизия «Совет Татарстаны», бронекатера, бронепоезда и многое другое.

В феврале 1945 г. по инициативе кайбицких хлеборобов развернулся сбор средств для фронта. За короткий срок в него поступили десятки миллионов рублей. Одним из таких патриотов, например, являлся член колхоза «Кзыл-Юлдуз» («Красная Звезда») Мензелинского района Хази Ахметов. По примеру саратовского колхозника Ферапонта Головатого он внес для приближения победы над фашистскими захватчиками 101 тыс. руб. На эти деньги построили самолет-истребитель. А сколько варежек и теплых носков, связанных натруженными руками сельских женщин при скудном свете керосиновой лампы, были отправлены на фронт…

Крестьяне Татарии Победу приближали, как могли.

Сугыш елларында колхозчыларны кырлардан рөхсәтсез алып кителгән башаклар өчен хөкем итү иң киң таралган җинаять маддәсе була.

Гомумән, тамак туймау һәм ачлык ул елларның даими юлдашлары була. Һәр авыл баласы һәм зурлар да ул вакыт туйганчы ашау хыялы белән яши. Ирләр һәм аталар сугышта вакытта аларның гаиләләре булдыра алганча яшәргә тырыша. Кыш буе яткан икмәк бөртекләре дә, туңган черек бәрәңге дә ашауга китә, көздән җирдә калган бәрәңгедән кәлҗәмә дә пешереп ашыйлар. Еш кына черек бәрәңгедән кешеләр агулана – йөзләре, куллары һәм аяклары шешенә...

Шикәрне кабак һәм чөгендердән үзләре ясаган мармелад белән алыштыралар. Алабута орлыкларыннан ботка, ат кузгалагыннан көлчәләр пешерәләр. Чәй урынына кара карлыган яфраклары, киптерелгән кишер һәм башка үләннәр файдаланалар. Тешләрне гадәти күмер белән чистарталар.

Хәтта шундый авыр тормыш шартларында да Татарстан крестьяннары дәүләткә дүрт ел эчендә 131 млн пот икмәк, 39 млн пот бәрәңге һәм яшелчә, 56 млн пот ит, 200 млн литр сөт, дистәләгән мең пот май, сало, бал, 11 млн пот печән һәм башка продукция әзерләп тапшыралар.

1942–1944 елларда республикада Җиңү фондына 262 миллион сумнан артык акча җыела. Хезмәт ияләренең шәхси акчаларына «Красная Татария» һәм «Колхозник Татарии» танк колонналары, «Совет Татарстаны» авиадивизиясе, бронекатерлар, бронепоездлар һ.б. төзелә.

1945 елның февралендә Кайбыч игенчеләре инициативасы белән фронт өчен акча җыю башлана. Кыска гына вакыт эчендә аңа дистәләгән миллион сум акча керә. Минзәлә районының «Кызыл Йолдыз» колхозы әгъзасы Хаҗи Әхмәтов шундый патриотларның берсе булып тора. Саратов колхозчысы Ферапонт Головатый үрнәгендә ул фашист илбасарларын җиңүне якынайту өчен 101 мең сум акча кертә. Бу акчага самолет-истребитель төзелә. Керосин лампасының тонык яктысында авыл хатын-кызларының талчыккан куллары бәйләгән күпме бияләйләр һәм җылы оекбашлар фронтка озатыла…

Татарстан крестьяннары Җиңүне мөмкин булганча якынайттылар.

ХЛЕБ – РОДИНЕ!

ВПЕРЕД!
ПОБЕДА БЛИЗ

КА!



1945– 1960 гг.

«Җепшеклек» купләргә тормыш сулышы өрде

ГЛАВА 3

«Оттепель» во многих вдохнула жизнь

ДОБЬЕМСЯ МОЩНОГО ПОД

РАСШИРЯЙТЕ
ПОСЕВЫ
КУКУРУЗЫ!
ЪЕМА ЖИВОТНОВОДСТВА!

МИНИСТРЫ СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА

Ганеев Гиляз Камалетдинович – работал с мая 1948 г. по апрель 1952 г.; с июня 1953 г. по май 1957 г.

Родился в 1906 г. в деревне Казарми Кушнаренковского района Башкирской АССР. Трудовая биография начиналась с таких должностей, как секретарь, затем председатель сельского Совета, политработник районного уровня, секретарь райкома комсомола. В 1936–1938 гг. работал сначала первым, затем вторым секретарем Мишкинского райкома ВКП(б) Башкирской АССР. После окончания Высшей партийной школы был направлен в Казахскую АССР, где работал на различных ответственных постах с 1939 по 1944 г. В 1944 –1947 гг. – заместитель уполномоченного КПК при ЦК ВКП(б) по ТАССР, июнь 1947 г. – май 1948 г. – заместитель заведующего отделом кадров обкома ВКП(б). 15 мая 1948 г. назначается министром сельского хозяйства ТАССР. Июнь 1953 г. – май 1957 г. – министр сельского хозяйства и заготовок ТАССР.

Матвеев Николай Павлович – работал с апреля 1952 г. по июнь 1953 г.

До назначения занимал пост заместителя министра сельского хозяйства ТАССР. После возвращения Г.М. Ганеева на пост министра стал его первым заместителем.

Шибдин Николай Петрович – работал с мая 1957 по июль 1957 г.

До назначения занимал пост председателя Исполнительного комитета Совета народных депутатов трудящихся Арзамасской области. Через два месяца работы министром его перевели на должность секретаря Татарского обкома КПСС.

Гущин Федор Иванович – работал с октября 1957 г. по январь 1959 г.

До назначения работал начальником Саратовского областного управления сельского хозяйства. Проработал министром сельского хозяйства ТАССР 15 месяцев.

Биктимиров Узбек Абдрахманович – работал с января 1959 г. по март 1962 г.

Родился в 1926 г. в Петропавловске в семье рабочего – сортировщика сырья. В 1930 г. семья переехала в Казань. Трудовая биография началась с работы токарем-инструментальщиком на заводе. Окончил Казанский сельскохозяйственный институт по специальности «ученый-агроном». С апреля 1952 г. по октябрь 1954 г. – главный агроном Атнинской МТС, затем директор этой же МТС. С июля 1957 г. – первый заместитель, через два года назначается министром сельского хозяйства ТАССР.

Остаплюк Василий Николаевич – работал с марта 1962 г. по март 1963 г.

До назначения министром производства и заготовок сельскохозяйственных продуктов ТАССР занимал пост первого заместителя Председателя Совета Министров ТАССР, вел сельскохозяйственное направление.

Мартынов Борис Павлович – работал с марта 1963 г. по январь 1965 г.

Родился в 1928 г. в селе Риндино Цивильского района Чувашской АССР в семье сельского учителя. Окончил Казанский сельскохозяйственный институт по специальности «ученый-агроном». После института работал сначала участковым, а затем главным агрономом Димитровской МТС Балтасинского района. С 1958 по 1963 г. занимал ответственные посты в Балтасинском, Буинском, Высокогорском районах. 19 марта 1963 г. назначается первым заместителем председателя Совета Министров и министром производства и заготовок сельскохозяйственных продуктов ТАССР.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛАРЫ

Ганиев Гыйләҗ Камалетдин улы – 1948 елның мае – 1952 елның апрелендә эшли.

1906 елда хәзерге Башкортстан Республикасының Кушнаренко районы Казарма авылында туа. Хезмәт биографиясендә авыл советы сәркатибе, аннары рәисе, район дәрәҗәсендәге сәяси хезмәткәр, комсомол райкомы секретаре вазифалары бар. 1936–1938 елларда башта ВКП(б) Башкортстан АССРның Мишкә райкомының беренче, аннан икенче секретаре булып эшли. Югары партия мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казахстанга җибәрелә, анда 1939–1944 елларда төрле җаваплы урыннарда эшли, 1944–1947 елларда – ТАССР буенча ВКП(б) ҮК каршындагы партия контроле комитеты (КПК) вәкиле урынбасары, 1947 елның июне – 1948 елның мае – ВКБ(б) өлкә комитетының кадрлар бүлеге мөдире урынбасары. 1948 елның 15 маенда ТАССР авыл хуҗалыгы министры итеп билгеләнә 1952 елның апрелендә ВКП(б)ның Казан өлкә комитеты беренче секретаре булып сайлана. 1953 елның июне – 1957 елның мае – ТАССР авыл хуҗалыгы һәм хәзерләүләр министры.

Матвеев Николай Павлович – 1952 елның апреленнән 1953 елның июненә кадәр эшли.

Вазифага билгеләнгәнче, ТАССР авыл хуҗалыгы министры урынбасары булып эшли. Г.К. Ганиев министр вазифасына әйләнеп кайтканнан соң, аның беренче урынбасары була.

Шибдин Николай Петрович – 1957 елның май-июль айларында эшли.

Билгеләнгәнче, Арзамас өлкәсе хезмәт ияләренең халык депутатлары Советы Башкарма комитеты рәисе вазифасын били. Ике ай министр булып эшләгәннән соң КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре вазифасына күчерелә.

Гущин Федор Иванович- 1957 елның октябреннән 1959 елның гыйнварына кадәр эшли.

Билгеләнгәнче, Саратов өлкә авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы булып эшли. ТАССР авыл хуҗалыгы министры булып 15 ай эшли.

Биктимиров Үзбәк Абдрахман улы – 1959 елның гыйнвары – 1962 елның мартында эшли

1926 елда Петропавловскида чимал сортлаучы эшче гаиләсендә туа. 1930 елда гаилә Казанга күчеп килә. Хезмәт биографиясе заводта токарь-инструментальщик булып эшләүдән башлана. Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган, белгечлеге буенча галим-агроном. 1952 елның апреленнән алып 1954 елның октябренә кадәр – Әтнә МТСы баш агрономы, аннары шул ук МТС директоры. 1957 елның июлендә – ТАССР авыл хуҗалыгы министрының беренче урынбасары, ике елдан соң министры итеп билгеләнә.

Остаплюк Василий Николаевич – р1962 елның марты – 1963 елның мартында эшли.

ТАССР авыл хуҗалыгы продуктларын җитештерү һәм хәзерләүләр министры итеп билгеләнгәнче, ТАССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары вазифасын били, авыл хуҗалыгы юнәлешен алып бара.

Мартынов Борис Павлович – 1963 елның марты – 1965 елның гыйнварында эшли.

1928 елда Чуваш АССРның Цивильск районы Риндино авылында укытучы гаиләсендә туа. Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый, белгечлеге буенча галим-агроном. Институттан соң Балтач районының Димитров МТСында башта участок агрономы, аннары баш агроном булып эшли. 1958 елдан 1963 елга кадәр – Балтач, Буа, Биектау районнарында җаваплы вазифалар башкара. 1963 елның 19 мартында Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары һәм ТАССР авыл хуҗалыгы продуктларын җитештерү һәм хәзерләүләр министры итеп билгеләнә.

Страна победителей в страшной войне была опустошена, потеряла миллионы людей на полях сражений, в плену или от голода и болезней, получила разрушенные города и разоренные села. Около 30% национального богатства было потеряно. Великая Отечественная принесла стране колоссальный ущерб.

Программа по восстановлению сельского хозяйства Татарии была разработана областным комитетом партии, когда до Победы оставалось три месяца. Первоочередной задачей объявляется восстановление материально-технического состояния разорившихся колхозов.

В марте 1946 г. в четвертом пятилетнем плане восстановления и развития народного хозяйства СССР (1945–1950) определяются основные задачи в аграрной сфере страны. К концу пятилетки планировалось превышение довоенного уровня производства продукции сельского хозяйства на 27%, прирост поголовья крупного рогатого скота и лошадей на 50%. Предполагалось совершить стремительный прорыв во всех отраслях сельского хозяйства, а высокие показатели рассчитывали достигнуть за счет роста

Дәһшәтле сугышта җиңүчеләр иле бушап кала – ул сугыш кырларында, әсирлектә, ачлыктан һәм авырулардан миллионнарча кешеләрен югалта, меңнәрчә шәһәрләре һәм авыллары җимерелә һәм бөлдерелә. Милли байлыкның 30% ка якыны юкка чыга. Бөек Ватан сугышы илгә гаять зур зыян китерә.

Җиңүгә кадәр өч ай вакыт калгач партия өлкә комитеты тарафыннан Татарстанның авыл хуҗалыгын торгызу программасы эшләнә. Тәмам хәерчеләнгән колхозларның матди-техник торышын торгызу беренче чираттагы бурыч булып тора.

1946 елның мартында СССРның халык хуҗалыгын торгызу һәм үстерү буенча дүртенче бишьеллык (1945-1950) планында илнең аграр өлкәсендәге төп бурычлар билгеләнә. Бишьеллык ахырына авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне сугышка кадәрге күрсәткечтән 27% ка, мөгезле эре терлек һәм атларның баш санын 50% ка арттыру планлаштырыла. Авыл хуҗалыгының барлык тармакларында да ыргылыш ясау, чәчү мәйданнарын арттыру, шулай ук уңдырышлылыкны һәм игенчелек культурасын күтәрү хисабына югары күрсәткечләргә ирешү күздә тотыла.

посевных площадей, а также урожайности и повышения культуры земледелия.

Однако этим грандиозным планам было очень трудно осуществиться. В первую очередь, послевоенное пятилетие оказалось для Среднего Поволжья неблагоприятным по погодным условиям. По мнению аналитиков, засуха 1946 г. была самой жестокой из всех, которые были в стране за 50 лет. Подсчитать число жертв голода 1946–1947 гг., даже приблизительно, представляется сложным, так как власти старались скрыть истинные масштабы трагедии, да и сам факт голода. В научной литературе называется рост официальной смертности в 1947 г. в СССР примерно в 1,5 раза. К началу 1947 г. численность сельского населения сократилась почти на 1 млн человек.

Последствия засухи оказались трагическими и для деревень Татарии, где еще помнили о страшном голоде начала 20-х годов. В засушливый 1946 г. урожай получился вдвое меньше довоенного. Засушливыми оказались и 1948 г., и 1949 г. Сельское хозяйство республики было настолько ослабленным за годы войны, что противостоять природным катаклизмам ему

Әмма әлеге гаять зур планнарны тормышка ашыру бик авырга туры килә. Беренче чиратта сугыштан соңгы бишьеллыкта Урта Идел буенда катлаулы һава шартлары хөкем сөрә. Аналитиклар фикеренчә, илдә 50 ел эчендә 1946 елгы корылык иң рәхимсезе була. 1946-1947 еллардагы ачлык корбаннарының якынча санын гына исәпләп чыгару да кыен, чөнки хакимиятләр фаҗиганең чын масштабларын һәм ачлык фактының үзен дә яшерергә тырыштылар. Фәнни әдәбиятта 1947 елда СССРда рәсми теркәлгән үлем очракларының якынча 1,5 тапкыр артуы күрсәтелә. 1947 ел башына авыл халкы саны 1 миллионлап кешегә кими.

Корылык нәтиҗәләре Татарстан авыллары өчен дә фаҗигале булып чыга, авылларда яшәүчеләр 20 нче еллар башындагы коточкыч ачлык турында хәтерлиләр әле. Корылыклы 1946 елда уңыш сугышка кадәргедән ике тапкыр кимрәк була. 1948 һәм 1949 еллар да коры килә. Сугыш елларында республиканың авыл хуҗалыгы табигый катаклизмнарга каршы тора алмаслык хәлгә килеп какшый. Нәтиҗәдә дүртенче бишьеллыкта әлләни казанышларга ирешелми: бөртеклеләрнең уртача еллык

было не под силу. В результате успехи четвертой пятилетки оказались более чем скромными: среднегодовой урожай зерновых находился на уровне 5,3 центнера с га, валовой сбор зерновых не превышал 65 млн пудов. Это было почти в 2,5 раза меньше, чем предусматривалось планом. Состояние животноводства тоже оставляло желать лучшего: поголовье крупного рогатого скота уменьшилось на 20%, овец, свиней, коз – в 2 раза. Средние надои молока составляли лишь 800–900 кг, примерно столько же молока надаивали в 1939 г. Улучшению ситуации в животноводстве мешали инфекционные болезни, распространившиеся еще в годы войны: у лошадей – чесотка, пироплазмоз, инфекционный энцефаломиелит, нутталиоз, у крупного рогатого скота – ящур, диплококковая инфекция; у свиней – ящур и рожа. В 1946 г. были зарегистрированы даже случаи сибирской язвы людей на предприятиях по первичной переработке шерсти. Но самое главное, для возрождения колхозов не хватало сильных мужских рук. Многие крестьяне, мобилизованные на фронт, не вернулись домой. А некоторые из тех, кому посчастливилось встретить Победу, возвращались инвалидами. В этот же период происходит отток крестьян в города для работы на фабриках и заводах.

Именно в этот период стала закладываться основа развернувшейся позднее бурной урбанизации. Селяне использовали любую возможность, чтобы уйти от тяжелой крестьянской

уңышы күрсәткече гектардан 5,3 центнер тирәсендә тирбәлә, бөртеклеләрнең тулай җыемы 65 миллион поттан артмый. Бу планда каралганнан 2,5 тапкыр диярлек азрак. Терлекчелекнең хәле дә мактанырлык булмый: мөгезле эре терлекнең баш саны – 20% ка, сарыклар, дуңгызлар, кәҗәләрнең исәбе ике тапкыр кими. Уртача савым нибары 800-900 килограмм тәшкил итә – 1939 елда шул чама сөт савыла. Терлекчелектәге хәлне яхшыртуга әле сугыш елларыннан ук атларда – корчаңгы, пироплазмоз, йогышлы энцефаломиелит, нутталиоз, мөгезле эре терлекләрдә – ящур, диплококк инфекциясе, дуңгызларда – ящур һәм рожа кебек йогышлы авырулар таралуы комачаулый. 1946 елда йонны беренчел эшкәртү предприятиеләрендә кешеләрдә хәтта түләмә очраклары да теркәлә.

Әмма иң мөһиме – колхозларны тернәкләндерү өчен көчле ир-атлар җитенкерәми. Фронтка алынган күп кенә крестьяннар яу кырларында ятып кала. Җиңүне каршыларга насыйп булганнарның бер өлеше гарипләнеп-имгәнеп кайта. Шул ук чорда фабрикаларда һәм заводларда эшләү өчен крестьяннар шәһәрләргә агыла.

Нәкъ менә шул чорда соңрак киң колач җәйгән шәһәрләшүгә (урбанизациягә) нигез салына башлый. Авыл халкы авыр крестьян язмышыннан котылу өчен теләсә нинди мөмкинлектән файдалана, әмма бу бик үк җиңел бирелми. Крестьяннарның элеккечә үк паспортлары бул-

Байчурова со студентами КСХИ, 1949 – 1950-е годы

доли, но сделать это было весьма непросто. Крестьяне по-прежнему не имели паспортов. Возможность уйти из деревни давала служба в армии, которая была своего рода социальным лифтом. Еще одной возможностью была учеба в ФЗУ – представители заводов специально приезжали в села для того, чтобы набрать себе учащихся.

Деревня по-прежнему находилась в жестких тисках аграрной политики сталинского руководства. Реалии послевоенной жизни крестьян в большей части были безрадостны: тяжелые условия выживания, многочисленные налоги и повинности, эксплуатация энтузиазма населения, подкрепляемая ужесточением трудового законодательства и усилением внеэкономических методов. Так, заготовительные цены на продукцию колхозов и совхозов были намного ниже затрат на ее производство и не позволяли вести рентабельное хозяйство. Планы устанавливались, исходя из потребностей государства, а не возможностей села. Сохранялся повышенный еще в 1942 г. обязательный минимум выработки трудодней, за невыполнение которого колхознику грозили уголовное наказание или потеря приусадебного участка.

мый. Армиядə хезмəт итү авылдан китəргə мөмкинлек бирə, ул үзенə күрə социаль лифт буларак файдаланыла. Тагын бер мөмкинлек – ФЗУда уку, үзлəре өчен укучылар җыю максатында завод вəкиллəре авылларга махсус килəлəр.

Авыл элеккегечə үк Сталин җитəкчелеге аграр сəясəтенең рəхимсез тискилəрендə кысылып яши. Крестьяннарның сугыштан соңгы чордагы тормышы куанырлык булмый – авыр яшəү шартлары хөкем сөрə , күпсанлы салымнар һəм йөклəмəлəр кертелə, хезмəт законнарын кырысландыру һəм икътисадка бəйле булмаган алымнарны көчəйтү белəн бергə халык энтузиазмы катгый файдаланыла. Шулай итеп, колхоз һəм совхозларның продукциясенə хəзерлəү бəялəре аны җитештерүгə киткəн чыгымнардан күпкə түбəн булып, табышлы хуҗалык алып барырга мөмкинлек бирми. Планнар авыл мөмкинлеклəрен исəпкə алып түгел, бəлки дəүлəт ихтыяҗларыннан чыгып билгелəнə. 1942 елда ук күлəме күтəрелгəн мəҗбүри эшлəнергə тиешле хезмəт көннəре минимумы саклана, колхозчыга аны үтəмəгəн өчен җинаять җəзасы яки йорт яны участогын югалту куркынычы яный.

ПОЭЗИЯ

Оныта алмыйм һаман,
Газапланам, янам,
Инде кайда гына йөрмəдем.
Күңелемдə арыш — Сары сагыш.
Башак шавын ишетəм төннəрен,
Узса җиллəр исеп,
Дулкынлана ничек,
Офыкларга җитеп офыктан.

Фаил Шəфигуллин сүзлəре,
Сəлимə Шəмсина көе

Колхоз с успехом выращивает кукурузу на зерно. Председатель колхоза М.Х. Хусаинов, директор школы Гиниатуллин и агроном колхоза Закиров

В первые послевоенные годы в колхозах республики произошло резкое снижение ценности трудодня по сравнению с довоенным 1940 г. На него приходилось лишь 2,4% общего денежного дохода колхозников. Трудодни в народе назывались «палочками». В каждой семье велась заветная тетрадка, куда старательно проставлялись «палочки». Этот учет позволял колхозникам получать что-то и для себя, но только после того, как хозяйство должно было рассчитаться с государством.

В сентябре 1946 г. в интересах укрепления и развития колхозов Совет Министров СССР принимает постановление «О мерах по ликвидации нарушений устава сельскохозяйственной артели в колхозах». В документе указывалось на факты неправильного расходования трудодней, расхищения общественной земли колхозов и колхозного имущества, на нарушения демократических основ управления жизнью сельскохозяйственных артелей. Для контроля за соблюдением «Устава сельскохозяйственной артели» и решением вопросов колхозного строительства при Правительстве СССР создается Совет по делам колхозов. Надо отметить, что Совет прислушивался к предложениям передовиков сельского хозяйства, в частности, занимался разработкой системы поощрений хозяйств, которые выполняли свои обязательства перед государством.

Но в это же время власти начинают наступление на приусадебные участки колхозников,

Сугыштан соңгы беренче елларда республика колхозларында, 1940 ел белән чагыштырганда, хезмәт көненең кыйммәте кискен кимүе күзәтелә. Аңа колхозчыларның гомуми акча керемене нибары 2,4 % ы туры килә. Халыкта алар «таякчыклар» дип атала. Һәр гаиләдә кадерле дәфтәр алып барыла, шунда тырышыптырышып «таякчыклар» куела. Шул рәвешле исәп алып бару колхозчыларга үзләре өчен дә нәрсә дә булса алырга мөмкинлек бирә, ләкин моның өчен башта хуҗалык дәүләт белән исәп-хисап ясарга тиеш була.

1946 елның сентябрендә колхозларны ныгыту һәм үстерү мәнфәгатьләрендә СССР Министрлар Советы «Колхозларда авыл хуҗалыгы артеле уставын бозуларны бетерү чаралары турында» карарын кабул итә. Документта хезмәт көннәрен дөрес сарыф итмәү, колхозларның җәмәгать җирен һәм колхоз мөлкәтен урлау, авыл хуҗалыгы артельләре тормышы белән идарә итүнең демократик нигезләрен бозу фактлары күрсәтелә. «Авыл хуҗалыгы артеле Уставы»ның үтәлешен һәм колхоз төзелеше мәсьәләләрен хәл итүне контрольдә тоту өчен СССР хөкүмәте каршында Колхозлар эшләре буенча совет төзелә. Совет авыл хуҗалыгы алдынгылары тәкъдимнәренә колак сала, аерым алганда, дәүләт алдындагы йөкләмәләрен үтәгән хуҗалыкларны бүләкләү системасын эшләү белән шөгыльләнә.

Әмма шул ук вакытта, шәхси ярдәмче хуҗалыклардан базарга кергән продукция го-

КОЛХОЗНИКИ И
КРЕПИТЕ ДРУЖБУ Н
СОЦИАЛИСТИЧЕСКИ

КОЛХОЗНИЦЫ!
АРОДОВ СССР
ИМ ТРУДОМ !

хотя продукция, поступавшая с личных подсобных хозяйств на рынок, значительно пополняла общий продовольственный фонд. Однако уже к весне 1946 г. в республике у крестьян было изъято более 91 тыс. га земли, отобрано около 2 тыс. коров и лошадей.

Отдельно остановимся на налоговой политике. Крестьянский двор (и колхозный, и единоличный) облагался государственным натуральным налогом в форме общих поставок продуктов. Для единоличного хозяйства нормы сдачи были более высокими. Каждое крестьянское хозяйство должно было поставлять государству строго определенное количество молока, мяса, яиц, шерсти. В конце 40-х годов увеличиваются сборы и налоги с доходов от продаж на колхозном рынке. Торговать своей продукцией колхозник имел право только при условии выполнения государственных поставок. Практиковался перенос недоимок по поставкам на следующий год, судами взыскивались по ним штрафы, осуществлялась опись в пользу государства крестьянского имущества.

Налоговое законодательство менялось, но при этом, как правило, мало учитывались интересы крестьян. Так, в 1948 г. от уплаты налогов были освобождены хозяйства нетрудоспособных колхозников и единоличников, у которых

муми азык-төлек фондын шактый тулыландырса да, хакимиятләр колхозчыларның йорт яны кишәрлекләренә ябырыла башлыйлар. 1946 елның язы башланыр алдыннан ук республикада крестьяннардан 91 мең гектардан артык җир, 2 меңгә якын сыер һәм ат тартып алына.

ки изменить ситуацию в сельском хозяйстве к лучшему, внедрить прогрессивные формы организации труда. Так, при первом секретаре Татарского обкома КПСС Гумере Исмагиловиче Усманове принимается «Программа 100». Ее реализация позволила резко нарастить комбайновый парк и снизить нагрузку на комбайн до 100 га. Поголовье дойных коров достигло 426 тыс.

В республике бурно развивалось мелиоративное строительство – площади орошаемых земель были доведены до 200 тыс. га, в основном это были (ДКП) долголетние культурные пастбища из расчета 0,5 га на корову, что отразилось на укреплении кормовой базы и росте продуктивности скота. Поливом было обеспечено 100% овощей. В деле орошения был взят курс на внедрение широкозахватной поливной техники «Фрегат» и «Волжанка», электропривода насосных станций, внесения удобрений с поливной водой.

Вместе с тем основу основ продовольственной безопасности страны – сельское хозяйство – серьезно тормозили в развитии командно-административная система и колхозно-совхозная форма организации труда. В те годы в республике существовали крепкие хозяйства, но их экономическое благополучие достигалось, прежде всего, благодаря таланту и ответственности их руководителей. Общая картина характеризовалась бесхозяйственностью, безответственностью, отсутствием должного учета и контроля, личной заинтересованности работников, связанных с уравниловкой при вознаграждении за труд.

кору елларында Коммунистлар партиясе тарафыннан авыл хуҗалыгында хөкем сөргән хәлне яхшы якка үзгәртү, хезмәтне оештыруның прогрессив формаларын гамәлгә кертү омтылышлары ясала. Аерым алганда, КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Гомәр Исмәгыйль улы Усманов вакытында «Программа 100» кабул ителә. Аны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә комбайннар паркын кискен арттыру һәм һәр комбайнга эш йөкләнешен 100 гектарга кадәр киметү мөмкин була. Савым сыерларының баш саны 426 меңгә җитә.

Республикада мелиорация төзелеше куәтле үсеш кичерә – сугарулы җирләрнең мәйданнары 200 мең гектарга кадәр җиткерелә, моңа башлыча бер сыерга 0,5 гектар исәбеннән күпчәкле киң колачлы яңгыр яудыргычлар (ДКП) файдалану нәтиҗәсендә трешелә, бу исә терлек азыгы базасы ныгуда һәм терлекләрнең продуктивлыгы үстешендә чагылыш таба. Сугару белән яшелчәләрнең 100% ы тәэмин ителә. Сугару эшендә киң колачлы «Фрегат» һәм «Волжанка» су сиптерү техникасын, электр приводлы насос станцияләрен файдалануга, сугаруда ашламаларны су белән бергә кертүгә юнәлеш тотыла.

Шуның белән бергә, илнең азык–төлек иминлегенең төп нигезе – авыл хуҗалыгы үсешен команда-административ системасы һәм хезмәтне оештыруның колхоз-совхоз формалары җитди тоткарлыйлар. Әлеге елларда республикада нык хуҗалыклар да бар иде, әмма алардагы икътисади муллыкка барыннан да элек аларның җитәкчеләренең таланты һәм җаваплылыгы хисабына ирешелә. Гомуми манзара хуҗасызлык, җавапсызлык, тиешенчә исәпкә алуның һәм контрольдә тотуның, хезмәт өчен түләүдә тигезләүчелек аркасында хезмәткәрләрдә шәхси кызыксынуның булмавы белән сыйфатлана.

Авыл җирендә кооперативлар, аренда звенолары оеша башлый. Хуҗалыкларның җитәкчеләре альтернатив сайлаулар нәтиҗәсендә демократик юл белән сайлана. Республикада беренче шундый звенолар Актаныш районында барлыкка килә, ә аннары һәркайда таралыш ала башлый. Аларның оешу мәгънәсе аермачык булып, крестьяннарның җиргә мөнәсәбәтен үзгәртүдән, югары уңыш алу белән кызыксындырудан гыйбарәт иде.

Үзгәртеп кору башында Лениногорск районының Мичурин исемендәге колхозында ике интенсив хезмәт коллективы (КИТ) оештырыла. Моның инициаторлары колхоз рәисе



депутат,
мы доверили
ты

власть–
зан
шать самые острые
проблемы перестройки
XXI

На селе стали рождаться кооперативы, арендные звенья. Руководители хозяйств выбирались демократическим путем, в результате альтернативных выборов. Первые такие звенья в республике появились в Актанышском районе, а затем стали распространяться повсеместно. Смысл их возникновения был очевиден: изменить отношение крестьянина к земле, заинтересовать в получении высоких урожаев.

В колхозе имени Мичурина Лениногорского района в начале перестройки было создано два коллектива интенсивного труда (КИТ). Инициаторами выступили председатель колхоза И. Садриев и главный агроном Ф. Лукманов, их энтузиазм поддержало районное начальство. О заинтересованности руководства хозяйства и района в становлении аренды говорит и такой факт: через республиканские организации для колхозных арендных звеньев составили специальные севообороты, позволявшие чередовать культуры на полях в соответствии с агрономической наукой.

Среди механизаторов охотники до нового нашлись быстро. Одно звено возглавил Григорий Куракин, другое – Никанор Исаев. Звеньям выделили тракторы, комбайны, прицепные машины. Арендаторы обеспечивались минеральными удобрениями, семенами, горюче-смазочными материалами.

И.Садриев һәм баш агроном Ф. Локманов иде, аларның энтузиазмын район җитәкчелеге хуплый. Хуҗалык һәм район җитәкчелегенең арендаины гамәлләштерү белән кызыксынуы хакында шул факт та сөйли – республика оешмалары аша колхоз аренда звенолары өчен, агрономия фәненә туры китереп, кырларда культураларны чиратлаштыру мөмкинлеге биргән махсус чәчү әйләнеше булдырыла.

Механизаторлар арасында яңалыкка керешергә теләүчеләр тиз табыла. Бер звеноны – Григорий Куракин, икенчесен Никанор Исаев җитәкли. Звеноларга тракторлар, комбайннар, тагылма машиналар бирелә. Арендачылар минераль ашламалар, орлыклар, ягулык-майлау материаллары белән тәэмин ителә. Куракин звеносы механизаторлары дүртесенә 443 гектар сөрүлек җирләрне арендага алалар! Авыр камыт кияләр. Арендачыларның ничек эшләүләре турында күп һәм озак язарга мөмкин. Остаханәгә, кырга иртә таңнан, башка механизаторлар соңгы төшләрен күреп ятканда чыгалар. Алар гаиләләренә кайтып кергәндә башкалар өйләрендә булла инде. Үз кырларында уңышны үстерү һәм җыйнап алу эшләренең барысын да диярлек үзләре башкаралар. Буразнага беркемне дә кертмиләр. Элек

Механизаторы звена Куракина взяли в аренду 543 га пашни на четверых! Тяжелый хомут. О том, как трудились арендаторы, можно писать долго. Уходили в мастерскую, в поле рано утром, когда другие механизаторы еще досматривали сны. Когда возвращались к семьям – другие уже были дома. Почти весь объем работ, связанный с выращиванием и уборкой урожая на своих полях, выполняли сами. Никого не допускали в борозду. Даже погрузкой-разгрузкой минеральных удобрений, семян – это то, что прежде делали помощники, занимались самостоятельно. Потому что теперь за любую услугу со стороны приходилось расплачиваться из собственного кармана.

И все же звенья распались, расползлась аренда. В колхозе поменялось руководство, и все механизаторы оказались снова в куче, опять пошла погоня «за гектарами». Потому что начались неоправданные отвлечения арендных звеньев на работы, не предусмотренные договором, все чаще руководство хозяйства стало вмешиваться в дела коллективов, ограничивая его хозяйственную самостоятельность.

С переходом на новые экономические отношения крестьянин-землепашец так и не стал настоящим хозяином на земле. Он по-прежнему остался в зависимости от командно-

ярдәмчеләр җәлеп ителгән минераль ашламаларны, орлыкларны төяү-бушату эшләре белән дә мөстәкыйль шөгыльләнәләр. Чөнки хәзер инде читтән күрсәтелгән теләсә нинди хезмәт өчен үз кесәләреннән түләргә туры килә иде.

- Балаларым әтиләрен күрми дә башладылар, – ди звено җитәкчесенең хатыны Зинаида Андреевна Куракина. – Кыр эшләре башлангач, Григорий өйгә кунарга гына кайта иде. Йорттагы эшләрнең барысын да аннан башка гына башкардык. Ышанасызмы-юкмы, ул чакта мин эчемнән генә аның арендасын каһәрләдем...

Арендачыларның һәркайсының гаиләсендә – Николай Куракин, Гамил Әюпов, Дамир Зәйнуллин гаиләләрендә шундый ук хәл хөкем сөрә. Колхозда да сәламәт булмаган микроклимат урнаша. Тузган техниканы төзекләндереп, чүплеккә чыгарып ташланган эш коралларын һәм детальләрне торгызып һәм үз ихтыяҗларына яраклаштырып, тәмам арып аяктан егылырлык хәлгә килсәләр дә, күп кенә колхозчылар иң яхшы әйберләр арендачыларга бирелә дип санýйлар.

Җир «хуҗалары» булып җитлегү процессы авыр бара. Беренче ике елда арендачылар катлаулы сынауга дучар булалар – игеннәр җәйге корылыктан,боз сугудан зыян

административной системы, представленной в колхозе правлением, его председателем и конторой. Например, продавать зерно предстояло не государству, а колхозу, и не по закупочным, а по так называемым расчетным ценам. Если колхоз продавал государству центнер гороха за 20 руб., то арендное звено колхозу за рубль с копейками. На селе, как и в народном хозяйстве страны в целом, создавалась та самая революционная ситуация, когда «низы» уже не хотели жить по-старому, а «верхи» не могли управлять по-старому.

Политические события, произошедшие в стране в конце 80-х и начале 90-х годов, одновременно драматичны и судьбоносны. В августе-октябре 1990 г. за «парадом суверенитетов» союзных республик последовал «парад суверенитетов» автономных образований. Принимается Декларация о государственном суверенитете Татарской АССР. Для Татарии начинается важный исторический период, полный надежд и ожиданий.

Однако экономические реформы, предпринятые в федеральном центре, рикошетом бьют по регионам. 1992 г. вошел в новейшую историю сельского хозяйства России переходом к рыночной экономике и памятен как год «шоковой терапии Гайдара». Либерализация цен обострила их диспаритет, так как никем не контролируемые цены на промышленную продукцию устремились вверх, а на сельскохозяйственную, ввиду ее особой социальной значимости, стали придерживаться. Если в советские годы цена литра солярки составляла 4 копейки, а литр молока – 10 копеек, то в ходе рыночной

күрәләр. Ничек кенә югары нәтиҗәләргә омтылсалар да, казанышларга ирешү мөмкин булмый. Искечә эшләгән башка механизаторлар белән чагыштырганда арендачылар хезмәтенең җитештерүчәнлеге югарырак булса да, килешүдәге йөкләмәләрне үти алмыйлар. Дөрес, шул чакта да колхоз идарәсе алардан йөз чөерми – башкарылган эшләр, запас частьларны һәм башка материалларны янга калдырган өчен хезмәт хакы түли.

...Шулай да звенолар таркала, аренда сүтелә. Барлык механизаторлар кабат бер өемдә тупланалар, янә «гектарлар артыннан» куарга керешәләр. Чөнки нигезсез рәвештә аренда звенолары килешүдә каралмаган эшләргә бүлдерелә, коллективларның мөстәкыйльлеген чикләп, хуҗалык җитәкчелеге торган саен аларның эшләренә ешрак катыша башлый.

Яңа икътисади мөнәсәбәтләргә күчкәннән соң да крестьян җирдә чын хуҗага әверелми. Ул элеккегечә үк колхозда идарә, аның рәисе һәм контора буларак гәүдәләнгән командахакимият системасына бәйле булып кала. Мәсәлән, аның тарафыннан ашлык дәүләткә түгел, колхозга һәм сатып алу бәясе буенча түгел, ә исәп-хисап бәяләреннәнсатылырга ттиеш иде. Әгәр дә колхоз дәүләткә борчакны центнеры өчен 20 сумнан сатса,колхозның аренда звеносы аны фәлән сум да фәлән тиенгә генә сата иде.

Илдә 80 нче еллар ахырында – 90 нчы еллар башында булган сәяси вакыйгалар бер үк вакытта драматик һәм язмыш төсенә керәләр. 1990 елның август-октябрь айларында, союздаш республикаларның «суве-

реформы ситуация поменялась: молоко стало в 2 раза дешевле солярки.

Сельское хозяйство Татарстана, лишенное государственной поддержки федерального центра, стало терять финансовую устойчивость. Перестали строиться новые производственные объекты – коровники, мастерские, зернотоки, кормохранилища, прекратилось обновление машинно-тракторного парка, началось сокращение поголовья скота как в общественном секторе, так и в личных подсобных хозяйствах населения. Характерная картина для этого периода: пустые прилавки продуктовых магазинов и длинные очереди людей с талонами на руках…

В этих непростых условиях по инициативе Президента Татарстана Минтимера Шариповича Шаймиева принимается курс на «мягкое вхождение в рынок». Были введены меры по ограничению вывоза за пределы республики товаров первой необходимости. Хозяйствам, реорганизованным по указанию Москвы в акционерные общества, товарищества, ассоциации крестьянско-фермерских хозяйств и т.д., разрешили оформление банковских кредитов, банковская ставка которых подскочила до 100–200% и более. Это было сложное решение, но на тот момент сельское хозяйство находилось под угрозой полного разрушения. Кроме того, статус суверенитета позволил Татарстану перенаправить часть средств от продажи нефти и других маржинальных отраслей, направлявшихся ранее в федеральный бюджет, в экономику республики, в частности в сельское хозяйство. Но ситуация оставалась по-прежнему сложной.

ренлыклар парады»ннан соң, автономияле берәмлекләрнең «суверенлыклар парады» булып уза. Татарстан АССРның дәүләт суверенлыгы хакындагы Декларация кабул ителә. Татарстан өчен өметләр һәм көтелүләр белән тулы мөһим тарихи чор башлана.

Әмма федераль үзәктә кабул ителгән икътисади реформалар рикошет рәвешендә төбәкләргә китереп суга. 1992 ел Россия авыл хуҗалыгының яңа тарихына базар икътисадына күчү буларак керә һәм «Гайдар шок терапиясе»елы буларак истә кала. Бәяләрне ирекккә җибәрү аларның тигезләнеше бозылуны кискенләштерә, чөнки. беркем дә тарафыннан контрольдә тотылмау сәбәпле, сәнәгать продукциясенә бәяләр югарыга томырыла, авыл хуҗалыгы продукциясе аерым социаль әһәмияткә ия булганга күрә, аның бәяләре саклана килә. Әгәр дә совет елларында солярканың литры – 4 тиен, сөтнең литры 10 тиен торса, базар реформасы барышында хәл үзгәрә – сөт соляркага караганда ике тапкыр арзанрак бәяләнә.

Татарстанның авыл хуҗалыгы, федераль үзәкнең дәүләт ярдәменнән мәхрүм ителеп, финанс тотрыклылыгын югалта башлый. Яңа җитештерү объектлары – сыер абзарлары, остаханәләр, ындыр табаклары, азык саклау урыннары төзү, машина-трактор паркын яңарту туктатыла, җәмәгать секторында да, халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларында да терлекләрнең баш саныазаюга йөз тота. Азык-төлек кибетләрендәге буш прилавкалар һәм кулларына талон тоткан кешеләрнең озын чиратларга тезелүе әлеге чор өчен хас күренеш

1991
КОНЕЦ
И НАЧАЛО

Азат Галимзянович Зяббаров, Гумер Исмагилович Усманов, Вагиз Василович Мингазов

Азат Галимзянович Зяббаров, директор зверосовхоза «Бирюлинский» (1990–1994 гг.)

Характер нашего крестьянина таков, что ему чем трудней, тем он упрямей. Азат Галимзянович Зяббаров, генеральный директор агрофирмы «Бирюли» Высокогорского района, раньше большинства других руководителей понял, что в создавшейся ситуации спасение утопающих – дело рук самих утопающих. В то время, когда большинство хозяйств Татарстана, спешно меняя вывески на конторах, продолжали барахтаться в трясине долгов и безденежья, на базе Бирюлинского зверосовхоза в рост пошло государственное предприятие, которое, поднимаясь в гору само, взяло «на буксир» и лежащие рядом разоренные хозяйства. И вскоре агрофирма представляла из себя крупное сельхозформирование с площадью угодий более 13 тыс. га, в дальнейшем увеличившихся до 23 тыс. К середине 90-х аналогов в сельском хозяйстве Татарстана не было. В 1996 г. из «Бирюлей» на рынок поступило более 6 тыс. тонн зерна, 1,6 тыс. тонн картофеля, 5 тыс. тонн молока, 658 тонн скота, не считая пушнины. Агрофирма была удостоена авторитетной международной награды – «Факел Бирмингема» за успешное экономическое выживание в трудных условиях зарождающихся рыночных отношений.

иде. Шундый катлаулы шартларда Татарстан Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев инициативасы белән «базарга йомшак керү» юнәлеше кабул ителә. Иң кирәкле товарларны республикадан читкә чыгаруны чикләү буенча чаралар күрелә. Мәскәү күрсәтмәсе буенча акционерлык җәмгыятьләре, ширкәтләр, крестьян-фермер хуҗалыклары ассоциациясе һ.б. итеп үзгәртеп корылган хуҗалыкларга банк кредитлары рәсмиләштерергә рөхсәт итәләр, аларның банк ставкасы 100-200% ка сикерә һәм аннан да артып китә. Бу катлаулы юл иде, әмма ул вакытта авыл хуҗалыгы тулысынча җимерелү куркынычы яный. Моннан тыш, суверенлык статусы Татарстанга элек федераль бюджетка җибәрелгән нефть һәм башка маржиналь тармаклар сатудан кергән акчаларның бер өлешен республика икътисадына, аерым алганда, авыл хуҗалыгына юнәлдерергә мөмкинлек бирә. Әмма вазгыять элеккечә катлаулы булып кала бирә.

1996 елда, җирне һәм элеккеге колхоз-совхоз мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибендә, хуҗалыкларның хезмәткәрләренә һәм колхоз-совхоз пенсионерларына – җир өлешләренә һәм милек пайларына, ә авылдагы социаль өлкә хезмәткәрләренә – укытучыларга, та-

ЦИТАТА

«Суть аграрной реформы – в закреплении частной собственности на землю и имущество за крестьянами с конечной целью – создать эффективно работающие сельскохозяйственные предприятия. Реформы – это не только реальная необходимость, но и потребность жизни».

Валерий Васильев, министр сельского хозяйства и продовольствия Татарстана в 1996 – 1999 гг.

В 1996 г. работников хозяйств и колхозно-совхозных пенсионеров в порядке приватизации земли и бывшего колхозно-совхозного имущества стали наделять правом собственности на земельные доли и имущественные паи, а работников социальной сферы села – учителей, врачей, библиотекарей и т.д. – правом на земельную долю. На каждого попавшего в списки было выписано соответствующее свидетельство с гербовой печатью. Но что делать с этими свидетельствами, большинство населения не знало. Многие руководители заперли документы в конторских сейфах. Реформы буксовали.

В сельском хозяйстве республики попрежнему преобладало крупное производство. Однако убедительные примеры стойкости, предприимчивости и ответственности фермеров «первой волны» на фоне всеобщего упадка укрепляли в руководстве понимание того, что фермерство – это та соломинка, за которую надо было в тот момент схватиться. И в Татарстане на государственном уровне выбирают курс на фермеризацию сельского хозяйства.

В 1997 г. в Альметьевском районе проходит республиканский семинар-совещание с участием глав администраций районов, руководителей и специалистов сельского хозяйства, республиканских министерств и ведомств. О ситуации в аграрном секторе республики говорится без прикрас. Несмотря на высокие производственные показатели, финансовое состояние сельскохозяйственных товаропроизводителей остается сложным. Долги предприятий АПК

библарга, китапханәчеләргә һәм башкаларга җир өлешенә милек хокукы бирелә башлый. Исемлеккә кергән һәр кешегә герблы мөһер сугылган тиешле таныклык язылады. Ләкин бу таныклыклар белән нәрсә эшләргә кирәклеген халыкның күбесе белми иде. Күп кенә җитәкчеләр документларны контора сейфларына бикләп куя. Реформалар аксыйлар. Республиканың авыл хуҗалыгында элеккечә эре җитештерү өстенлек итә. Әмма «беренче дулкын» фермерларының гомуми таркалыш шартларында ныклык, булдыклылык һәм җаваплылык күрсәтүе җитәкчелектә фермерлыкның ул вакытта тотынырга кирәкле терәк булуы турындагы фикерне ныгытты. Татарстанда да авыл хуҗалыгын фермерлаштыруга юнәлеш тотыла.

1997 елда Әлмәт районында район хакимияте башлыклары, авыл хуҗалыгы, республика министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре һәм белгечләре катнашында республика семинар-киңәшмәсе уза. Республиканың аграр секторындагы хәл турында катгый сүз була. Җитештерү күрсәткечләре югары булуга карамастан, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең финанс хәле катлаулы булып кала бирә. Аграр сәнәгать комплексы предприятиеләренең банкларга һәм төрле кредит бирүчеләргә бурычлары 5 триллион сум чамасы тәшкил итә. Республика хуҗалыклары елны 100 миллиард сумнан артык зыян белән тәмамлый. Бюджеттан тыш фондларга салымнар буенча бурычлар гына да якынча 1 трилли-

банкам и различным кредиторам составляют почти 5 трлн руб. Хозяйства республики закончили год с убытком свыше 100 млрд руб. Задолженность только по налогам во внебюджетные фонды составляет около 1 трлн руб., в том числе различные пени и штрафы – 150 млрд руб.

Участникам семинара-совещания представили опыт Альметьевского района, где накануне в срочном порядке были созданы в качестве примера 200 крестьянско-фермерских хозяйств (КФХ).

Однако нововведение не было воспринято в аграрной среде однозначно. Руководители и специалисты сельского хозяйства пока не были готовы к переходу на новые производственные отношения. Фермеры к тому моменту еще не показали себя устойчивой, динамично набирающей силу формой организации труда. А в сознании крестьян еще не стерлась память о «кулаках-мироедах».

Время показало: назначить крестьянина фермером нельзя, он должен состояться сам – добровольно, осознанно, с пониманием всех трудностей, которые ему предстоит преодолеть. Большинство первых КФХ в Альметьевском районе вскоре распалось.

Яркой иллюстрацией непростого отношения к реформам, имевшего место в ту пору на селе, является ситуация в агрофирме «Идель» Высокогорского района. Авторитетный директор хозяйства Рафик Замалетдинович Гильмутдинов, вдохновленный решениями Альметьевского семинара-совещания, решил немедленно провести реорганизацию, создав на базе хозяйства 9–10 кооперативов и несколько крестьянско-

он сум, шул исәптән төрле пенялар һәм штрафлар 150 миллиард сум тәшкил итә.

Семинар-киңәшмәдә катнашучыларга Әлмәт районы тәҗрибәсе турында сөйләнә, анда әлеге чара алдыннан гына ашыгыч тәртиптә үрнәк рәвешендә 200 крестьян-фермер хуҗалыгы оештырыла.

Әмма бу яңалык аграр мохиттә бертөрле генә кабул ителми. Авыл хуҗалыгы җитәкчеләре һәм белгечләре яңа җитештерү мөнәсәбәтләренә күчәргә әзер булмыйлар. Фермерлар ул чакта үзләрен хезмәтне оештыруның тотрыклы, динамик рәвештә көч җыючы формасы буларак танытырга өлгермиләр. Ә крестьяннарның аңында «кулаклар-байгуралар» турындагы хатирәләр җуелмый әле.

Вакыт шуны күрсәтте: крестьянны билгеләп кенә фермер итеп булмый, ул үз теләге белән, үзе узарга тиешле барлык кыенлыкларны аңлап мөстәкыйль рәвештә хуҗалык алып барырлык булып җитлегергә тиеш. Әлмәт районындагы беренче крестьян-фермер хуҗалыкларының күбесе тиздән таркала.

Биектау районының «Идел» агрофирмасында килеп туган хәл – ул чорда авылда реформаларга карата гади булмаган мөнәсәбәтнең ачык мисалы. Хуҗалыкның Әлмәт семинар-киңәшмәсе карарлары белән рухланган абруйлы директоры Рәфыйк Җамалетдин улы Гыйльметдинов, хуҗалык җирлегендә 9-10 кооператив һәм берничә крестьян-фермер хуҗалыгы оештырып һәм аларга җирләр бүлеп биреп, кичекмәстән хуҗалыкны үзгәртеп корырга карар кыла. Ләкин директорга ышанычсызлык белдереп һәм аның урынына башка



фермерских хозяйств с наделением их землей. Но встретил отпор в лице большинства специалистов, которые написали петицию в администрацию Высокогорского района и в вышестоящую производственную организацию – концерн «Татплодоовощпром», в которой высказали недоверие директору и потребовали его переизбрания. В результате директора-реформатора сняли с должности. И хотя потом приказом министра сельского хозяйства и продовольствия РТ Валерия Павловича Васильева Р. Гильмутдинов был восстановлен в должности, но продолжать свою работу в этом качестве он уже не смог.

Но были примеры и другого плана. Так, еще в 1991 г. в Альметьевском районе решением общего собрания работников колхоза имени Фрунзе, существовавшего 60 лет, было создано акционерное общество «Тан». Крестьяне стали совладельцами собственности акционерного общества – зданий, техники, скота и других фондов бывшего колхоза. Чтобы соблюсти социальную справедливость, тогда даже подняли архивные данные с 1930 г. – с момента создания колхоза. Стаж тех сельчан, документы на которых были утерянными, определял совет стариков. Проведенная реорганизация вскоре благотворно стала сказываться на отношении людей и к своей работе, и на результатах труда.

Реформы на селе, тем не менее, продвигались медленно. Быстрее нарастали кризисные моменты. Начали возникать многомесячные задержки с выдачей работникам зарплаты. Причин этому было несколько: высокая закредитованность хозяйств, прекращение практи-

кешене сайлауны таләп итеп Биектау районы хакимиятенә һәм югары җитештерү оешмасына – «Татплодоовощпром» концернына петиция язган белгечләрнең күпчелеге каршылыгына очрый. Нәтиҗәдә реформатор директор вазифасыннан азат ителә. Аннары Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Валерий Павлович Васильев боерыгы белән Р.Гыйльметдинов вазифасында торгызылса да, ул шул сыйфатта үз эшен дәвам итә алмый.

Башка төрле мисаллар да бар. Мәсәлән, 1991 елда Әлмәт районында 60 ел буе яшәп килгән Фрунзе исемендәге колхоз хезмәткәрләренең гомуми җыелышы карары белән «Таң» акционерлык җәмгыяте оештырыла. Крестьяннар акционерлык җәмгыяте мөлкәтенең – элеккеге колхоз биналарының, техникасының, терлекләренең һәм башка фондларының милекчеләре булалар. Социаль гаделлекне саклау өчен, ул чакта хәтта 1930 елдан – колхоз төзелгәннән бирле теркәлеп килгән архив мәгълүматларын да күтәрәләр. Документлары югалган авылдашларның стажын аксакаллар шурасы билгели. Әлеге үзгәртеп кору тиздән кешеләрнең үз эшләренә дә, хезмәт нәтиҗәләренә дә уңай йогынты ясый башлый.

Шулай да авылда реформалар акрын бара. Кризис мизгелләре тизрәк үсә. Эшчеләргә хезмәт хакы түләүдә күп айлык тоткарлыклар туа башлый. Моның сәбәләре берничә була, ягъни – хуҗалыкларның зур кредитлар алуы, банк бурычларын сызуны туктату, банкларның яңа кредитлар бирүдән баш тартуы, хәзерләләрү һәм эшкәртү предприятиеләре тарафыннан

ки списания банковских долгов, отказ банков в новых кредитах, нарушения платежной дисциплины со стороны заготовительных и перерабатывающих предприятий. Все это привело к тому, что труднее стало проводить сезонные полевые работы, обеспечивать нормальное функционирование животноводческих ферм, обновлять и восстанавливать технику.

В таких сложных условиях еще ярче проявился талант ряда руководителей сельхозпредприятий республики. Сумели адаптироваться к рынку и нашли резервы для сохранения жизнеспособности и развития руководители хозяйств Файзрахман Ахметович Галиев (колхоз «Искра» Атнинского района), Нафик Факилович Хусаинов (СХПК им. Вахитова Кукморского района), Хамит Гараевич Гараев (ООО «Якты юл» Балтасинского района), Анна Андреевна Захарова (ООО «Серп и Молот» Высокогорского района), Ильшат Газимович Ганиев (ООО ТК «Майский» Зеленодольского района), Раухат Салихянович Салихянов (колхоз им. Шаймарданова Актанышского района), Рафик Рауфович Рауфов (ООО «Новая жизнь» Кукморского района), Николай Васильевич Андреев (ОАО «Масловский» Рыбно-Слободского района), Фоат Габдулхакович Вилданов (ПК «Камский» Тукаевского района), Мансур Рахимзянович Галятдинов (АКХ «Яна юл» Апастовского района), Фазыл Вагизович Ибатуллин (СПК «50 лет Октября» Черемшанского района), Геннадий Самигуллович Миннуллин (СПК «Колос» Бавлинского района), Сирин Ахатович Галиев

түләү дисциплинасы бозылу. Болар барысы да сезонлы кыр эшләрен башкаруда, терлекчелек фермаларының нормаль эшләвен тәэмин итүдә, техниканы яңартуда һәм төзекләндерүдә кыенлыклар тудыра.

Әлеге катлаулы шартларда республиканың кайбер авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренең таланты тагын да яктырак чагыла. Хуҗалыкларның җитәкчеләре – Фәйзрахман Әхмәт улы Галиев (Әтнә районының «Искра» колхозы), Нәфыйк Факил улы Хөсәенов (Кукмара районының Вахитов исемендәге авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы), Хәмит Гәрәй улы Гәрәев (Балтач районының «Якты юл» ҖЧҖ), Анна Андреевна Захарова (Биектау районының «Серп и молот» ҖЧҖ), Илшат Газим улы Ганиев (Яшел Үзән районының «Майский» ҖЧҖ), Рәүхәт Салихҗан улы Салихҗанов (Актаныш районының Шәймәрдәнов исемендәге колхозы), Рәфыйк Рәүф улы Рәүфов (Кукмара районының «Яңа тормыш» ҖЧҖ), Николай Васильевич Андреев (Балык Бистәсе районының «Масловский» ААҖ), Фоат Габделхак улы Вилданов (Тукай районының «Кама» җитештерү кооперативы), Мансур Рәхимҗан улы Галәветдинов, Апас районы «Яңа юл» хуҗалыгы), Фазыл Вагыйз улы Ибәтуллин (Чирмешән районының «Октябрьнең 50 еллыгы» хуҗалыгы), Геннадий Сәмигулла улы Миңнуллин (Баулы районының «Колос» хуҗалыгы), Сирин Әхәт улы Галиев (Ютазы районының «Бәйрәкә» ҖЧҖ), Мәхтүр Мансур улы Нуриев (Әгерҗе районының

(ООО «Байряка» Ютазинского района), Махтур Мансурович Нуреев (СХПК «Тан» Агрызского района), Рустам Габдулазянович Хайруллин (СХПК «Северный» Арского района), Мансур Сафович Халилов (колхоз «Алга» Алексеевского района) и др.

Они умело использовали тот запас прочности, который хозяйства накопили в 80-е годы, участвуя в программах «100» (не более 100 га уборочной площади на комбайн), мелиорации, химизации и т.д. А также мудро разрабатывали стратегию и тактику, применяя хозрасчет, усиливая учет и контроль, экономию и бережливость, проявляли предприимчивость, рачительность, эффективно применяли меры материальной и моральной заинтересованности работников.

Большое внимание агропромышленному комплексу уделяло руководство республики. В качестве государственной поддержки сельскому хозяйству уходило до четверти республиканского бюджета. Стало хорошей практикой регулярное проведение республиканских семинаров-совещаний по изучению и распространению передового опыта. По указанию Президента Татарстана Минтимера Шариповича Шаймиева в 1994 г. была принята Республиканская программа по увеличению производства продовольственной пшеницы. Созданная при ТатНИИСХ группа «Продовольственная пшеница» под руководством Иосифа Фомича Левина разработала технологию выращивания с рекомендацией использования перспективных сортов, на хлебоприемных предприятиях

«Таң» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы), Рөстәм Габделәхәтҗан улы Хәйруллин (Арча районының «Северный» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы), Мансур Сафа улы Хәлилов (Алексеевск районының «Алга» колхозы) һәм башкалар базарга җайлаша алалар, яшәү сәләтен саклау һәм үсеш өчен резервлар табалар. Алар 80 нче елларда «100 программасы» (комбайнга йөкләнеш 100 гектардан артмау), мелиорация, химияләштерү программаларында һәм башкаларда катнашып хуҗалыклар туплаган ныклык запасларын оста файдаланалар, шулай ук хуҗалык исәп-хисабын кулланып, исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны, бәрәкәтлелекне һәм сакчыллыкны көчәйтеп, стратегия һәм тактиканы белеп эшлиләр, булдыклылык күрсәтәләр, хезмәткәрләрне матди һәм мораль кызыксындыру чараларын нәтиҗәле кулланалар.

Республика җитәкчелеге агросәнәгать комплексына зур игътибар бирә. Республика бюджетының чиреге чамасы авыл хуҗалыгына дәүләт ярдәме буларак сарыф ителә. Алдынгы тәҗрибәне өйрәнү һәм тарату буенча даими рәвештә республика семинар-киңәшмәләрен уздыру яхшы тәҗрибәгә әверелә. Татарстан Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев Указы белән 1994 елда азык-төлек бодае җитештерүне арттыру буенча республика программасы кабул ителә. Иосиф Фомич Левин җитәкчелегендә Татарстан авыл хуҗалыгы каршында оештырылган «Азык-төлек бодае» төркеме перспективалы сортларны куллану тәкъдимен үз эченә

была налажена приемка зерна по группам качества, были отработаны вопросы стимулирования сельхозпроизводителей. В результате республика, где выращенная пшеница в основном шла на кормовые цели, смогла в достатке обеспечивать себя продовольственной пшеницей.

В середине 90-х годов уже при министре сельского хозяйства Фатихе Саубановиче Сибагатуллине была принята программа поглотительного скрещивания районированных в Татарстане пород скота с самой молочной в мире голштинофризской. Процесс адаптации происходил сложно, но потенциал продуктивности скота вырос. Республика уверенно перешагну-

алган үстерү технологиясен эшли, икмәк кабул итү предприятиеләрендә сыйфат төркемнәре буенча ашлык кабул итү җайга салына, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләрен стимуллаштыру мәсьәләләре эшләнә. Нәтиҗәдә, үстерелгән бодай башлыча азык максатларында кулланылган республика үзен азык-төлек бодае белән тәэмин итә алды.

90 нчы еллар уртасында, авыл хуҗалыгы министры Фатыйх Сәүбән улы Сибәгатуллин вакытында, Татарстанда районлашкан терлек токымнарын дөньяда сөтне иң күп бирүче голштин-фриз токымлы сыерлар белән катнаш кушу программасы кабул ителә. Җайлашу процессыкатлаулы бара, әмма терлекләрнең продуктивлык потенциалы арта. Республика бер

ла рубеж надоев в 3000 кг молока на корову в год и пошла дальше.

В 90-е годы агропромышленный комплекс Татарстана имел еще немалый запас прочности. На передовых позициях по России оставалась молочная промышленность республики. Благодаря государственной поддержке из республиканского бюджета районные объединения «Татсельхозхимии» продолжали работы по известкованию кислых почв, оказанию других услуг хозяйствам. Несмотря на нарастающие трудности из-за неплатежей, продолжали функционировать районные подразделения «Сельхозтехники». Начали сдавать сбои, но еще работали мясокомбинаты.

И все же преобладающей в сельском хозяйстве и России, и республики была тенденция к ухудшению ситуации. Постоянные задержки с зарплатой усилили миграцию сельского населения в города, продолжилось сокращение поголовья скота и птицы как в общественном секторе, так и в личных подсобных хозяйствах. Неконтролируемый и непрогнозируемый рынок сельхозпродукции не мог быть стимулом для хозяйств к достижению высоких результатов. Даже рекордный для Татарстана урожай 1997 г. – более 6 млн тонн зерна – не улучшил финансовое состояние сельхозпроизводителей из-за обрушившихся цен на зерно. «Недород – горе, урожай – беда». Эта поговорка стала актуальной среди сельчан в те годы.

Так закончился первый этап перехода к капитализму, к рыночной экономике, и закончился он финансовым банкротством государства. Дефолт, подготовленный правительством В.С. Черномырдина и объявленный 17 августа 1998 г. правительством С.В. Кириенко, привел к обвалу национальной валюты. Это произошло через несколько месяцев после деноминации (укрупнения) рубля, проведенной в целях упорядочения денежного обращения и придания большей полноценности национальной валюте. Соотношение рубль/доллар, равнявшееся накануне финансового кризиса 6/1, к концу сентября достигло 18/1.

... Без денег жить можно. Трудно жить без хлеба, молока, мяса. Так же как без воздуха, воды, тепла, света. Должны были наступить те реформы в стране, которые изменили бы ситуацию в сельском хозяйстве в лучшую сторону. Ждать их пришлось долго.

сыерга 3000 кг сөт саву чиген атлап чыга һәм алга таба бара.

90 нчы елларда Татарстанның агросәнәгать комплексы шактый ук нык була. Республика сөт сәнәгате Россия буенча алдынгы позицияләрдә кала. Республика бюджетыннан дәүләт ярдәме белән «Татсельхозхимия» район берләшмәләре ачы туфракларны известьлауны, хуҗалыкларга башка хезмәтләр күрсәтүне дәвам итәләр. Түләүләр аркасында арта барган кыенлыкларга карамастан, «Сельхозтехника»ның район бүлекчәләре эшли бирәләр. Өзеклекләр белән булса да, элеккечә үк ит комбинатлары эшли.

Шулай да Россиядә дә, республикада да авыл хуҗалыгында хәлләр начарая бара. Хезмәт хакын түләүдәге даими тоткарлыклар авыл халкының шәһәрләргә күчүен көчәйтә, җәмәгать секторында да, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда да терлек һәм кошкорт саны кимү дәвам итә. Авыл хуҗалыгы продукциясенең контрольдә тотылмаган һәм фаразланмаслык базары хуҗалыкларны югары нәтиҗәләргә ирешү өчен кызыксындыру чарасы була алмый. Татарстан өчен 1997 елгы рекордлы уңыш та (6 миллион тоннадан артык ашлык), ашлык бәяләре ишелеп төшү сәбәпле, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең финанс хәлен яхшыртмый. Ул елларда «Кытлык – хәсрәт, уңыш – бәла» дигән әйтем авыл халкы арасында актуаль була.

Шулай итеп капитализмга, базар икътисадына күчүнең беренче этабы тәгәлләнә, һәм ул дәүләтнең финанс җәһәтендә бөлгенлеккә төшүе белән тәмамлана. В.С. Черномырдин хөкүмәте әзерләгән һәм 1998 елның 17 августында С. В. Кириенко хөкүмәте тарафыннан игълан ителгән дефолт милли валютаның җимерелүенә китерә. Бу хәл акча әйләнешен тәртипкә салу һәм милли валютага күбрәк тотрыклылык бирү максатыннан үткәрелгән деноминациядән (эреләндерү) соң берничә ай узгач булды. Финанс кризисы алдыннан 6/1 сум тәшкил иткән доллар — рубль нисбәте сентябрь ахырына 18/1 гә җитә.

... Акчасыз яшәп була. Икмәксез, сөтсез, итсез яшәү авыр. Һава, су, җылылык, утсыз кебек үк. Илдә авыл хуҗалыгында вазгыятьне уңай якка үзгәртүче реформалар булырга тиеш иде. Аларны озак көтәргә туры килде.


рыночная
экономика
ПЕРЕСТРОЙКА
ДЕМОКРАТИЯ
ГЛАСНОСТЬ
ПУТЧ
ПАРАД
СУВЕРЕНИТЕТОВ

2000 – 2020 гг.

Агросәнәгать җилкәннәре үзгәреш җилендә

ГЛАВА 6

Ветер перемен – в паруса агропрома

МИНИСТРЫ СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА

Ахметов Марат Готович – работал с мая 1999 г. по сентябрь 2019 г.

Родился в 1954 г. в деревне Хасаншаих Арского района Татарской АССР. Окончил Казанский ветеринарный институт (1976), Саратовскую ВПШ (1990). 1976–1978 гг. – главный ветеринарный врач колхоза им. Чапаева Балтасинского района; 1978–1983 гг. – председатель колхоза «Алга» Балтасинского района; с 1983 г. – второй секретарь, 1985–1990 гг. – первый секретарь Балтасинского райкома КПСС; 1990–1991 гг. – председатель Балтасинского районного Совета народных депутатов; 1991–1999 гг. – глава администрации Балтасинского района. С мая 1999 г. по сентябрь 2019 г. – заместитель Премьер-министра РТ, министр сельского хозяйства и продовольствия РТ. В настоящее время – заместитель Председателя Госсовета Республики Татарстан.

Кандидат сельскохозяйственных наук. Заслуженный работник сельского хозяйства РТ. Лауреат Государственной премии в области науки и техники Республики Татарстан. Награжден орденами Дружбы, «Знак Почета», орденом Почета, серебряной медалью Минсельхоза РФ.

Зяббаров Марат Азатович – работает с сентября 2019 г. по настоящее время.

Заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, министр сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан.

Родился в 1983 г. в г. Чистополь Татарской АССР. Окончил Казанский государственный финансово-экономический институт (2005) по специальности «бухгалтерский учет, анализ и аудит, экономист»; Казанский государственный аграрный университет (2008) по специальности «агрохимия и агропочвоведение», ученый агроном-эколог; Казанский (Приволжский) федеральный университет (2013) по специальности «юриспруденция, юрист».

Трудовую деятельность начал программистом в АФ «Бирюли» Высокогорского района. В 2002 г. – заместитель генерального директора ЗАО «Бирюли». В 2003 г. становится сначала заместителем генерального директора, а затем генеральным директором ОАО Племзавод «Бирюлинский». С 2006 по 2013 г. работает генеральным директором ЗАО «Бирюли».

20.05.2013 – 07.06.2017 – заместитель министра сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан; 08.06.2017 – 05.07.2017 – первый заместитель руководителя исполнительного комитета Буинского муниципального района Республики Татарстан; 06.07.2017 – 13.09.2017 – руководитель исполнительного комитета Буинского муниципального района Республики Татарстан; 15.09.2017 – 18.09.2019 – глава Буинского муниципального района Республики Татарстан.

С 19 сентября 2019 г. по настоящее время – заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, министр сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан.

Заслуженный работник сельского хозяйства Республики Татарстан.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛАРЫ

Әхмәтов Марат Готыф улы 1999 елның маеннан 2019 елның сентябренә кадәр эшли.

1954 елда Татарстан АССРның Арча районы Хәсәншәех авылында туа. Казан ветеринария институтын (1976), Саратов югары партия мәктәбен (1990) тәмамлый. 1976–1978 елларда – Балтач районының Чапаев исемендәге колхозының баш ветеринария табибы; колхоз рәисе; 1978–1983 елларда – Балтач районының «Алга» колхозы рәисе; 1983 елдан КПССның Балтач райкомы икенче секретаре, 1985–1990 елларда – беренче секретаре; 1990–1991 елларда – Балтач районы Халык депутатлары советы рәисе; 1991 – 1999 елларда – Балтач районы хакимияте башлыгы. 1999 елның маеннан 2019 елның сентябренә кадәр – Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры. Хәзерге вакытта – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары. Авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты. Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре. Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты. Дуслык, «Почет билгесе» орденнары, Почет ордены, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының көмеш медале белән бүләкләнә.

Җаббаров Марат Азат улы 2019 елның сентябреннән хәзерге вакытка кадәр эшли.

Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры.

1983 елда Татарстан АССРның Чистай шәһәрендә туган. Казан дәүләт финанс-икътисад институтын (2005) «бухгалтерлык исәбе, анализ һәм аудит, икътисадчы» белгечлеге буенча; Казан дәүләт аграр университетын (2008) агрохимия һәм агротуфрак белеме белгечлеге буенча, галим агроном-эколог буларак; Казан (Идел буе) федераль университетын (2013) юриспруденция, юрист белгечлеге буенча тәмамлый.

Хезмәт эшчәнлеген Биектау районының «Бөреле» АФда программист булып башлый. 2002 елда – «Бөреле» ЯАҖ генераль директоры урынбасары. 2003 елда башта генераль директор урынбасары, аннары «Бөреле» нәсел заводы ААҖ генераль директоры булып эшли. 2006 елдан 2013 елга кадәр «Бөреле» ЯАҖ генераль директоры булып эшли.

20.05.2013 – 07.06.2017 – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары; 08.06.2017–05.07.2017 Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты– җитәкчесенең беренче урынбасары; 06.07.2017–13.09.2017 Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе; 15.09.2017 –18.09.2009 – Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгы.

19.09.2009 елдан бүгенге көнгә кадәр – Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры. Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре.

ФГБУ Россельхозцентр
ФГБУ Россельхозцентр

WHITE SIBERIA

Гости из-за рубежа знакомятся с нашей техникой

На рубеже двух тысячелетий сельское хозяйство России оказалось на краю пропасти. По целому ряду продуктов нас спасал импорт. Страна, имеющая самые большие в мире территории черноземов, не могла накормить саму себя.

Кризисная ситуация сложилась и в агропромышленном комплексе Татарстана. Диспаритет цен после гайдаровской реформы 1992 г. обескровил село. Колхозы и совхозы уже под новыми вывесками оказываются по уши в долгах, банкротятся один за другим. Не на что ремонтировать фермы, нечем отапливать мастерские, нет средств для обновления техники. Зарплата задерживается месяцами. Лучшие работники ищут заработок на стороне…

В Москве будто не замечают этих проблем: финансирование сельского хозяйства практически отсутствует, по-прежнему в ходу лозунг молодых демократов: «Рынок все отрегулирует». В бюджете республики тоже нет таких денег, чтобы закрыть все дыры агропрома.

У ведомства Марата Ахметова, назначенного в 1999 г. министром сельского хозяйства Татарстана, финансовые возможности ограничены. Значит, надо поднимать дух крестьян. Марат Готович объявляет 2000 год годом культа технологий. В последующие годы призывает учиться агробизнесу. Но он понимает: это лозунги, а нужны реальные меры. Неустанно говорит об этом руководству республики.

Постепенно созревает решение привлечь в сельское хозяйство средства крупных инвесторов. Нужны были большие деньги. Кризис углубился настолько, что спасать надо было не от-

Конкурс операторов машинного доения

Меңъеллыклар чигендә Россиянең авыл хуҗалыгы кырга гына түгел, ә упкынның үзенә оча. Күп кенә продуктлар буенча безне читтән товарлар кертү коткарып кала. Дөньяда кара туфраклы иң зур территорияләре булган илне чит ил фермерлары туендыра.

Татарстанның агросәнәгать комплексында да кризис барлыкка килә. Авылда төшенкелек хөкем сөрә. 1992 елгы Гайдар реформасыннан соң бәяләр диспаритеты авылны какшата һәм аның бөтен сокларын эчеп бетерә сыман. Колхозлар һәм совхозлар, инде яңа элмә такталар астында, муеннан бурычка батып, бер-бер артлы бөлгенлеккә төшә. Фермаларны ремонтлау, остаханәләрне җылыту, техниканы яңарту өчен акча юк. Хезмәт хакы айлар буе тоткарлана. Иң яхшы хезмәткәрләр читтә хезмәт хакы эзли…

Мәскәүдә бу проблемаларны күрмәмешкә салышалар: авыл хуҗалыгын финанслау юк диярлек, элеккечә үк яшь демократларның: «Базар барысын да җайга сала» дигән шигаре гамәлдә. Республика бюджетында да агросәнәгатьнең барлык тишекләрен тутырырдай акчалар юк.

1999 елда Татарстан авыл хуҗалыгы министры итеп билгеләнгән Марат Әхмәтовның финанс мөмкинлекләре чикләнгән. Димәк, крестьяннарның рухын күтәрергә кирәк. Марат Готыф улы 2000 елны технологияләр культы елы дип игълан итә. Алдагы елларда агробизнеска өйрәнергә чакыра. Тик ул моның лозунг кына булуын, ә реаль чаралар кирәклеген яхшы аңлый. Бу хакта республика җитәкчелеген армый-талмый искәртеп тора.

Әкренләп авыл хуҗалыгына эре инвесторларны җәлеп итү карары өлгереп килә. Аның өчен

Расцвела гречиха

дельные хозяйства, а всю отрасль. Выбор пал на перерабатывающие предприятия агропромышленного комплекса. Будущим спасителям предполагались большие преференции.

Первым на призыв откликнулся владелец пивоваренного производственного объединения «Красный Восток» Айрат Хайруллин. С его помощью было создано акционерное общество – крупнейший территориальный агрохолдинг, включивший в себя 300 тыс. га земли, сотни сел и деревень, множество разорившихся хозяйств Алькеевского, Зеленодольского, Верхнеуслонсокого, Алексеевского, а затем Спасского, Нурлатского и Рыбно-Слободского районов.

Задача стояла определенная: выйти на современные технологии производства, на мировой уровень. Стали появляться крупные животноводческие комплексы на 4–5 тыс. скотомест: Каргопольский, Макуловский, Чув. Бродский, Левашевский… Сюда со всей Европы свозились племенные нетели самых молочных пород.

Один за другим спасать деревню решают все новые и новые крупные инвесторы: «Вамин», «Золотой колос», ХК «Ак Барс», «Агросила групп»…

зур акчалар сорала. Кризис шулкадәр тирәнәя ки, аерым хуҗалыкларны гына түгел, ә бөтен тармакны коткару ихтыяҗы туа. Сайлап алганда агросәнәгать комплексының эшкәртүче предприятиеләренә игътибар бирелә. Булачак коткаручыларга зур ташламалар карала.

Беренче булып чакыруга «Кызыл Шәрык» сыра кайнату җитештерү берләшмәсе хуҗасы Айрат Хәйруллин кушылды. Аның ярдәме белән акционерлык җәмгыяте – 300 000 гектар җир, йөзләгән авыллар, Әлки, Яшел Үзән, Югары Ослан, Алексеевск, аннары Спас, Нурлат һәм Балык Бистәсе районнарындагы бөлгән хуҗалыкларны үз эченә алган бик зур территориаль агрохолдинг төзелә.

Куелган бурыч билгеле: җитештерүнең заманча технологияләрен үзләштерү, дөнья дәрәҗәсенә күтәрелү. 4–5 мең баш терлеккә исәпләнгән эре терлекчелек комплекслары барлыкка килә башлый: Карга, Макыл, Чуваш Кичүе, Левашево... Бирегә бөтен Европадан иң сөтле токымнардан саналган нәселле таналар кайтарыла.

Авылны коткаруга бер-бер артлы яңадан-яңа инвесторлар алына: «Вамин», «Алтын башак», «Ак Барс» холдинг компаниясе, «Агросила групп

ЦИТАТА

«В развитии сельского хозяйства многое зависит от регионов. Считаю, что нужно дать им больше самостоятельности в определении приоритетов использования федеральных субсидий на поддержку АПК, а сам их объем связать с увеличением пашни, повышением урожайности, других качественных показателей эффективности производства, тем самым создав стимул для ввода в оборот простаивающих сельхозземель и внедрения передовых агротехнологий. Здесь хотел бы подчеркнуть: если мы даем больше самостоятельности в использовании средств федерального бюджета, федеральной поддержки, то и ответственность регионов за результаты и эффективное вложение полученных ресурсов… также должна возрасти».

В.В. Путин

Үзмәшгуль
сәүдә рәте
СУВЕНИР

ТОРГОВЫЙ РЯД
САМОЗАНЯТЫХ
Центр поддержки самозанятых
АНО
САМОЕ
2020

Комбайнеры АО «Агросила»

Это сейчас, по прошествии времени, очевидно, что крупные территориальные агрохолдинги – не самые эффективные формы организации сельского хозяйства. Банкротство «Вамина» и «Золотого колоса» – наглядное тому свидетельство. Но существовал ли в начале 2000-х другой, более правильный выход из ситуации? Вопрос сложный.

…Наступил 2006 г. Спасательным кругом для сельского хозяйства и для села стал Приоритетный национальный проект. В сельское хозяйство из федерального бюджета пошли ощутимые денежные ресурсы. Татарстан активно участвовал в реализации этой программы. Деньги направлялись через уполномоченные банки в виде субсидированных кредитов. Взял кредит – получи господдержку в виде погашения части процентной ставки. Кредиты давали под залог имущества – техники, оборудования, скота. Львиную долю господдержки получили крупные агрохолдинги. Как грибы после дождя стали расти все новые и новые комплексы и мегафермы: «Челны-Бройлер», «Камский Бекон», реконструировались фермы «Вамина», началась модернизация птицефабрик, строились элеваторы, семенные заводы…

В эти годы произошла масштабная модернизация животноводческих ферм: реконструировались коровники, механизировалась дойка – молоко пошло по молокопроводам в танки-охладители, были построены десятки доильных залов. Корма стали завозиться тракторами с кормораздатчиками-смесителями и рас-

» … Хәзер, вакытлар узу белән, эре территориаль агрохолдингларның нәтиҗәле булмавы аермачык күренә. «Вамин» һәм «Алтын башак»ның бөлгенлеккә төшүе – моңа ачык дәлил. Тик 2000 еллар башында ул вакыттагы хәлдән чыгуның тагын да дөресрәк башка юлы бар идеме? Катлаулы сорау.

... 2006 ел җитте. Авыл хуҗалыгы һәм авыл өчен Өстенлекле милли проект коткару чарасы булды. Федераль бюджеттан авыл хуҗалыгына сизелерлек акча ресурслары бүлеп бирелде. Татарстан әлеге программаны тормышка ашыруда актив катнашты. Акчалар вәкаләтле банклар аша субсидияле кредитлар рәвешендә җибәрелде. Кредит алдың – процент ставкасының бер өлешен каплау рәвешендә дәүләт ярдәме ал. Кредитлар техника, җиһазлар, терлек кебек мөлкәтне залог итү бәрабәренә бирелде. Дәүләт ярдәменең зур өлешен эре агрохолдинглар алды. Яңгырдан соң чыккан гөмбәләр шикелле яңадан-яңа комплекслар һәм мегафермалар: «Челны-Бройлер», «Камский Бекон» барлыкка килде, «Вамин» фермалары реконструкцияләнде, кошчылык фабрикаларын модернизацияләү башланды, элеваторлар, орлык заводлары төзелде…

Бу елларда терлекчелек фермаларын киң колачлы модернизацияләүгә ирешелә: сыер абзарлары реконструкцияләнә, савым механикалаштырыла – сөт сөтүткәргечләр буенча танк-суыткычларга китә, дистәләгән сыер саву заллары төзелә. Терлек азыгы азык таратнкычлы-катнаштыргычлы тракторлар белән кертелеп,

Заслуженный агроном РТ Шамиль Ахметзянович Кушмин (ООО «Хаерби» Лаишевского района)

кладываться на кормовые столы. Всего за годы действия Приоритетного национального проекта в Татарстане было построено и модернизировано более 200 комплексов и ферм.

Далее поехали в мою родную деревню Апазово Арского района, там тоже чаепитие, обычаи, традиции можно показать и даже базар организовать, так как Апазово испокон веков была базарной деревней. Дальше Тукай-Кырлай, и вот его уже надо делать по-настоящему. Показать великого Тукая таким, каким он действительно был. Далее Арск, который славился шитьем ичиг. Надо восстановить это знаменитое ремесло. Кроме того, в Арске давно существует педучилище, основательное, с богатой историей, с прекрасной базой. Вот его и можно сделать национальным университетом для подготовки татарских учителей, воспитателей татарских детских садов, учителей начальных школ и т.д. Дальше маршрут продолжается в Атню. Там есть историческая деревня, из которой вышло много видных татарских купцов. Сегодня Атнинская зона – это место, где получают экологически чистую продукцию. После Атни направляемся в сторону Дубъяз и в Казань.

Думаю, этот проект может работать в нескольких направлениях: развивать в республике экологический туризм и поднимать еще выше престиж республики.

түгел. Алга таба – Балтач, аннары 2 километр ераклыкта урнашкан Кара Күл. Үз вакытында колхоз рәисе булып эшләгәндә, биредәге тау битләренә агачлар утырткан идек. Кара Күлдә кунакханә төзергә кирәк булачак. Бер көн Казаннан килерләр, ә кичкә – анда. Җәен биредә су коенырга, кышын тау чаңгыларында шууны оештырырга мөмкин. Иртә белән торгач, Балтачка, район үзәгенә китәргә була – анда Халыклар дуслыгы музее, Мортаза бай йорты, анда да музей булачак ди сөйлиләр, тик ул әлегә буш. Аннары Карадуган авылына китәсе, анда ике катлы йортта берьюлы ике музей урнашкан: берсе – Муса Җәлилгә, икенчесе — Себер тракты тарихына багышлана. Ә бу музейдан бераз югарырак йомры таш түшәлгән юл әле Екатерина II заманыннан ук сакланып калган. Аннары Арча районына минем туган авылым Апазга юл тотабыз – анда да традицион чәй эчүләрне, йолагадәтләребезне күрсәтергә, хәтта базар оештырырга да була, чөнки Апаз элек-электән базарлы авыл иде. Алга таба Тукай-Кырлай, һәм менә аны чын-чынлап эшләргә кирәк. Бөек Тукайны, чыннан да, нинди була алганын күрсәтәсе иде, ә чахоткадан интегүче түбәтәйле ябык бер зат итеп түгел! Алга таба – чигүле читекләре белән дан тоткан Арча. Бу атаклы һөнәрне торгызырга кирәк. Моңардан тыш, Арчада күптән инде бай тарихлы, искиткеч база булган педучилище бар. Менә аны татар укытучылары, татар балалар бакчалары тәрбиячеләре, башлангыч мәктәп укытучылары һ.б. ны әзерләү өчен милли университет итеп эшләргә була. Алга таба маршрут Әтнәгә таба сузыла. Ул районда бик күп күренекле татар сәүдәгәрләре чыккан тарихи авыл бар. Бүген Әтнә зонасы – экологик яктан чиста продукция ала торган урын. Әтнәдән соң Дөбъяз ягына һәм Казанга юнәләбез. Минемчә, әлеге проект берничә юнәлештә – республикада экология туризмын үстерү һәм республиканың абруен тагын да югарырак күтәрү юнәлешләрендә эшли ала.

ЗАЛАКОВ
НАИЛЬ РИНАТОВИЧ

Первый заместитель министра сельского хозяйства и продовольствия РТ

ЗАЛАКОВ
НАИЛ РИНАТ УЛЫ

ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары

СЕГОДНЯ СЕЛЬСКОЕ ХОЗЯЙСТВО – НЕ ТОЛЬКО УКЛАД ЖИЗНИ, НО И ВЫГОДНЫЙ БИЗНЕС

В сельском хозяйстве в общей сложности я работаю 10 лет. Когда в 2009 г. мне предложили возглавить ООО «Агрофирма Ялтау», с удовольствием согласился. Это была очень интересная работа, и мы со своей командой вложили немало усилий, чтобы поднять на должный уровень этот свинокомплекс на 25 тыс. голов. Кроме того, мы занимались выращиванием как кормовых, зерновых, так и технических культур. Только сахарной свеклы было засеяно порядка 3 тыс. га. В 2013 г. стал генеральным директором крупнейшей агрофирмы «Лениногорская» – большое хозяйство в 5 тыс. голов крупного рогатого скота. Надо отметить, что это была очень хорошая профессиональная школа, благодаря которой у меня сформировалось достаточно четкое представление – куда должно развиваться сельское хозяйство Татарстана.

В прошлом году Марат Азатович Зяббаров пригласил меня стать первым заместителем министра. В министерстве очень сильные, опытные заместители, курирующие свои направления. Моя задача – общая координация, внешнее общение с бизнес-структурами, инвесторами, решение проблемных вопросов.

Сельское хозяйство Татарстана – одно из самых успешных в России. В этом, несомненно, заслуга нашего первого Президента Минтимера Шариповича Шаймиева, а также поддержка нашего действующего Президента Рустама Нургалеевича Минниханова. Сегодня не будет преувеличением сказать, что аграрии республи-

Авыл хуҗалыгында мин гомумән алганда 10 ел эшлим. 2009 елда миңа «Ялтау агрофирмасы» ҖЧҖен җитәкләргә тәкъдим иткәч, рәхәтләнеп ризалаштым. Бу бик кызыклы эш булды, һәм без үз командабыз белән 25 башка исәплөнгән әлеге дуңгызчылык комплексын тиешле дәрәҗәгә җиткерү өчен күп көч куйдык. Моннан тыш, без азык, бөртекле культуралар белән бергә, техник культуралар үстерү белән дә шөгыльләндек. Шикәр чөгендере генә дә 3 мең гектарга якын чәчелде. 2013 елда 5 мең баш мөгезле эре терлеккә исәплөнгән зур хуҗалыкның – «Лениногорск» агрофирмасының генераль директоры вазифасына билгеләндем. Әйтергә кирәк, бу бик яхшы һөнәри мәктәп булды, ул миндә Татарстан авыл хуҗалыгының үсешенә карата шактый төгәл күзаллау формалаштырды.

Узган ел Марат Азат улы Җаббаров миңа министрның беренче урынбасары вазифасын тәкъдим итте. Министрлыкта үз юнәлешләренә кураторлык итүче тәҗрибәле, бик көчле урынбасарлар эшли. Минем бурыч – гомуми координацияләү, бизнес-структуралар, инвесторлар белән тышкы аралашу, проблемалы мәсьәләләрне хәл итү.

Татарстанның авыл хуҗалыгы – Россиядә иң уңышлылардан берсе. Һичшиксез, бу – беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең казанышы, шулай ук хәзерге Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнехановның булышлыгы. Бүген республикабыз аграрийлары аякларында нык басып тора дип әйтү дә арты-

БҮГЕН АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ – ТОРМЫШ РӘВЕШЕ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, ТАБЫШЛЫ БИЗНЕС ТА

ки твердо стоят на ногах. У нас есть как крупные и сильные инвесторы, так и развитые крестьянские и фермерские хозяйства, небольшие предприятия. Огромную долю занимают подсобные личные хозяйства.

Сельскохозяйственная отрасль Татарстана диверсифицирована. Мы являемся лидерами по очень многим направлениям и в Российской Федерации, и в Приволжском федеральном округе. Активно развивается сельхозпереработка. Наша задача – становиться более эффективными, идти в ногу со временем, учиться новым технологиям и улучшать экономику каждого хозяйства. В республике много примеров успешных хозяйств и по зарплате работников, и по прибыли. Это возможно только при должном уровне цифровизации, внедрении современных технологий, при умении работать с бюджетом, анализировать предыдущие периоды, находить ошибки и идти дальше.

Очень важный вопрос современного аграрного сектора – это создание новых, современно оснащенных рабочих мест. Сегодня сельское хозяйство – не просто определенный уклад жизни, но и выгодный бизнес. Я убежден, что инициативные молодые люди найдут на селе и интересную работу, и способ заработать. Крестьянский труд – качественный, благородный. Что меня особенно привлекает в нашей работе? То, что мы производим ту продукцию, без которой невозможно жить. И мы каждый день видим результат своего труда.

ру булмас. Бездә зур һәм көчле инвесторлар да, алга киткән крестьян һәм фермер хуҗалыклары да, кечерәк предприятиеләр дә бар. Зур өлешне шәхси ярдәмче хуҗалыклар тәшкил итә.

Татарстанның авыл хуҗалыгы тармагы диверсификацияләнгән. Без Россия Федерациясендә дә, Идел буе округында да бик күп юнәлешләр буенча лидерлар булып торабыз. Авыл хуҗалыгы эшкәртүе актив үсеш ала. Безнең бурыч – нәтиҗәлерәк эшләү, заман белән бергә атлау, яңа технологияләргә өйрәнү һәм һәр хуҗалыкның икътисадын яхшырту. Республикада хезмәткәрләрнең эш хакы буенча да, табыш буенча да уңышлы эшләүче хуҗалыкларның мисалларын күпләп китерергә мөмкин. Бары тиешле дәрәҗәдә цифрлаштыру, заманча технологияләр кертү, бюджет белән эшли белү, алдагы чорларны анализлау, хаталарны табу ярдәмендә генә алга барырга мөмкин.

Хәзерге аграр секторның бик мөһим мәсьәләсе – яңа, заманча җиһазландырылган эш урыннары булдыру. Бүген авыл хуҗалыгы – билгеле бер тормыш рәвеше генә түгел, ә табышлы бизнес та. Инициативалы яшьләр авылда кызыклы эш тә, акча эшләү юлын да табарлар дип ышанам мин. Крестьян хезмәте – сыйфатлы, игелекле хезмәт. Безнең эштә мине шунысы аеруча җәлеп итә – без аннан башка яшәү мөмкин булмаган продукция җитештерәбез. Һәм без көн саен үз хезмәтебезнең нәтиҗәсен күрәбез.

ТАГИРЗЯНОВ ТАЛЬГАТ ГАЛИМЗЯНОВИЧ

Заместитель министра сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан (курирует направление инженерно-технической политики министерства)

ТӘЛГАТЬ ГАЛИМҖАН УЛЫ ТАҺИРҖАНОВ

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары (министрлыкның инженер-техник сәясәте юнәлешенә кураторлык итә)

НАША СТРАТЕГИЧЕСКАЯ ЗАДАЧА – ВНЕДРЕНИЕ «УМНОЙ» СЕЛЬХОЗТЕХНИКИ

Сельское хозяйство — это одна из экономических основ Татарстана. Мы ведем активную работу над укреплением лидирующей позиции Агропромышленного комплекса республики в России. Стремимся к технологическому прогрессу, модернизации отрасли, росту темпов производства.

Процесс стартовал в 2000-е годы, когда началось серьезное техническое перевооружение отрасли – постепенный переход на новые модели тракторов, комбайнов. Этому предшествовало тщательное изучение опыта зарубежных передовых хозяйств. Нужно отметить, что в основе технологических нововведений АПК Татарстана лежат разработки специалистов Бразилии, Канады и Австралии.

Первым неоспоримым результатом реновации стал стремительный рост производительности труда. К примеру, в 1970-е годы я сам работал на комбайне «Нива». Раньше, чтобы быть передовиком в районе, нужно было намолоть 1 тыс. тонн зерна. Сегодня современный комбайн способен убрать 4–6 тыс. тонн. Если прежние жатки, управляемые хорошим механизатором, в день обрабатывали 10–15 га земли, то сегодня широкие жатки с рабочей шириной до 9 м могут на высокой скорости скосить за это же время 100 га.

В начале 2000-х годов на одного работника приходилось по 60–70 тыс. руб. продукции. Сказывались последствия экономического кризиса

Авыл хуҗалыгы – Татарстанның икътисади нигезләренең берсе. Без Россиядә республика агросәнәгать комплексының алдынгы позициясен ныгыту өстендә актив эш алып барабыз. Технологик алгарышка, тармакны модернизацияләүгә, житештерү темплары үсүенә омтылабыз.

Процесс 2000 нче елларда, тармакны җитди рәвештә техник яктан яңадан коралландыруга – әкренләп тракторларның һәм комбайннарның яңа модельләренә күчүгә керешкәч башланып китте. Моңа кадәр чит илләрдәге алдынгы хуҗалыкларының тәҗрибәсе җентекләп өйрәнелде. Татарстан агросәнәгать комплексының технологик яңалыклары нигезендә Бразилия, Канада һәм Австралия белгечләре эшләнмәләре ятуын билгеләп үтәргә кирәк.

Реновациянең, ягъни яңартылуның беренче бәхәссез нәтиҗәсе хезмәт җитештерүчәнлегенең ыргылышлы үсешеннән гыйбарәт иде. Мисал өчен, 1970 елларда мин үзем «Нива» комбайнында эшләдем. Элек районда алдынгы булу өчен 1 мең тонна ашлык суктырырга кирәк иде. Бүгенге көндә заманча комбайн 4-6 мең тонна җыеп алырга сәләтле. Әгәр яхшы механизатор идарә иткән элекке ургычлар көнгә 10-15 гектар җир эшкәртсә, бүген 9 метр киңлектәге киң ургычлар югары тизлек белән шул ук вакыт эчендә100 гектарны чабып чыга ала.

СТРАТЕГИК БУРЫЧЫБЫЗ – «АКЫЛЛЫ» АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ТЕХНИКАСЫН ГАМӘЛГӘ КЕРТҮ

в России 90-х, девальвация, дефолт. Сейчас денежная выручка составляет 300 тыс. руб. на одного работника. Цифры несопоставимые!

Приведем еще один показательный пример. Чтобы получить хороший урожай, надо обеспечить равномерный сев на нужную глубину. Раньше использовался специализированный агрегат с одним механизатором и тремя сеяльщиками. Все вместе они могли засеить по 30 га земли. Сегодня один большой современный трактор тянет целый посевной комплекс, а там – все необходимые удобрения и семена. Он один засевает до 200 га. То есть было занято 4 человека с производительностью 30 га, а сейчас 1 механизатор – и результат в 200 га.

В свое время мне пришлось внедрять в хозяйствах и машинную дойку. Всей технологии нас отлично обучали в институте. У нас были замечательные преподаватели на факультете механизации: Мудров Петр Григорьевич, Митряев Николай Игнатьевич, Яхин Мирбат Ахметович. Авторитетные специалисты, настоящие ученые, которых знали во всем Советском Союзе.

Так вот, при ручной дойке за одной дояркой, как правило, закреплялось 18–20 коров. У бедных женщин болели руки, самая распространенная напасть для них – ревматизм. Когда внедрили машинную дойку, доярки стали доить по 30–35 коров. В 2000-е годы после установки на фермах молокопроводов и доильных аппаратов – по 50 коров. Дальше – больше. Мы

2000 нче еллар башында бер хезмәткәргә 60-70 мең сум продукция туры килде. Килеп туган әлеге хәлдә Россиядәге 90 нчы елларда булган икътисади кризис нәтиҗәләре, девальвация, дефолт чагылыш тапты. Хәзерге вакытта бер хезмәткәргә акчалата керем 300 мең сум тәшкил итә. Саннар чагыштырырлык түгел!

Тагын бер гыйбрәт алырлык мисал китерик. Яхшы уңыш алу өчен тиешле тирәнлеккә тигез чәчүне тәэмин итәргә кирәк. Элек бер механизатор һәм өч чәчүче хезмәт күрсәткән махсус агрегат файдаланылды. Алар барысы бергә 30 ар гектар җир чәчә алдылар. Бүген бер зур заманча трактор тулы бер чәчү комплексын тарта, ә анда кирәкле барлык ашламалар һәм орлыклар бар. Ул берүзе 200 гектарга кадәр чәчә. Ягъни, элек 4 кеше 30 гектарда чәчсә, хәзер 1 механизатор 200 гектарда чәчү эшләрен башкара.

Үз вакытында миңа хуҗалыкларда машина белән сыер савуны да гамәлгә кертергә туры килде. Институтта бөтен технологияне бик яхшы укыттылар. Бездә механикалаштыру факультетында гаҗәеп укытучылар бар иде: Петр Григорьевич Мудров, Николай Игнатьевич Митряев, Мирбат Әхмәт улы Яхин. Абруйлы белгечләр, чын галимнәр, аларны бөтен Советлар Союзында беләләр иде.

Кагыйдә буларак, кул белән сауганда бер савымчыга 18-20 сыер беркетелде. Бичара хатын-кызларның куллары сызлый, алар киң таралган ревматизмнан интектеләр. Машина белән

стали строить доильные залы «Карусель». Это система предназначается для крупных хозяйств и мегаферм, где существенно сокращен ручной труд. Тут уже на одну доярку приходится по 200 коров. А самое главное, работа превратилась из физически тяжелой в автоматизированную. Сейчас на современных фермах чисто, светло, воздух вентилируется. Успешно развиваются комплексы, где уже не требуется обслуживания доярок. Если раньше в животноводстве крупного рогатого скота применяли различные способы мечения: клеймение, татуировка, биркование, ошейники, краска, то сейчас каждой корове вживляют микрочип. Это позволяет роботам отслеживать все этапы жизни животного и регулировать количество комбикорма в соответствии с результатами удоя. В этих комплексах нужна слаженная работа IT-инженеров. При условии высокоэффективной и интенсивной работы возможность доения в час достигает 700 коров. Как результат, сейчас животноводчество республики занимает по уровню производительности

савуны кулланышка керткәч, сыер савучылар 30-35 сыер сава башладылар. 2000 нче елларда фермаларда сөтүткәргечләр һәм саву аппаратлары урнаштырылганнан соң 50 шәр сыер саудылар. Алга таба бу күрсәткеч арта барды. Без «Карусель» саву залларын төзи башладык. Бу система кул хезмәте шактый азайган эре хуҗалыклар һәм мегафермалар өчен каралган. Аларда бер савымчыга 200 әр сыер туры килә. Ә иң мөһиме – авыр физик эшне автоматлаштырылган хезмәт алыштырды. Хәзер заманча фермаларда чисталык хөкем сөрә, якты, һава җиллләтелә. Сыер савучылар хезмәте таләп ителмәгән комплекслар уңышлы үсеш кичерә. Элек терлекчелектә мөгезле эре терлекләрне тамгалауда төрле ысуллар – келәймә сугу, татуировка төшерү, тамга асу, муенчак кидерү, буяу сөртү кулланылса, хәзер һәр сыерга микрочип куела. Бу роботларга терлекләр тормышының барлык этапларын күзәтеп торырга һәм, савым нәтиҗәләренә карап, катнаш азыкның күләмен көйләргә мөмкинлек бирә. Әлеге комплекслар-

труда лидирующие позиции в Приволжском федеральном округе и по всей стране.

Для меня как человека, выросшего в деревне, знающего не понаслышке, что такое кропотливый крестьянский труд и что такое старая техника, всегда было очевидно: важно облегчить жизнь труженика. Наша стратегическая задача в условиях развития технологий – это своевременно реагировать и внедрять все необходимые новшества и разработки в производственный процесс. Сейчас активно ведем работу по переводу всей нашей технической базы на самое экономичное топливо, требующее минимальных затрат, – метан.

Большим достижением является то, что наши комбайны стали «умными». В кабине современного комбайнера нешумно, функционирует кондиционер. Комбайнер сегодня работает не в грязной спецовке и в рабочих ботинках, а в чистой рубашке, белых носках и тапочках. И заработную плату он получает достойную – по 150–200 тыс. руб. в сезон.

Для выявления лучших комбайнеров республики Министерством сельского хозяйства и продовольствия Татарстана ведется постоянный мониторинг. Только за 2019 г. мы определили 500 лучших комбайнеров. Информация об участниках жатвы публиковалась на официальном сайте министерства и обновлялась в течение всей уборочной кампании. Комбайнеры, достигшие наивысших результатов в 2019 г., были награждены премией в 60 тыс. руб. Кроме того, ежегодно проводится конкурс на призы Президента Республики Татарстан для передовых трактористов, комбайнеров и других механизаторов с целью поощрения участников уборки урожая.

У нас всегда было понимание: хозяйствам необходима качественная техника, которая обслуживается, проходит дефектовку осенью, сразу же после полевых работ. Работая в период перемен, в 90-е годы, перед руководством министерства мы ставили условие, чтобы просубсидированная техника была куплена только у основного дилера. Именно тогда была организована инновационная система продаж. Уже тогда было понимание, что дилер должен находиться на территории Республики Татарстан, должен быть здесь зарегистрирован, и работать должны специально обученные, прошедшие экзамен и сертификацию татарстанцы. Как результат, мы получили систему, в которой в течение одних суток любая техника может быть восстановлена.

да IT-инженерларның эше җайга салынуы кирәк. Югары нәтиҗәле һәм интенсив эш шартларында сәгатенә 700 сыер саву мөмкинлеге бар. Нәтиҗә буларак, хәзер республика терлекчелеге хезмәт җитештерүчәнлеге дәрәҗәсе буенча Идел буе федераль округында һәм бөтен ил буенча алдынгы урында тора.

Авылда туып-үскән, крестьян хезмәтенең нәрсә икәнлеген һәм иске техниканың нәрсә икәнлеген ишетеп кенә түгел, якыннан белүче кеше буларак, хезмәт кешесенең тормышын җиңеләйтүнең мөһимлеген мин һәрчак ачык аңлый идем. Технологияләрне үстерү шартларында безнең стратегик бурычыбыз – җитештерү процессына кирәкле барлык яңалыкларга һәм эшләнмәләргә үз вакытында игътибар итү һәм аларны гамәлгә кертү. Хәзерге вакытта үзебезнең барлык техник базабызны минималь чыгымнар таләп иткән иң бәрәкәтле ягулыкка күчерү буенча актив эш алып барабыз.

Безнең комбайннарның «акыллы» булуы – зур казанышыбыз. Комбайнчының заманча кабинасында тавышлы түгел, кондиционер эшли. Бүген комбайнчының өстендә – пычрак махсус кием һәм эш ботинкалары түгел, чиста күлмәк, ак оекбашлар һәм башмаклар. Хезмәт хакы да лаеклы – сезонга 150-200 мең сум ала.

Республиканың иң яхшы комбайнчыларын ачыклау өчен Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан даими мониторинг алып барыла. 2019 елда гына да без 500 иң яхшы комбайнчыны ачыкладык. Уракта катнашучылар турындагы мәгълүмат министрлыкның рәсми сайтында күрсәтелде һәм урып-җыю кампаниясе дәвамында яңартылып барылды. 2019 елда иң югары нәтиҗәләргә ирешкән комбайнчылар 60 мең сумлык премия белән бүләкләнде. Моннан тыш, ел саен урып-җыюда катнашучыларны бүләкләү максатында алдынгы тракторчылар, комбайнчылар һәм башка механизаторлар өчен Татарстан Республикасы Президенты призына конкурс үткәрелә.

Без һәрвакыт хуҗалыкларга хезмәт күрсәтелә, көзен, кыр эшләреннән соң ук дефектлана торган сыйфатлы техника кирәклеген аңлап эш иттек. Үзгәрешләр чорында, 90нчы елларда, министрлык җитәкчелеге алдына субсидияләнгән техниканың бары тик төп дилердан гына сатып алынуы шартын куйдык. Нәкъ менә шул вакытта сатуның инновацион системасы оештырылды. Ул чакта ук дилерның Татарстан Республикасы территориясендә булырга һәм аның монда теркәлергә тиешлеген, махсус өйрәтелгән, имтихан һәм сертификация узган татарстанлылар

В результате на нашей территории появились свои заводы сельхозмашиностроения, например, «Кузембетьевский РМЗ», «Агромастер», «Казаньсельмаш». Все эти производства участвуют в федеральных программах. Татарстанская техника поставляется не только в Татарстан, но и в другие регионы России и даже за рубеж.

Ежегодно проводим две значительные выставки – «ТатАгроЭкспо-2020» и традиционный «День поля». В процессе демонстрации техники показывается ее работа в условиях основной и предпосевной обработки почвы, внесения минеральных и органических удобрений, химической защиты растений, орошения, сбора урожая. Это по-настоящему уникальная возможность для работников сельского хозяйства и руководителей познакомиться и сравнить в действии потенциал техники для сельскохозяйственных работ от разных производителей, а также получить консультации специалистов по агротехнологиям.

С 2008 г. в республике активно развивается «Программа государственной поддержки технической и технологической модернизации сельскохозяйственного производства («40 на 60»)». По программе 40% субсидируется Правительством РТ покупка новой, не бывшей в употреблении сельскохозяйственной техники, это трактора, комбайны, плуги, жатки, кормораздатчики и т.п. Оставшиеся 60% стоимости оплачивает сельхозпроизводитель.

Мечта у нас, инженеров, одна – более надежные и совершенные машины. Мы продолжаем модернизировать и развивать конкурентоспособную техническую и технологическую базу АПК Республики Татарстан.

эшләргә тиеш икәнлеген аңлый идек. Нәтиҗәдә без бер тәүлек эчендә теләсә нинди техника торгызылырга мөмкин булган системага ия булдык, территориябездә үзебезнең авыл хуҗалыгы машиналарын төзү заводлары, мәсәлән, «Хуҗәмәт РМЗ», «Агромастер», «Казансельмаш» барлыкка килде. Бу производстволарның барысы да федераль программаларда катнаша. Татарстан техникасы Татарстан буенча гына түгел, Россиянең башка төбәкләренә дә, хәтта чит илләргә дә җибәрелә.

Ел саен ике зур күргәзмә – «ТатАгроЭкспо» һәм традицион «Кыр көне» үткәрәбез. Аларда техниканың туфракны төп һәм чәчү алдыннан эшкәртү, минераль һәм органик ашламалар кертү, үсемлекләрне химик яклау, сугару, уңыш җыю шартларында эшләве күрсәтелә. Бу – авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре һәм җитәкчеләр өчен төрле җитештерүчеләр тарафыннан эшләнгән авыл хуҗалыгы техникасының потенциалы белән танышу һәм аны гамәлдә чагыштыру, шулай ук агротехнологияләр буенча белгечләрдән консультацияләр алу өчен уникаль мөмкинлек.

2008 елдан республикада авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләүгә дәүләт ярдәме программасы актив үсеш кичерә («60 ка 40»). 40% программасы буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан яңа, куллануда булмаган авыл хуҗалыгы техникасы (тракторлар, комбайннар, сабаннар,ургычлар, азык тараткычлар һ.б.) сатып алу субсидияләнә. Бәянең калган 60 % ын авыл хуҗалыгы җитештерүчесе түли.

Безнең, инженерларның, хыялы бер – ышанычлырак һәм камилрәк машиналар. Без Татарстан Республикасы аграр сәнәгать комплексының көндәшлеккә сәләтле техник һәм технологик базасын модернизацияләүне һәм үстерүне дәвам итәбез.

ГАБДРАХМАНОВ ИЛЬДУС ХАРИСОВИЧ

Заместитель министра сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан (курирует направление земледелия)

ИЛДУС ХАРИС УЛЫ ГАБДРАХМАНОВ

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары (игенчелек юнәлешенә кураторлык итә)

РАБОТА НА ЗЕМЛЕ НЕ ТЕРПИТ ПОТРЕБИТЕЛЬСКОГО ОТНОШЕНИЯ

Растениеводческая отрасль АПК занимает особое положение в экономике Татарстана как одна из основополагающих отраслей народного хозяйства, определяющих жизнедеятельность и продовольственную безопасность.

Надо сказать, в начале 2000-х годов наблюдалось определенное безразличие к земледелию со стороны многих руководителей, даже было ощущение какой-то безысходности. Сегодня отношение специалистов отрасли меняется в лучшую сторону. Мы проводим много мероприятий, которые призваны разъяснять актуальные вопросы: зональные семинары, учеба. Если раньше посещение таких встреч было больше обязаловкой, то сейчас люди уже знают, сколько полезного, ценного можно узнать здесь. Люди понимают: сегодня время простого производства уже прошло, нужен особый подход, требуется учитывать особенности экономики на селе.

Иногда меня спрашивают: «Вам не жалко колхозы?». Почти десять лет я работал председателем колхоза в Кукморском районе. Колхоз – это психология «все наше, общее». В настоящее время на селе существуют разные формы хозяйствования – это и фермерские хозяйства, и акционерные общества, и общества с ограниченной ответственностью. Мы имеем очень хорошие примеры, когда на базе бывших колхозов, где было «все наше», появились адекват-

Агросәнәгать комплексының үсемлекчелек тармагы, халык хуҗалыгының төп тармакларыннан берсе буларак, Татарстан икътисадында аерым урын алып тора.

Әйтергә кирәк, 2000 нче еллар башында күп кенә җитәкчеләр тарафыннан игенчелеккә карата билгеле бер битарафлык күзәтелде, хәтта котылгысызлык хисе дә бар иде. Бүген тармак белгечләренең мөнәсәбәте яхшы якка үзгәрә. Без актуаль мәсьәләләрне аңлатуга юнәлдерелгән күп кенә чаралар – зона семинарлары, төрле укулар уздырабыз. Әгәр элек мондый очрашуларга бару мәҗбүри булса, хәзер кешеләр бирелә күпме файдалы, кыйммәтле нәрсә белергә мөмкин икәнлеген беләләр. Кешеләр аңлыйлар – бүген гади җитештерү вакыты узды инде, мәсьәләгә аерым якын килү кирәк, авылда икътисад үзенчәлекләрен исәпкә алу таләп ителә.

Кайчагында миннән: сезгә колхозлар кызганыч түгелме, дип сорыйлар. Ун елга якын Мин Кукмара районында колхоз рәисе булып эшләдем. Колхоз – «барысы да безнеке, уртак» психологиясе ул. Хәзерге вакытта авылда хуҗалык итүнең төрле формалары – фермер хуҗалыклары да, акционерлык җәмгыятьләре дә, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр дә бар. Элеккеге «барысы да безнеке» булган колхозлар җирлегендә территорияләрнең иминлеге, кешеләрне мөмкин

ҖИР ҮЗЕН КАДЕРЛӘГӘННЕ ЯРАТА

ные собственники, хозяева, думающие о благополучии территорий, об обеспечении как можно большего количества людей рабочими местами.

Можно сказать, работа на земле требует серьезного, профессионального подхода и не терпит потребительского отношения. Сегодня пришла новая плеяда инвесторов, которые уже несколько по-иному стали относиться к земле. В республике мы видим большие перспективы в этих направлениях. Например, последние 7–8 лет мы активно ведем Программу биологизации земледелия. Она предусматривает более активное использование биологических препаратов и удобрений, выращивание сидеральных культур, увеличение площадей под многолетние травы и их систематическое обновление. Все это призвано улучшить плодородность земель в республике, повысить урожайность. Если раньше в Татарстане площадей сидеральных культур практически не было, то в этом году мы имеем 80 тыс. га. А в ближайшие годы все пары должны быть сидеральными. В Татарстане в качестве основных культур сидерального пара используются горчица белая, редька масличная, донник. Рекомендуем такую культуру, как фацелия. После них урожайность на этих полях вырастает на 20–25%. Органики получается 25,0–30,0 тонн на га. В результате почва меняет структуру, получает необходимые элементы питания.

кадәр күбрәк эш урыннары белән тәэмин итү турында уйлаучы адекват милекчеләр, хуҗалар барлыкка килүнең яхшы мисаллары бар.

Җирдә эшләү җитди, профессиональ якын килүне таләп итә һәм кулланучылар мөнәсәбәтенә түзә алмый. Бүген җиргә башкача карый башлаган инвесторларның яңа буыны килде. Республикада без бу юнәлештә зур перспективалар күрәбез. Мәсәлән, соңгы 7-8 елда без игенчелекне биологияләштерү программасын актив алып барабыз. Ул биологик препаратларны һәм ашламаларны активрак куллануны, сидераль культуралар үстерүне, күпьеллык үләннәр мәйданнарын арттыруны һәм аларны системалы яңартуны күздә тота. Болар барысы да республикада җирләрнең уңдырышлылыгын яхшыртырга, уңышны арттырырга тиеш. Элек Татарстанда сидераль культуралар мәйданнары юк диярлек иде, быел ул культуралар 80 мең гектар били, ә якындагы елларда барлык пар җирләре дә сидераль булырга тиеш. Татарстанда сидераль парның төп культуралары сыйфатында ак горчица, майлы торма, тәкәмөгез кулланыла. Фацелия культурасын да чәчәргә тәкъдим иттәбез. Алардан соң бу басуларда уңыш 20-25 процентка арта. Органика бер гектарга 25,0-30,0 тонна чыга. Нәтиҗәдә туфрак структурасын үзгәртә, кирәкле туклану элементлары ала.

В республике для развития животноводства мы также имеем полмиллиона гектаров многолетних трав. И один раз в четыре года рекомендуем обновление этих трав. Ежегодно выращивается около 200 тыс. га рапса, сои, гороха, они также улучшают почву.

Вырастить хороший хлеб без профессиональной защиты невозможно. Сегодня мы ведем интегрированную защиту, т.е. совмещаем химические препараты с биологическими. Они очень эффективно работают, снижая нагрузку на экосистему территории.

Еще одним направлением нашей работы являются противоэрозионные, влагосберегающие мероприятия. В республике ежегодно высаживается около 3 тыс. га лесных противоэрозионных насаждений, чтобы приостановить процесс эрозии почвы. И самое главное – сейчас все больше понимаем необходимость перехода на разноглубинную обработку почвы без оборота пласта. Я выпускник сельскохозяйственного вуза 80-х годов, и помню, как нас учили важности классической пахоты. Сейчас, имея за плечами большой аграрный опыт, я против классической пахоты. И с каждым годом все больше убеждаюсь в этом.

За последние годы реализуются масштабные целевые программы по восстановлению орошаемых земель и гидротехнических сооружений. Благодаря этим усилиям в Татарстане система

Республикада терлекчелек үсеше өчен ярты миллион гектарда күпьеллык үләннәр үстерелә. Дүрт елга бер тапкыр бу үләннәрне яңартырга киңәш итәбез. Ел саен 200 мең гектарга якын рапс, соя, борчак үстерелә, алар шулай ук туфракны яхшырталар.

Профессиональ дәрәҗәдә саклаудан башка сыйфатлы икмәк үстерү мөмкин түгел. Бүген без интеграцияләнгән чаралар, ягъни химик һәм биологик препаратларны чиратлаштырып кулланабыз. Алар, территория экосистемасына йөкләнешне киметеп, югары нәтиҗә бирәләр.

Безнең эшебезнең тагын бер юнәлеше – эрозиягә каршы юнәлдерелгән, дым саклау чаралары. Республикада ел саен, туфракта эрозия процессын туктату өчен, 3 мең гектарга якын урман утыртыла. Һәм иң мөһиме – хәзер катлам әйләнешеннән башка туфракны төрлечә тирәнәйтүгә күчү кирәклеген ныграк аңлыйбыз. Мин 80 нче елларда авыл хуҗалыгы вузын тәмамлаган идем, классик сөрүнең мөһимлеген ничек өйрәтүләрен хәтерлим. Хәзер инде шактый бай аграр тәҗрибә тупланды, һәм мин классик сөрүгә каршы. Һәм моңа елдан-ел күбрәк инанам.

Соңгы елларда сугарулы җирләрне һәм гидротехник корылмаларны торгызу буенча масштаблы максатчан программалар тормышка ашырыла. Бу тырышлыклар нәтиҗәсендә, Татарстанда мелиорация системасы сакланып

мелиорации не только сохранена, но и ежегодно укрепляется и продолжает развиваться.

В нашей республике 42% почвы разной степени кислотности. Но мы смогли удержать ситуацию еще с советских времен, и Татарстан является одним из немногих субъектов России, где работает программа известкования. В этом году мы поставили цель произвестковать почву 80 тыс. га, а к 2024 г. – 100 тыс. га. Это тоже относится к мерам по улучшению и сохранению плодородного состояния почвы Татарстана.

Урожайность зависит во многом от семенного фонда. В Татарстане предел 50% пашни занимают зерновые культуры. В этом направлении активно помогают Татарский научно-исследовательский институт сельского хозяйства со своими сортовыми семенами и ассоциация «Элитные семена Татарстана», производя и реализуя свою продукцию аграриям не только Татарстана. В целом выстроена эффективная система семеноводства. В составе ассоциации свыше 40 хозяйств, которые хорошо технически оснащены и специализируются на выращивании и поставке семенного материала.

Сейчас мы достигли такого уровня знания и понимания земледелия, что ставим вопрос о необходимости управления формированием урожая на каждой стадии вегетации культур. Лаборатория диагностирует, чего не хватает для получения высокой урожайности. Я бы сравнил это с первыми месяцами жизни новорожденного младенца: если ему не хватает каких-то витаминов и микроэлементов, он может заболеть, например рахитом. Так и растения на всех этапах своего роста и созревания требуют постоянного мониторинга. Такие же технологические мероприятия проводятся и на полях, где выращиваются корма для животноводства. В Татарстане они занимают 1 млн га.

Часто бывая в хозяйствах, беседуя с руководителями и агрономами, видишь и творческий подход, и системность в технологической практике земледелия республики. Очень важен человеческий фактор. Мне кажется, в 90-е годы в газетах и по телевидению создавался непривлекательный образ труженика села. Если ты не уезжаешь в город, а остаешься на селе – ты почти неудачник. Именно отсюда произрастают корни существующей и поныне проблемы с кадрами. Сельскохозяйственной отрасли по-прежнему нужны не только высококлассные специалисты, но и механизаторы. Очень важно заинтересовать, поддержать на местах молодых людей, чтобы они посвятили важному для общества труду свою жизнь.

кына калмыйча, елдан-ел ныгый һәм үсә бара.

Республикабызда төрле дәрәҗәдәге ачы туфрак 42% тәшкил итә. Әмма без хәлне совет чорыннан ук саклап кала алдык, Татарстан – Россиянең известьлау программасы эшли торган бик аз субъектларының берсе. Быел без 80 мең га, ә 2024 елга 100 мең га җирне эшкәртү максатын куйдык, бу да Татарстан туфрагының уңдырышлылыгын яхшырту һәм саклау чараларына кагыла.

Уңыш күп очракта орлык фондына бәйле. Татарстанда сөрүлек җирләренең 50 % ын бөртекле культуралар били. Бу юнәлештә Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты, «Татарстанның элиталы орлыклары» ассоциациясе актив ярдәм итә. Тулаем алганда, орлыкчылыкның нәтиҗәле системасы төзелгән. Ассоциация составында 40 тан артык хуҗалык керә, алар техник яктан яхшы җиһазландырылган, орлык материалы үстерү һәм аның белән тәэмин итү буенча специальләшә.

Хәзер безнең игенчелек буенча белемнәребез югары дәрәҗәгә күтәрелде, шуңа күрә культуралар вегетациясенең һәр стадиясендә уңыш формалаштыру белән идарә итү кирәклеге мәсьәләсен куябыз. Лаборатория югары уңыш алу өчен нәрсә җитмәвен тикшерә. Мин моны яңа туган сабыйның беренче айлары белән чагыштырыр идем: әгәр аңа витаминнар һәм микроэлементлар җитми икән, ул, әйтик, рахит белән авырырга мөмкин. Шулай итеп, үсемлекләр дә үсешнең һәм өлгерүнең барлык этапларында да даими мониторинг таләп итә. Терлекчелек өчен азык үстерелә торган басуларда да шундый ук технологик чаралар үткәрелә. Татарстанда алар 1 млн. га мәйдан били.

Хуҗалыкларда еш булу, җитәкчеләр, агрономнар белән сөйләшү нәтиҗәсендә иҗади якын килү дә, республика игенчелегенең технологик практикасындагы системалылык та аермачык күренә. Кеше факторы бик мөһим. Миңа калса, 90 нчы елларда газеталарда һәм телевидение аша авыл хезмәтчәненең күңелгә бик үк хуш килмәслек образы тудырылды. Әгәр дә шәһәргә китмичә, авылда каласың икән – син бәхетсез диярлек. Нәкъ менә шуннан хәзер дә актуаль кадрлар проблемасы үсеп чыга. Авыл хуҗалыгы тармагына элеккечә үк югары квалификацияле белгечләр генә түгел, механизаторлар да кирәк. Гомерләрен җәмгыятебез өчен әһәмиятле хезмәткә багышласыннар өчен урыннарда яшьләрне кызыксындыру, аларга ярдәм итү бик мөһим.

OSTSELMASH
STOP
ЖХТ 9-18

ХАБИПОВ РИШАТ РАШИТОВИЧ

Заместитель министра сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан (курирует развитие фермерских и малых форм хозяйствования)

РИШАТ РӘШИТ УЛЫ ХӘБИПОВ

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары (фермерлык һәм хуҗалык итүнең кече формалары үсешенә кураторлык итә)

ЭКОЛОГИЯ БУДУЩЕГО НАЧИНАЕТСЯ С СЕЛЬСКОГО УКЛАДА ЖИЗНИ

Если рассуждать глобально, то в чем смысл, в чем цель всей нашей работы? Помогая людям обрести «экологическое» мышление, мы словно возвращаем их к истокам, к исконным традициям уклада семьи и жизни. Это и называется «сельский уклад жизни». Многие программы государственной поддержки фермерских и малых хозяйств направлены на то, чтобы люди жили на земле и жили счастливо.

Экономика, статистика доходов фермеров и сельских частников в последние годы радует. В Татарстане сейчас 455 тыс. (!) личных хозяйств, расположенных в 43 муниципальных, в 911 сельских поселениях. В этих поселениях проживает более 900 тыс. татарстанцев, это почти четвертая часть республики. Вот такая армия, такой ресурс нашей земли. Особенно радует, что все больше молодежи остается на земле.

Ликвидный бизнес – лучший стартовый капитал, которым молодые знают, как управлять. В республике есть удивительные семьи, главы которых в 90-е годы были первыми фермерами, а сейчас уже внуки «встали к плугу». Например, легендарная семья Аппаковых. Владимир Аппаков был, можно сказать, первым фермером в Татарстане, сейчас его хозяйство кормит Нижнекамск, Елабугу, Набережные Челны, его продукцию приобретает известный концерн «Махеев». И таких династий много: Сахиповы, Мадьяровы, Миникановы...

Мы очень гордимся темпами развития малых хозяйств в Татарстане и, конечно, в этом огром-

Глобаль фикер йөрткәндә, барлык эшебезнең мәгънәсе нәрсәдә? Кешеләргә «экологик» фикерләүгә ирешүгә ярдәм итеп, без аларны гаилә һәм тормыш рәвешенең башлангычларына, чын традицияләренә кайтарабыз сыман. Бу «авыл тормышы рәвеше» дип атала да инде. Фермерларга һәм кече хуҗалыкларга дәүләт ярдәме күрсәтү буенча күп кенә программалар кешеләр җирдә яшәсен һәм бәхетле яшәсен өчен юнәлтелгән.

Фермерларның һәм авылдагы хосусый милекчеләрнең икътисады, керемнәре статистикасы соңгы елларда сөендерә. Татарстанда хәзер 43 муниципаль районда, 911 авыл җирлегендә урнашкан 455 мең шәхси хуҗалык (!) бар. Әлеге җирлекләрдә 900 меңнән артык татарстанлы яши, бу республиканың дүрттән бер өлеше диярлек. Менә шундый армия, безнең җирнең ресурсы шундый. Бигрәк тә яшьләрнең җирдә калуы куандыра.

Отышлы бизнес – иң яхшы старт капиталы, яшьләр аның белән ничек идарә итәргә икәнен беләләр. Республикада башлыклары 90 нчы елларда беренче фермерлар булган гаҗәеп гаиләләр бар, ә хәзер инде аларның оныклары «сабан башына» җигелде. Мәсәлән, Аппаковларның легендар гаиләсе. Владимир Аппаков, әйтергә кирәк, Татарстанда беренче фермер иде, хәзер аның хуҗалыгы Түбән Кама, Алабуга, Яр Чаллыны тукландыра, аның продукциясен танылган «Махеев» концерны алдыра. Мондый династияләр шактый: Сәхиповлар, Мадьяровлар, Миңнехановлар...

КИЛӘЧӘКНЕҢ ЭКОЛОГИЯСЕ АВЫЛ ТОРМЫШЫННАН БАШЛАНА

ная заслуга руководства республики. Первый Президент РТ М.Ш. Шаймиев в трудные годы на всех совещаниях с какой-то огромной личной болью обращался к нам: «Спасите деревню, не дайте земле погибнуть».

По программам господдержки в год выделяются миллиарды рублей на кредитование, гранты. И они дают накопительный, синергетический, буквально «взрывной» эффект: село оживает, становится полем для бизнеса, стартапов!

С 2010 г. в Татарстане стали работать программы господдержки развития фермерства и животноводческих ферм, государством выделялось по 500 тыс. руб. на развитие ферм по крупнорогатому скоту, до 1 млн руб. – на строительство молочных ферм. В этом году 300 человек подали документы на грантовую поддержку, 136 человек – как начинающие фермеры, 50 человек – на развитие семейных ферм. Каждый год республика выделяет больше и больше денег на эту сферу, а фермерские хозяйства становятся все более технологичными, прибыльными. Объединение крестьянских и фермерских хозяйств под председательством Байтимирова Камияра Мижагитовича приобретает все больший вес и все более серьезный статус.

Важнейшим звеном между производителем и потребителем становятся сельские кооперативы: заготовительные, перерабатывающие. Хозяйства объединяются, например, как пайщики, с целью продажи своей продукции по самой выгодной цене. Каждый год создается по 50–60

Без Татарстанда кече хуҗалыкларның үсеш темплары белән бик горурланабыз һәм, әлбәттә, монда республика җитәкчелегенең өлеше зур. Татарстанның беренче Президенты М.Ш. Шәймиев иң авыр елларда да барлык киңәшмәләрдә шәхси эчке сызлануы белән: «Авылны саклап калыгыз, җирне һәлак итмәгез», – дип мөрәҗәгать итә иде.

Дәүләт ярдәме программалары буенча кредит бирү, грантлар алу өчен елга миллиардларча сум акча бүлеп бирелә. Һәм алар тупланулы, синергетик, «шартлаулы» эффект бирә: авыл җанлана, бизнес, стартаплар өчен мәйданга әверелә!

2010 елдан башлап Татарстанда фермерлыкны һәм терлекчелек фермаларын үстерүгә дәүләт ярдәме программалары эшли башлады, дәүләт тарафыннан эре мөгезле терлек фермаларын үстерүгә 500 әр мең сум, сөт фермалары төзүгә 1 миллион сумга кадәр акча бүлеп бирелде. Быел 300 кеше грант ярдәме алуга, 136 кеше – яшь фермерлар буларак, 50 кеше гаилә фермаларын үстерүгә документлар тапшырды. Ел саен республика бу өлкәгә күбрәк акча бүлеп бирә, ә фермер хуҗалыклары технологик яктан тагын да камилрәк, табышлырак була бара. Камияр Мижагит улы Байтимеров рәислегендәге крестьян һәм фермер хуҗалыклары берләшмәсе тагын да зуррак һәм тагын да җитдирәк статус ала.

Авыл кооперативлары – әзерләү, эшкәртү кооперативлары җитештерүче һәм кулланучы арасында иң мөһим буын булып тора. Хуҗалыклар,

новых кооперативов и миникооперативов с оборотом до 5 млн руб. в год. В настоящее время в Татарстане 295 кооперативов, 125 кооперативов сотрудничают с министерством.

Приятно видеть, как развиваются молодые хозяйства: «Юлдыз» (Кайбицкий район), «Барэкет» (Азнакаевский район), «Фермер» (Мамадышский район), «У Мырзая» (Сабинский район), завода по производству кормов «Монокорм». В Муслюмовском районе молодой кооператив «Фаиза» научился делать сыры по голландской технологии. В кооперативе «Деревня» (интересно, что организовал хозяйство иммигрант из Европы) – уникальное производство и методы хранения ягод и фруктов.

Свою посильную лепту в «продовольственную безопасность» республики вносят и личные подворья. Личные подворья Татарстана – это более 100 тыс. голов коров и крупного рогатого скота, главный акцент в этом сегменте – на сохранении традиций, культуры сельского образа жизни.

В общую казну личных подворий по разным статьям и формам поддержки каждый год из бюджета выделяется около 2 млрд руб. На корову выделяется ежегодное пособие в 3 тыс. руб., на козу – 500 руб. Это те деньги, что возвращаются сторицей, может быть, не в виде прямой и быстрой прибыли, а в виде ухоженной, обогащенной земли, качественной продукции. А значит, будут развиваться деревни и села, и жизнь будет продолжаться на нашей земле!

пайчылар кебек үк, үз продукцияләрен иң отышлы бәядән сату максаты белән берләшәләр. Ел саен 5 млн. сумга кадәр әйләнештәге 50-60 яңа кооператив һәм миникоператив төзелә. Хәзерге вакытта Татарстанда 295 кооператив бар. 125 кооператив министрлык белән хезмәттәшлек итә.

«Йолдыз» (Кайбыч), «Бәрәкәт» (Азнакай районы), «Фермер» (Мамадыш районы), «Умырзая» (Саба районы), «Монокорм» терлек азыгы җитештерү заводы кебек яшь хуҗалыкларның үсешен күрү күңелне бизи. Мөслим районында яшь «Фаиза» кооперативы сырларны Голландия технологиясе буенча эшләргә өйрәнгән. «Авыл» кооперативында (шунысы кызык, әлеге хуҗалыкны Европадан килгән иммигрант оештырды) җиләк-җимешне уникаль җитештерү һәм саклау алымнары гамәлгә ашырыла.

Республиканың азык-төлек иминлегенә на шәхси хуҗалыклар да үз өлешләрен кертә. Татарстанның шәхси хуҗалыклары – 100 мең баштан артык сыер һәм эре мөгезле терлек, бу сегментта төп урынны били – гореф-гадәтләрне, авылның яшәү рәвеше мәдәниятен саклауда зур әһәмияткә ия.

Төрле юнәлешләр һәм ярдәм күрсәтү буенча шәхси хуҗалыкларның гомуми казнасына ел саен бюджеттан 2 миллиард сумга якын акча бүлеп бирелә, сыерга – ел саен 3 мең сум, кәҗәгә – 500 сум. Бу туры һәм тиз табыш рәвешендә түгел, ә каралган, баетылган җир, сыйфатлы продукция рәвешендә кире кайтарыла торган акчалар. Димәк, авыллар да үсәчәк, җиребездә тормыш дәвам итәчәк!

20

ЯКУШКИН НИКОЛАЙ МИХАЙЛОВИЧ

Доктор экономических наук, профессор, заслуженный экономист Республики Татарстан, лауреат Государственной премии РТ в области науки и техники, более 19 лет работал заместителем министра сельского хозяйства по экономике и развитию малых форм хозяйствования. С 2013 по 2019 г. – ректор ФГОУ ДПО «Татарский институт переподготовки кадров агробизнеса» (ТИПКА)

НИКОЛАЙ МИХАЙЛОВИЧ ЯКУШКИН

Икътисад фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы, ТРның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт бүәге лауреаты. 19 елдан артык авыл хуҗалыгы министрының хуҗалык итүнең кече формалары икътисады һәм үсеше буенча урынбасары булып эшли. 2013 елдан 2019 елга кадәр – «Татарстан агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институты» өстәмә һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры

СКОЛЬКО ЗНАЕШЬ – СТОЛЬКО СМОЖЕШЬ

Есть такая народная мудрость «Сколько знаешь – столько можешь». Перефразирую: если ты обладаешь современными знаниями, то тебе многое под силу.

Я начинал работать тогда, когда еще существовало колхозно-совхозное сельское хозяйство. На моих глазах произошли очень важные изменения, некоторые из них вселяли надежду, а некоторые заставляли искать выход на региональном уровне. Например, все 90-е годы сельское хозяйство существовало в условиях, когда государство не создавало элементарных условий для его развития. Минтимер Шарипович Шаймиев и министр сельского хозяйства Фатих Саубанович Сибгатуллин много размышляли тогда: как республике идти дальше. В Нижнем Новгороде по указу Ельцина распустили совхо-

Халыкта «Күпме беләсең – шулкадәр булдырасың» дигән фикер яши. Гыйбарәне беркадәр үзгәртәм: әгәр дә заманча белемнәргә ия булсаң, кулыңнан күп нәрсә киләчәк.

Мин колхоз-совхоз авыл хуҗалыгы заманында эшли башладым. Күз алдымда бик мөһим үзгәрешләр булды, аларның кайберләре өмет уятты, ә кайберләре төбәк дәрәҗәсендә чыгу юлларын эзләргә мәҗбүр итте. Мәсәлән, 90 нчы еллар дәвамында авыл хуҗалыгы дәүләт аны үстерү өчен гап-гади мөмкинлекләр дә тудырмаган шартларда яшәде. Минтимер Шәрип улы Шәймиев һәм авыл хуҗалыгы министры Фатыйх Сәүбән улы Сибгатуллин республиканың алга таба ничек барырга тиешлеге турында күп уйландылар. Түбән Новгородта Ельцин указы

КҮПМЕ БЕЛӘСЕҢ – ШУЛКАДӘР БУЛДЫРЫРСЫҢ

зы, миллионы гектар остались без обработки. Татарстан сделал все, чтобы в этих условиях сохранить аграрный сектор.

Минтимер Шарипович Шаймиев и Рустам Нургалиевич Минниханов как сельские ребята понимали, что в землю надо сначала хорошо вкладывать, чтобы получить хороший урожай. А эффективное земледелие – это основа для эффективного животноводства.

Сегодня в развитие сельского хозяйства России выделяется из федерального бюджета 1,3%. Представьте, если мы заболеваем гриппом, врач назначает две таблетки, которые надо пить 4 раза в день. Но если мы будете пить по полтаблетки – эффекта не будет. Потому что существует такое понятие, как порог эффективности: две таблетки дают этот эффект, а полтаблетки –

буенча совхозлар таркатылган, миллионнарча гектар җирләр эшкәртелмичә калган. Әлеге шартларда аграр секторны саклап калу өчен Татарстан барысын да эшләде.

Шәймиев һәм Рөстәм Нургали улы Миңнеханов, авыл уллары буларак, яхшы уңыш алу өчен, иң элек җиргә мулдан акча кертергә кирәклеген аңлап эш иттеләр. Ә нәтиҗәле игенчелек – нәтиҗәле терлекчелек өчен нигез.

Бүген Россия авыл хуҗалыгын үстерүгә федераль бюджеттан 1,3 % бүлеп бирелә. Күз алдыгызга китерегез: әгәр дә без грипп белән авырый калсак, табиб көнгә 4 тапкыр эчәргә тиешле ике сәдәп дару билгеләи. Тик ярты сәдәп эчсәк, нәтиҗә булмаячак. Чөнки нәтиҗәлелек бусагасы кебек төшенчә бар: ике сәдәп нәтиҗә бирәчәк,

уже нет. 1,3% федерального бюджета – это как раз полтаблетки, которые не позволяют решать кардинально важные вопросы сельского хозяйства. А ведь были времена, когда вкладывали до 16% бюджета. Тогда мы видели, как интенсивно идет мелиорация, строятся социальные объекты на селе и т.д.

Сегодня, когда говорят об успехах обеспечения продовольственной безопасности, действительно, определенные подвижки сделаны, но заслуга в этом принадлежит больше региональному правительству. В Татарстане хорошо понимают, насколько это важно. Уже в 90-е годы мы не менее 10% республиканского бюджета вкладывали в развитие сельского хозяйства. Это позволило республике давать 2,9% российской продукции. Сегодня мы даем 4,5% – в полтора раза увеличилось производство сельскохозяйственной продукции.

Продовольственная безопасность – это тогда, когда продукция выходит на медицинские нормы потребления продуктов питания. Качественная, например халяльная, продукция стоит на 30–40% дороже. Чтобы быть самостоятельными, независимыми в обеспечении продовольственной безопасности, надо постепенно, планово уходить и от завозных кормов, и от завозной техники, и от завозных семян, что собственно и делает Татарстан.

